Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

# Социалистик ТАТАРСТАН

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ, ТАССР ЮГАРЫ СОВЕТЫ һӘМ МИНИСТРЛАР СОВЕТЫ ОРГАНЫ
ОРГАН ТАТАРСКОГО ОБКОМА КПСС, ВЕРХОВНОГО СОВЕТА И СОВЕТА МИНИСТРОВ ТАССР

Газета 1918 елның 12 мартыннан бирле чыга

№ 70—71 (20970—20971). ◆ Якшәмбе, 25 март, 1990 ел ◆ Бәясе 6 тиен.

## ТАСС белдерүе

СССР Президенты иптәш М. С. Горбачевның «Литва ССР территориясендә совет гражданнарының хокукларын тәэмин итү, ССР Союзының суверенитетын саклау буенча өстәмә чаралар турында»гы 1990 ел, 21 март Указын һәм СССР хөкүмәтенең 20 март Белдерүендәге поручениеләрне үтәү йөзеннән, СССР Дәүләт иминлеге комитетының чик буе гаскәрләре Литва ССР территориясе буйлап үтә торган дәүләт чигендә заставаларны һәм башка подразделениеләрне ныгыттылар. Чик сакчылары таможня учреждениеләренә кешеләрне һәм йөкләрне дәүләт чиге аша үткәрү режимын көчәйтүдә ярдәм күрсәтәләр. Совет гражданнарының республика территориясеннән чыгуына контроль көчәйтелде. Литвага чит ил гражданнары кертүне чикләү чаралары күренә.

Оешмалардан һәм халыктан коралны алу чаралары тормышка ашырыла. Алынган корал хәрби частьларга саклауга тапшырыла. Тереклекне тәэмин итү предприятиеләрен һәм объектларын, Игналина атом электр станциясен саклау көчәйтелде.

## *Литва ССР Югары Советы Рәисе В. В. Ландсбергиска*

Литва ССРдан алына торган информациядән күренгәнчә, республика территориясендә ирекелеләрне крайны саклау оешмасы дип аталган, чик буе гаскәрләре һәм өлешчә эчке эшләр органнары эшчәнлеген алмаштыруны күздә тоткан оешмага язу бара.

Мондый һәм моңа охшаш формированиеләр булдыруга юнәлдерелгән барлык хәрәкәтләрне туктату буенча кичектергесез чаралар күрергә тәкъдим итәм. Моның үтәлүе турында ике көн эчендә хәбәр итүне сорыйм.

Литва ССР Югары Советы сессиясенең көн тәртибенә кертелгән «Дәүләткә каршы чакырулар өчен җинаять җаваплылыгы турында»гы Закон проектын кабул итүнең дөрес булмаячагына да игътибарыгызны юнәлтәм, чөнки дәүләт җинаятьләре өчен җаваплылыкны билгеләү бары тик ССР Союзы компетенциясенә генә керә.

**Совет Социалистик Республикалар Союзы Президенты М. ГОРБАЧЕВ.**

## *Республика хатын-кызлар съезды*

23 мартта КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында хатын-кызларның III республика съезды булды. «Республикабызның иҗтимагый-политик тормышында хатын-кызлар советларының роле» турындагы доклад белән ТАССР Югары Советы П[illegible]идиумы секретаре Д. С. Дәүләт[illegible] чыкты.

Доклад буенча фикер алышуларда хатын-кызлар советы эшен киләчәктә тагын да яхшырту буенча эшлекле тәкъдимнәр әйтелде.

Хатын-кызлар съездында шулай ук СССР халык депутаты, Совет хатын-кызлар комитеты рәисе З. П. Пухо[illegible], КПСС өлкә комитеты се[illegible] Р. Р. Идиатуллин, [illegible]етаре [illegible]нистрлар Советы ТАССР Ми[illegible]иров чыгыш [illegible] Рәисе М. Г. [illegible] ясадылар.

Съезд эшендә ТАССР Югары Советы Президиумы Рәисе Ш. Ә. Мустаев катнашты.

Съезд республика хатын-кызлар советының яңа составын һәм аның президиумын сайлады.

Рәсемдә: хатын-кызларның III съездыннан күренешләр.

А. АНДРОНОВ фотосы.

## Идеология комиссиясе утырышы

КПСС өлкә комитетының Идеология комиссиясе утырышында политик плюрализм шартларында партия комитетлары һәм массакүләм информация чараларының үзара бәйләнеше турындагы мәсьәлә каралды. Комиссия әгъзаларыннан тыш, анда партиянең шәһәр һәм район комитетлары секретарьлары, республиканың массакүләм информация чаралары җитәкчеләре дә катнашты.

КПСС өлкә комитетының идеология бүлеге мөдире Р. М. Харисов доклад ясады. Мәсьәләне тикшерүдә «Советская Татария» газетасы редакторы Е. А. Лисин, ТАССР Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт комитеты рәисе И. К. Хәйруллин, Югары Ослан районында чыга торган «Волжская новь» газетасы редакторы Р. С. Троицкая, КПССның Бөгелмә шәһәр комитеты секретаре Г. Ф. Лукашова һәм башкалар катнашты.

Утырышта билгеләп үтелгәнчә, тормышның рухи-идеология өлкәсендә бара торган процесслар, политик һәм милли үзаңның үсүендәге яңа тенденцияләр партия комитетлары алдына массакүләм информация чаралары белән үзара бәйләнеш турындагы мәсьәләне аерыча кискен итеп куя. Бу бәйләнеш эштә яңа формалар һәм методларны эзләп табуга, даими диалогка, тыгыз хезмәттәшлеккә һәм үзара ихтирамга нигезләнгән булырга тиеш.

Массакүләм информация чараларына партия җитәкчелеге — ул, барыннан да бигрәк, югары компетентлылыкка нигезләнгән политик җитәкчелек. Ул исә, беренче чиратта, партия комитетларының үзләре тарафыннан булдырылган матбугат органнарының стратегиясен һәм тактикасын билгеләүдә, журналист кадрлар әзерләү турында нәтиҗәле кайгыртуда, матбугат эшчәнлегендә партия хезмәткәрләренең даими катнашуында чагыла.

Чыгыш ясаучылар күрсәтеп үткәнчә, политик плюрализм шартларында матбугатның эчтәлегенә партия йогынтысын көчәйтүнең генә түгел, бәлки партия комитетларының конкурентлыкка сәләтле басмалар чыгару белән кызыксынуының да әһәмияте үсә бара. Республикада полиграфия базасының бүгенге торышы аны [illegible] заманча техника [illegible] белән ныгыту өчен кичектергесез чаралар күрүне таләп итә.

Идеология комиссиясенең утырышын аның рәисе — КПСС өлкә комитеты секретаре Р. Р. Идиатуллин алып барды.

Игътибар! Игътибар! Игътибар!

## АТЫМ-[illegible]АР КАНАТЫМ

Борын-борыннан ат тормышта кешенең төп терәге булган. Ул нинди генә эшләр башкармаган: җир сөргән, чәчү чәчкән, иген урган, агач ташыган... Дошман яуларына каршы көрәшкәндә дә кеше аның белән бергә киткән. Моннан тыш ат кешене туендырган, киендергән. Аның шифалы кымызы үзе генә дә ни тора! Менә шуңа күрә атка багышланып җырлар җырланган, мәкаль-әйтемнәр чыгарылган.

Әле кайчан гына ат авылның бер матур бизәге иде. Һәр колхоз-совхозда йөзәрләгән баш ат асралды. Төп тарту көче булганга, аңа игътибар да зур булды. Тораклары якты һәм чиста, азыклары мул, сбруйлары тәртиптә иде. Әмма техник коралланышның артуы шушы матур бизәкне бетерде дә куйды. Еллар узган саен ат бөтенләй онытылды. Күп урында сабантуйлары атлар чабышыннан башка гына уза башлавы нигә күңелне әрнетмәс!

[illegible] тябрь районының «Төрнәс» совхозында, Әлмәт районының Токарликов исемендәге совхозында, тагын берничә хуҗалыкта атка игътибар зур икән, бу әлеге хуҗалык җитәкчеләренең тырышлыгы гына бит. Алардан моны берәү дә таләп итми. Әлеге җитәкчеләр үз төбәкләрендә крестьян рухын ныгытырга тырышалар. Ә бүгенге авыл кешесендә җиргә, туган-үскән төбәгенә битарафлыкның зур булуында атларның юкка чыгуы да үз ролен уйнамыйча калмагандыр.

«Социалистик Татарстан» газетасы бүген атлар турында сөйләшү башлый. Бу фикернең ТАССР Агропромышленность комитетында нык яклау табуы аеруча күңелле хәл. Уртак тырышлык белән смотр-конкурс үткәрергә дә карар ителде. Без сөйләшүдә күпләр катнашыр, үз фикерен әйтер дип уйлыйбыз. Сездән хатлар көтәбез. Аларны [illegible]

## САЙЛАУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

КПСС өлкә комитеты беренче секретаре, Минзәлә территориаль сайлау округыннан СССР халык депутаты Минтимер Шәрипович Шәймиев 22—23 мартта Минзәлә һәм Сарман районнарында булып, сайлаучылар белән очрашу үткәрде. СССР халык депутаты М. Ш. Шәймиевның бирегә киләчәге турында алдан хәбәр [illegible] алдынгы сыер савучылары слетына — һәр колхоз һәм совхоздан терлекчеләр килгән иде.

Хуҗамәт авыл культура йорты гөрләп тора. Моңа сәбәбе дә бар: районда һәр сыердан көнлек савым 11 килограммга якын. Ә байтак укганнар һәр сыердан көнлек савымны поттан арттырганнар. Ярышка йомгак [illegible] лешен тизләтү, шәһәр һәм авыллардагы өйләргә табигый газ кертү эшләрен кызулату зарурлыгы турында барды. «Кара алтын» чыгаручыларның культура-көнкүреш шартларын яхшыртуда, нефтьчеләр поселогын тедекләндерүдә «Татнефть» берләшмәсенең игътибарын нык арттырырга кирәклеге турында да тәкъдимнәр әй[illegible]

## Республика семинары

21—22 мартта Казанда КПССның шәһәр һәм рай[illegible] комитетлары идеология [illegible] кинның тууына 120 ел тулу[illegible] га һәм совет халкының Бө[illegible]

митетының Политик мәгариф йортында хатын-кызларның III республика съезды булды. «Республикабызның иҗтимагый-политик тормышында хатын-кызлар советларының роле» турындагы доклад белән ТАССР Югары Советы П[illegible]зидиумы секретаре Д. С. Дәүләт[illegible]ты.

Доклад буенча фикер а[illegible]

[illegible] объективль[illegible] фикер һәм иҗат[illegible]

[illegible] яхшырту буенча эшлекле тәкъдимнәр әйтелде.

Хатын-кызлар съездында шулай ук СССР халык депутаты, Совет хатын-кызлар комитеты рәисе З. П. Пухо[illegible] КПСС өлкә комитеты секретаре Р. Р. Идиатуллин, [illegible] министрлар Советы [illegible] ТАССР [illegible]биров чыгыш [illegible]

[illegible] Рәисе Ш. Ә. Мустаев катнашты.

Съезд республика хатын-кызлар советының яңа составын һәм аның президиумын сайлады.

Рәсемдә: хатын-кызларның III съездыннан күренешләр.

А. АНДРОНОВ фотосы.

[illegible]сы редакторы Е. А. Лисин, ТАССР Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт комитеты рәисе И. К. Хәйруллин, Югары Ослан районында чыга торган «Волжская новь» газетасы редакторы Р. С. Троицкая, КПССның Бөгелмә шәһәр комитеты секретаре Г. Ф. Лукашова һәм башкалар катнашты.

Утырышта билгеләп үтелгәнчә, тормышның рухи [illegible] өлкәсендә бара торган процесслар, политик һәм милли үзаңның үсүендәге яңа тенденцияләр партия комитетлары алдына массакүләм информация чаралары белән үзара бәйләнеш турындагы мәсьәләне аерыча кискен итеп куя. Бу бәйләнеш эштә яңа формалар матбугат эшчәнлегендә партия хезмәткәрләренең даими катнашуында чагыла.

Чыгыш ясаучылар күрсәтеп үткәнчә, политик плюрализм шартларында матбугатның эчтәлегенә партия йогынтысын көчәйтүнең генә түгел, бәлки партия комитетларының конкурентлыкка сәләтле басмалар чыгару белән кызыксынуының да әһәмияте үсә бара. Республикада полиграфия базасының бүгенге торышы заманча техника [illegible] белән ныгыту өчен кичектергесез чаралар күрүне таләп итә.

Идеология комиссиясенең утырышын аның рәисе — КПСС өлкә комитеты секретаре Р. Р. Идиатуллин алып барды.

Игътибар! Игътибар! Игътибар!

# АТЫМ — ПАР КАНАТЫМ

**Борын-борыннан ат тормышта кешенең [illegible] булган. Ул [illegible] генә эшләр** башкармаган: җир сөргән, чәчү чәчкән, иген урган, агач ташыган... Дошман яуларына каршы көрәшкәндә дә кеше аның белән бергә киткән. Моннан тыш ат кешене туендырган, киендергән. Аның шифалы кымызы үзе генә дә ни тора! Менә шуңа күрә атка багышланып җырлар җырланган, мәкаль-әйтемнәр чыгарылган.

Әле кайчан гына ат авылның бер матур бизәге иде. Һәр колхоз-совхозда йөзәрләгән баш ат асралды. Төп тарту көче булганга, аңа игътибар да зур булды. Торaклары якты һәм чиста, азыклары мул, сбруйлары тәртиптә иде. Әмма техник коралланышның артуы шушы матур бизәкне бетерде дә куйды. Еллар узган саен ат бөтенләй онытылды. Күп урында сабантуйлары атлар чабышыннан башка гына уза башлавы нечек күңелне әрнетмәс!

Хәзер республикабызда ат асрау энтузиастлар кулына калды дияргә була. Мөслим районының «Урожай» колхозында, Октябрь районының «Тәрнәс» совхозында, Әлмәт районының Токарликов исемендәге совхозында, тагын берничә хуҗалыкта ат[illegible]ка игътибар зур икән, бу әлеге хуҗалык җитәкчеләренең тырышлыгы гына бит. Алардан моны берәү дә таләп итми. Әлеге җитәкчеләр үз төбәкләрендә крестьян рухын ныгытырга тырышалар. Ә бүгенге авыл кешесендә җиргә, туган-үскән төбәгенә битарафлыкның зур булуында атларның юкка чыгуы да үз ролен уйнамыйча калмагандыр.

«Социалистик Татарстан» газетасы бүген атлар турында сөйләшү башлый. Бу фикернең ТАССР Агропромышленность комитетында нык яклау табуы аерыча күңелле хәл. Уртак тырышлык белән смотр-конкурс үткәрергә дә карар ителде. Без сөйләшүдә күпләр катнашыр, үз фикерен әйтер дип уйлыйбыз. Сездән хатлар көтәбез. Аларны «Атым — пар канатым» дип исемләп җибәрегез. (Смотр-конкурска кагылышлы материалларның дәвамын 7 нче биттән укыгыз.)

# САЙЛАУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

КПСС өлкә комитеты беренче секретаре, Минзәлә территориаль сайлау округыннан СССР халык депутаты Минтимер Шәрипович Шәймиев 22—23 мартта Минзәлә һәм Сарман районнарында булып, сайлаучылар белән очрашу үткәрде. СССР халык депутаты М. Ш. Шәймиевның бирегә киләчәге турында алдан хәбәр ителгән иде. Шуңлыктан 22 мартта иртәннән алып КПССның Минзәлә райкомы бинасында СССР халык депутатына үтенеч белән мөрәҗәгать итүчеләр күп булды. Аннары ул район комитетының конференцияләр залында район партия-хуҗалык активы белән очрашты.

Иптәш М. Ш. Шәймиев анда катнашучыларны СССР халык депутатларының чираттан тыш III съезды һәм КПСС Үзәк Комитетының март Пленумы карарлары белән таныштырды. Аларда кабул ителгән карарлардан чыгып, алда торган бурычлар турында сөйләде. Илдә политик һәм экономик реформаны тормышка ашыру һәм XXVIII съездга хәзерлек чорында партия оешмалары хәл итәргә тиешле мөһим мәсьәләләргә тукталды, игътибарны массалар арасында идея-политик, оештыру-партия эшен нык җанландыру зарурлыгына юнәлдерде.

М. Ш. Шәймиев көн уртасында Куйбышев исемендәге колхозда алдынгы терлекчеләр белән очрашуга барды. Бирегә — районның алдынгы сыер савучылары слетына — һәр колхоз һәм совхоздан терлекчеләр килгән иде.

Хуҗамәт авыл культура йорты гөрләп тора. Моңа сәбәбе дә бар: районда һәр сыердан көнлек савым 11 килограммга якын. Ә байтак унганнар һәр сыердан көнлек савымны поттан арттырганнар. Ярышка йомгак ясау, алда торган бурычларны билгеләү белән берәттән, сүз үзеннән-үзе наказларның үтәлеше барышы мәсьәләсенә кереп китте. Кайбер наказларның инде тормышка ашырылуы турында әйтелде. Депутатка яңа наказлар да бирелде.

Төп игътибар әле хәл ителмәгән мәсьәләләргә, тормышка ашырасы мөһим бурычларга юнәлдерелде. М. Ш. Шәймиев, республика күләмендә мул сөт җитештерү белән танылып барган Минзәлә районы уңганнарына рәхмәт әйтеп, азык-төлек программасын тормышка ашыру буенча алда торган мөһим бурычларга тукталды. Аннары наказларның үтәлеше барышы турында сөйләде.

СССР халык депутаты М. Ш. Шәймиев төштән соң партия райкомы бинасында тагын сайлаучыларны кабул итте. Хезмәт ияләре белән очрашу һәм аларны кабул итү вакытында сүз күбесенчә халыкның социаль-көнкүреш хәлен яхшырту, шул исәптән бигрәк тә Минзәлә шәһәрендә һәм район авылларында торак, юллар төзелешен тизләтү, шәһәр һәм авыллардагы өйләргә табигый газ кертү эшләрен кызулату зарурлыгы турында барды. «Кара алтын» чыгаручыларның культура-көнкүреш шартларын яхшыртуда, нефтьчеләр поселогын төзекләндерүдә «Татнефть» берләшмәсенең игътибарын нык арттырырга кирәклеге турында да тәкъдимнәр әйтелде.

Иптәш М. Ш. Шәймиев Минзәләдә булганда сайлаучылар аңа Түбән Кама ГЭСы суςаклагычы 62 нче билгедән бүтән күтәрелмәсен иде дигән тәкъдим әйттеләр. Депутат бу мәсьәләне уңай хәл итү өчен тырышлык куячагын белдерде. Очрашу вакытында шулай ук табигатьне саклау, Минзәлә шәһәрендә чистарту корылмаларын төзүне төгәлләү, медицина хезмәте күрсәтүне яхшырту мәсьәләләре дә күтәрелде.

23 мартта М. Ш. Шәймиев иртәнге якта район үзәгендә халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләрендә булды, аларның эшен яхшыртуга юнәлдерелгән фикерләрен әйтте. Иптәш М. Ш. Шәймиев Сарман районы сайлаучылары белән очрашты. СССР халык депутаты КПССның Сарман райкомы бинасында гражданнарны кабул итте. Аннан соң культура йортында район партия һәм хуҗалык активы, партоешма секретарьлары, район хезмәт ияләре белән очрашты. Сайлаучылар аңа күп сораулар бирделәр һәм сорауларына җаваплар алдылар.

## Республика семинары

21—22 мартта Казанда КПССның шәһәр һәм район комитетлары идеология секретарьларының республика семинары булды. Алар үзгәртеп коруның хәзерге чорында, җәмгыять тормышын демократияләштерүнең киңәя баруы, хезмәт ияләренең актив политиклашуы шартларында идеология эшен камилләштерүнең мөһим проблемаларын тикшерделәр.

Семинарның көн тәртибенә РСФСР, ТАССР һәм җирле Советлар халык депутатларын сайлауның политик йомгаклары, республикада иҗтимагый-сәяси хәлгә анализ, милләтара мөнәсәбәтләрне, үзешчән иҗтимагый-сәяси берләшмәләр белән үзара мөнәсәбәтләрне камилләштерү проблемалары, В. И. Ленинның тууына 120 ел тулуга һәм совет халкының Бөек Ватан сугышында Җиңүенең 45 еллыгына әзерлекне оештыру һәм башка мәсьәләләр кертелде.

Семинарда катнашучылар «Ленинизм һәм хәзерге чор» дигән темага оештырылган «түгәрәк өстәл»дә, партиянең XXVIII съездына КПСС Үзәк Комитеты Платформасы һәм КПСС Уставы проектлары. Демократик платформа проекты материаллары буенча оештырылган «Партия һәм үзгәртеп кору» дигән дискуссиядә, шулай ук КПСС өлкә комитетының Идеология комиссиясе утырышында катнаштылар.

Семинарны КПСС өлкә комитеты секретаре Р. Р. Идиатуллин алып барды.

## Язучылар җыены

Шушы елның 23 мартында Казанның Актерлар йортында Татарстан Язучылар берлегенең киңәйтелгән пленумы булды. Ул узган ел дөнья күргән әдәби әсәрләр турында сөйләшүгә, ягъни әдәби ел йомгагына багышланды. Аны кереш сүз белән РСФСР халык депутаты, ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. С. Мөхәммәдиев ачты.

Пленумда катнашучылар шагыйрь З. Мансуровның шигъри әсәрләр, язучы Т. Әйдинең чәчмә әсәрләр, язучы Л. Леронның балалар әдәбияты, В. Корчагинның республикабызда яшәп иҗат итүче рус әдипләре иҗатлары турындагы докладларын тыңладылар.

Алар буенча фикер алышуда язучылар В. Лаврешко, Р. Хисмәтуллин, Н. Әхмәдиев, Ә. Мәхмүдов, Р. Зәйдуллин, Э. Мөэминова, М. Вәлиев, С. Шәмси, Р. Мингалим, Җ. Тәрҗеманов, Р. Кәрами һәм башкалар чыгыш ясады.

Татарстан Язучылар берлегенең киңәйтелгән пленумы 14 нче Батыршин сайлау округына ТАССР халык депутатлыгына кандидатлар күрсәтү мәсьәләсен карады. Башта берничә кандидат тәкъдим ителгән иде. Соңыннан, күпчелек тавыш белән, ТАССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Гәрәй Рәхим кандидатурасын күрсәтү турында карар кабул ителде.

Татарстан Язучылар берлегенең киңәйтелгән пленумында ТАССР мәдәният министры М. М. Таишев катнашты.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Экономик эш өлкәсендәге хезмәтләре өчен Казан мотор төзү производство берләшмәсенең план-экономик бүлеге начальнигы урынбасары Рим Шәриф улы **Кәримовка**, Татарстан АССР Югары Советы Президиумының 1990 ел, 20 март Указы белән, **«Татарстан АССРның атказанган экономисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

• • •

Нәтиҗәле фәнни-педагогия эшчәнлеге өчен В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының механика-математика факультеты деканы, гомуми математика кафедрасы мөдире, профессор Владимир Владимирович **Вишневскийга**, Татарстан АССР Югары Советы Президиумының 1990 ел, 20 март Указы белән, **«Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

• • •

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге хезмәтләре өчен Буа районы үзәк больницасының балалар бүлеге мөдире Зәрият Фатыйх кызы **Фәйзетдиновага**, Татарстан АССР Югары Советы Президиумының 1990 ел, 20 март Указы белән, **«Татарстан АССРның атказанган врачы»** дигән мактаулы исем бирелде.

• • •

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ленин комсомолы исемендәге Казан яшь тамашачылар театры артистлары Вячеслав Васильевич **Казанцевка** һәм Роза Вәкил кызы **Хәйруллинага**, Татарстан АССР Югары Советы Президиумының 1990 ел, 20 март Указы белән, **«Татарстан АССРның атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

## Хезмәтен хөрмәтләп

Комсомол һәм партия органнарында озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен КПССның Алабуга шәһәр комитеты секретаре Доларис Гайнетдин кызы **Галләмова**, Татарстан АССР Югары Советы Президиумының 1990 ел, 20 март Указы нигезендә, Татарстан АССР Югары Советы Президиумының **Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

# 70 Туган җирем Татарстан

## Барасың куанып, кайтасың юанып

Күптән түгел Арча поселогы урамнары буйлап Советлар мәйданына ашыга-ашыга атлаучы хатын-кызлар, ирләр, балаларны күзәтергә туры килде. Алар барысы да ярминкәгә ашыга. «Базар керткән — баеган» дигәндәй, чыннан да, ярминкәгә мал күп куелган. Нәрсәләр генә юк анда. Киемсалым дисеңме, ашамлык дисеңме, бизәнү-косметика әйберләре һ. б.

«Базарга һәркем барыр, үзенең кирәген алыр» дигән халкыбызның мәкале, бу ярминкәнең исеменә дә, җисеменә бик тәңгәл килә иде. Ярминкәдә катнашучыларның һәркайсы мул товар, үзенә кирәк-яракны сайлап ала алды. Сатып алучылар бар да шат, канәгать иде. Ничек шулай булмасын! Сатучы иптәшләр бик күркәм холыклы, тәмле телле, итагатьле, сабыр, ачык йөзле. Шуңлыктан ярминкәнең һәр ноктасында сатучы иптәшләр һәм сатып алучылар арасында бер-берсен ихтирам итеп сөйләшү, яхшы мөнәсәбәт урнашкан. Ярминкә көн озын барса да, берниндиямьсез күренешләр күзгә чалынмады, ә киресенчә, һәркайда уен-көлке, җырбию, күңел кылларын чиртеп алучы көйләр.

Кемдер «Менә сиңа мал — үзең сайлап ал», дигән хакыйкатьне истә тотып, үзенә аеруча ошаган әйберне сайлый, кемдер тәмле-тәмле камыр ризыклары белән хуш исле чәй эчә, кемдер шашлыктан авыз итә, ә кемдер үзешчәннәрнең концертын карарга ашыга...

Арчалыларга зур бәйрәм программасын бүләк итүчеләргә — Казанның Совет районы җәмәгать туклануы һәм сәүдә предприятиеләре хезмәткәрләренә, шулай ук КПССның Арча райкомының идеология бүлегенә арчалыларның чиксез рәхмәтен юллыйсы килә.

**Н. САТТАРОВ,**
хезмәт ветераны.

## Әнвәр — фермер

Моңа кадәр Ильич исемендәге колхозда баш агроном булып эшләгән Әнвәр Мостафин башка районга киткән иде. Ул яңадан әлеге хуҗалыкка күченеп кайтты. Колхоз аның гаиләсенә Көрәшбүләк авылында йорт бүләк итте.

Әнвәр Мостафин үткән ел, аренда звеносы төзеп, 100 гектар мәйданда бертөклекузаклы культуралар һәм бәрәңге икте. Быел исә фермерлык хуҗалыгы булдыруга керәште. Колхоздан 12 баш кара-чуар токымлы таналы алды, савым җайланмалары юнәтте. Инде кайбер таналар бозаулый башлады. Терлекләр хуҗалыктан алынган бинада асрала. Фермер колхоздан йөк автомашинасы да сатып алды. Терлекләрне азык белән тәэмин итү өчен колхоздан җир бүлеп бирү турында сөйләшүләр алып барыла.

Фермер хуҗалыгында, гаилә башлыгыннан тыш, аның хатыны һәм балалары эшли.

**Ф. ЗӘЙНАГЫТДИНОВ.**
Баулы районы.

## РСФСР Югары Советы Президиумы Указы

**В. С. Федорованы РСФСР Югары Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләү турында**

Совет органнарында озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен Татарстан АССР Югары Советы Президиумының бүлек мөдире Валентина Сергеевна **Федорованы** **РСФСР Югары Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләргә.**

**РСФСР Югары Советы Президиумы Рәисе**
**В. ВОРОТНИКОВ.**

**РСФСР Югары Советы Президиумы Секретаре**
**С. ЧИСТОПЛЯСОВ.**

Мәскәү.
1990 ел, 23 март.

Татарстанга—союздаш республика статусы!

# Мөстәкыйльлек әлифбасы

**Менә бишенче ел инде без үзгәртеп корудан ниндидер могҗиза көтәбез. СССР депутатларына, Президентлык властена, КПССның булачак XXVIII съезды карарларына өметләнәбез. Ләкин могҗиза булмаячак. Әгәр «югарыдан» инициатива көтеп торсак, без бары тик бер нәрсәгә генә — республика экономикасының тулысынча уңышсызлыкка очравына гына ирешәчәкбез. Татарстанның киләчәге өчен без үзебез, хөкүмәтебез җавап бирә. Ләкин моның өчен безнең тиешле политик хокукларыбыз булуы кирәк.**

СССР хөкүмәте безгә, Татарстан Дәүләт план комитеты белән бергәләп, региональ хуҗалык исәбе механизмын тәкъдим итә. Янәсе, ул безгә үзидарә һәм үзфинанслау мөмкинлеген бирер, республика халкының хокукларын киңәйтер. Мин үзем бу чараларны халыкның хокукларын киңәйтү дип түгел, ә безнең хокукларны законсыз рәвештә тартып алу дип бәяләр идем. Экономик мөстәкыйльлек дип аталган нәрсәнең кайбер иң төп якларына гына күз салыйк.

Җирдән һәм табигый ресурслардан без үзебез файдалана алмыйбыз. Нефтьтән килгән долларлар үзәк органнар кулына керә, безгә исә тозланган җирләр һәм тозлы чишмәләр генә кала. Шул җәһәттән безне нинди перспектива көтә соң? Нефть тиздән бетәчәк, экологияне торгызу һәм халыкны эшкә урнаштыруның барлык проблемалары безнең җилкәгә авыр таш булып утырачак, ә ул таш Татарстан экономикасын һаман батыра барачак. Исең китәр, үзебезнең гаять зур табигый байлыкларыбыз үз өстебезгә шулай бәхетсезлек булып төшсен әле!

Татарстанда тәкъдим ителгән үзидарә һәм үзфинанслау механизмы нормативтан тыш табышны һәм товарларны үз республикабызда калдыру мөмкинлеген күздә тота, ә менә нормаларны — дәүләт **заказларын** һәм лимитларны — тулысынча югары инстанцияләр билгели. Башкача әйткәндә, РСФСР безгә план күрсәткечләрен үз ихтыяры белән арттыра ала. Кайда монда үзидарә? Кайда монда халыкларның хокуклары! Юк алар!

**ТАССР бюджетын РСФСР** [illegible] билгели, өстәвенә, бу елга ул 48 миллион сум дефицит белән билгеләнде. Ә бит без илгә 2,5 миллиард табыш китерәбез. Эш хакыбыз да, бурычларыбыз да менә шушы дефицит белән бәйләнгән ләбаса. Нинди гөнаһлары өчен Татарстан халкы Россия алдында мәңгелек бурычлы соң? Кайда монда үзфинанслау? Юк ул. Татарстанның РСФСР белән мөнәсәбәтләрен «вассал» (бәйлелек) мөнәсәбәтләр дип кенә әйтергә мөмкин.

Безнең экономик һәм социаль проблемаларыбызны бары тик бер шарт үтәлгән[illegible]

шы мәгънәсезлекне политиклар халыкның хокукларын киңәйтү дип атыйлар.

Хәзер бу хакта сөйләшүләр белән чикләнү генә җитми. Сөйләшү күп булды инде. Җиргә һәм табигый ресурсларга милек турында Татарстан республикасы Законы кирәк. Безнең рөхсәттән башка җирдән вәхшиләрчә файдалану булмасын, безнең рөхсәттән башка бер генә үзәк министрлык та АЭСлар һәм башка промышленность объектлары төзи алмасын, үз рөхсәтебездән башка безнең территориядә бер адым да ясый алмасын.

Аннары, без үз мәнфәгатьләребезне, үз халкыбызны, балаларыбызны үзәк министрлыклар экспансиясеннән сакларга тиешбез. Ә моны республика халкының **суверен** хокуклары турында закон кабул итү аша эшләргә кирәк. Мондый закон халык мәнфәгатьләренең үзәк министрлыклар мәнфәгатьләреннән өстен торуын төгәл билгеләр, промышленность төзелешен җайга салу һәм җитештерүче көчләрне урнаштыру өчен республика хөкүмәтенә вәкаләтләр бирер иде. Безнең кулда союз министрлыкларының республика халкы мәнфәгатьләренә каршы килә торган карарларын туктатып тора ала торган закон булырга тиеш.

Үзәк тарафыннан халыктан тартып алынган тагын бер хокук бар, ул — **хезмәтең өчен тиешенчә алу** хокукы. Без илебезгә бик зур табыш бирәбез. Әмма үзебездә торак, мәктәпләр, больницалар җитмәүдән интегәбез. Китапларны һәм музей хәзинәләрен саклар урыныбыз юк, акыл ияләребез читкә китеп бара, фәнни һәм мәдәни потенциал [illegible] кимеде. Татарстан республикасының акчасы юк, аның каравы эшләргә, эшләргә һәм тагын бер тапкыр эшләргә хокукы бар. Безгә Татарстанның **бюджет мөстәкыйльлеген һәм налог инициативасы хокукын билгели торган закон кирәк.** Бюджетыбызның Мәскәү чиновниклары башбаштаклыгына түгел, ә үз хезмәтебезгә бәйле булуы кирәк. Шундый законнан башка бездә бернинди үзфинанслау һәм үзидарә булмаячак.

Һиһаять, безгә республиканың **экономик мөстәкыйль**[illegible]

дагыдай хокукларга ия түгел, ә инде автономияле республикалар турында әйтеп тә торасы юк. Союздаш республиканың андый хокуклары булса, Балтик буе республикалары да Союздан чыгу мәсьәләсен куймаслар иде. Хәер, штат кынамы соң, иң унитар дип исәпләнгән дәүләттә дә теләсә кайсы департаментның, префектура, провинция, графлыкның да хокуклары Татарстанныкыннан күбрәк. Чөнки дөньяда һәркайда департаментларның реаль үзидарәсе бар, мөстәкыйль бюджетлары һәм налогы бар. Алар миграция процессларын үзләре җайга салып яшиләр, үз территорияләрендә җирдән һәм ресурслардан үзләре файдаланалар. Дөньяның барлык илләрендә региональ политика дигән төшенчә яши, бары тик Татарстанда гына региональ политиканы яклап чыгучыларны экстремистлар дип атыйлар.

Русларның күбесен Татарстанның СССР составыннан чыгу перспективасы куркыта. Янәсе, андый очракта өлкәләр һәм республика арасында стена үсеп чыгачак. Хәтта: «Бербөтен һәм бүленмәс Россияне аергалап бетерергә юл куймабыз!» — дигән авазлар да яңгырый. Бу фикер бары тик мәсьәләгә төшенеп җитмәүгә корылган. Татарстанның мөстәкыйльлеге һич тә Россия белән элемтәләрнең йомшаруын аңлатмый, киресенчә, бәйләнеш ныгыячак кына. Хәзерге бюрократлык мөнәсәбәтләре үзара файдалы экономик бәйләнеш белән алыштырылачак. Европага күз салыгыз, анда гаять көчле интеграция процесслары бара, ә милли экономикаларның мөстәкыйльлеге һич тә бозылмый. Экономик мөстәкыйльлек бюрократлык интеграциясе өчен түгел, ә чын интеграция өчен шарт булып хезмәт итә ала. Мәсәлән, хәзер Чаллыдан Балтик буе республикаларына бетон әйберләр ташыйлар. Кемгә файдалы бу? Татарстангамы? Россиягәме? Балтик буенамы? Ул бары тик бюрократиягә файдалы. Татарстанның экономик мөнәсәбәтләре күптән инде гомумсоюз мөнәсәбәтләренә әверелде, чөнки безнең продукциянең 85 проценты гомумсоюз буйсынуындагы предприятиеләрдә җитештерелә. Менә шунлыктан РСФСР органнары хәзер безнең өчен экономик үсешне тоткарлый торган артык буын гына булып тора.

Федератив мөнәсәбәтләр халыклар арасында **ышаныч** урнаштыруны күздә тота. Бу ышаныч үткәннәргә дә, хәзергегә дә кагылырга тиеш. Үзәк матбугат татарларның тарихи үткәне турында ниләр генә язып бетермәде[illegible]

лар нишләр? Барлык автономияле республикаларга союздаш республикалар белән тигез хокуклар бирергә кирәк». Ничек кенә әйтмә: сәер логика бу. Элек Сталин халыкларга төрле статусларны көчләп таккан. Бүген без барысын да тигезләргә телибез, әмма һаман шул **көчләп тагу** юлы белән. Чувашлардан, марилар, калмыклар һәм башка халыклардан союздаш республика статусы кирәкме-юкмы дип сорап та тормыйбыз. Бәлки, алар моны теләмиләрдер? Нәрсә, аларны хәзер оҗмахка кусәк белән куып кертикмени? Без Әфганстанда да шул ук «изге ниятләр» белән көч ярдәмендә социализм төзергә омтылып караган идек...

Милләтләрнең тигез хокуклылыгы шунда, һәр халык үзенең политик статусын үз ихтыяры белән сайларга, кайсы функцияләрне үзендә калдырырга, ә кайсыларын үзәк органнарга бирергә кирәклеген мөстәкыйль билгели ала һәм югарыгы органнарга бирелгән функцияләрен теләсә ни вакытта кире кайтара ала.

Һиһаять, автономияле республиканың союздаш республикага күчүе механизмын кемдер беренче булып эшләргә тиештер инде.

Татарстанның союздаш республика була алу хокукын нигезләп күрсәткәндә, тарихи, экономик һәм культура ягыннан күпләгән факторлар китерелә. Дөресен әйткәндә, барлык мөнәсәбәтләр икенчел характерда гына. Монда берләнбер критерий — халыкның үз ихтыярын белдерүе. Халыкның үзбилгеләнү хокукы халыкара договорларда, Советлар Союзының дистәләгән документында теркәлгән, хәзер вексельләр буенча түләр чак җитте.

Үзәк органнарга гына түгел, безнең үзебезгә дә бер җитешсезлек хас: республикабызга, халкыбызга, милли культурабызга ведомствочыл, өлкә критерийларыннан чыгып карыйбыз. Болай ярамый.

Татар культурасы — дөнья культурасының аерылгысыз өлеше, һәм үз республикабызда бара торган процессларга бездә **планетакүләм караш** булырга тиеш. Җир цивилизациясе милли культуралар җирлегендә үсә. Аларны бердәйләштерү — мәдәниятне ярлылануга, [illegible] түгә китерә, ә аларны [illegible] төрләләндерү, киресенчә, безне моннан коткара[illegible], үзешелек өчен кечкенә[illegible] халык[illegible] «Сүнмәс дәрт» [illegible] бары[illegible]

[illegible] ратив мөнәсәбәт[illegible] лаган да без халыка[illegible] күләмдә танылган принциплардан, нормалар һәм договорлардан чыгып эш итәргә тиеш. Шунлыктан РСФСР Конституциясендә 107 нче статьяның барлыкка килүе, СССР Югары Советының автономияле берәмлекләр белән исәпләшмәве, Россиядә һәм Советлар Союзында татарларны күрмәскә тырышуы бик сәер. Татарларны Россия халкы дип кенә карарга ярамый, татарлар һәм татар мәдәнияте — гомумкешелек[illegible]

Съезд алдыннан сөйләшү

# Вакытның минуты кадерле чак

XXVIII

**Газетабызда партиядә үзгәртеп кору, КПССның XXVIII съездына әзерлекнең барышы турында сөйләшү дәвам итә. Коммунистлар үзләрен борчыган, дулкынландырган проблемаларны күтәрәләр, бәхәскә керәләр, кайвакытта каршылыклы фикерләрен белдерәләр. Ә бергәләп, уртага салып сөйләшү өчен проблемалар күп. КПСС киләчәктә үзенең авангардлык ролен үти алырмы? Ни өчен кайбер коммунистлар партия сафларыннан чыга? КПССның абруен күтәрү өчен нәрсәләр эшләргә кирәк? Безгә башка партияләр кирәкме?**

**Бу хакта партия хезмәткәрләре үзләре ничек уйлый? КПССның Арча райкомы беренче секретаре В. В. Миңһаҗев белән әңгәмә вакытында шул сорауларның кайберләренә җавап табарга тырыштык.**

**— Вагыйз Васыйлович, Платформа проектына халык зур өметләр баглый. Сезнең район коммунистлары, хезмәт коллективлары аны ничек кабул итте?**

— Партия оешмаларында аны киң тикшерү барды. Кешеләр берни яшермичә, ачыктан-ачык сөйлиләр, Платформаның төп положениеләрен хуплыйлар. Мәсәлән, автотранспорт предприятиесе пропагандисты Әхәт Зәйнуллин фикеренчә, партиягә ышанычны арттыру өчен коммунистларның, сайлап куелган органнарның үзләрен практик эштә күрсәтүе кирәк. Ләкин шуны безгә истән чыгарырга ярамый. Хезмәт ияләренә вәгъдә биреп эшләнми калган эшләребез

## КПСС Үзәк Комитеты платформасы проекты турында

күп булды. Халык сүздән туйды. Барыбызга да Платформа проектында куелган проблемаларны хәл итү өчен җиң сызганып эшләргә кала. Үзгәртеп коруның алга бармавында бөтен гаепне партиядән күрәләр. Сүз дә юк, аңһан гаепне алып ташларга беркем дә җыенмый. Ә ни өчен без үзенә тапшырылган вазифаны үти алмаган коммунистлардан тиешенчә таләп итмибез. Шул ук вакытта партия аппаратыннан, урындагы партоешмалардан гаеп эзләү гадәткә керде. Без моңа кадәр өстән кушканны үтәп килдек. Шуңа күрә югары оешмалар да үз гаепләрен танырга тиешләр. Әгәр һәр коммунист бар көч[illegible] гәрлеген җигеп, намусы[illegible] [illegible] тия үзенең [illegible] ролен үти алмаячак. Коммунист булып та партияне, теләнә нәрсә килсә, шуны әйтеп, сүгеп йөрүчеләр дә бар бит.

**— Партия аппаратын күбрәк тәнкыйтьлиләр. Ул һаман искечә эшли, дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә. Хәтта партия аппараты кирәкми, диючеләр дә бар.**

— Партияне демократияләштерү шартларында партаппаратны без ничек итеп күрергә телибез? Әмма Платформа проектында бу нәрсә[illegible]

ничек көн күрүебез турында бара. Шулай икән, РАПО нәрсәгә? Чынлыкта, партия комитеты, барыннан да элек, идеология эшенә өстенлек бирергә тиеш. Шул юнәлештә эшебезне үзгәртеп корырга тырышабыз. Бер генә көн дә аппарат хезмәткәрләренең башлангыч оешмаларда, хезмәт коллективларында булмый калганы юк. Монда эшнең яңа формалары таләп ителә. Без терлекчеләр, механизаторлар белән очрашуларны җайга салып җибәрдек. Шундый ук очрашулар интеллигенция, ветераннар белән дә уза. Мәсәлән «Мәктәп көне» үткәр[illegible]. Анда райком һәм бюро членнары, ата-[illegible] катнашты. Ачык [illegible] булдык. Уку-укы[illegible] [illegible] проблемалары турында [illegible] сөйләштек. Сүз дә юк, проблемалар күп. Әмма аларның мөмкин булганнарын вакытында хәл итәргә тырышырга кирәк.

Безне урынлы тәнкыйтьлиләр. Идеология активы киңәшмәсендә милли аяк киемнәре җитештерү берләшмәсе партия оешмасы секретаре Розалия Шәяхмәтова болай диде: «Соңгы вакытта идеология фронтында сүлпәнлек сизелә. Бердәм политкөннәрне дә үткәрми башладык». Яңа Кенәрдә булган чагында халык сәүдә, көнкүреш, транспорт эшенә кагылышлы[illegible]

лаштыруда да кимчелекләргә юл куйдык. Коммунистлар эш урынына карап сайланды. Еш кына аларның политик, эшлеклелек сыйфатлары исәпкә алынмады. Еш кына аппарат райком исеменнән эш итә. Ул шулай калганда, аппарат һаман да административ-команда ролен үтәүдән туктамаячак. Совет органнары белән партия аппаратының функцияләрен аеру сүздә генә кала бирә.

Менә үзегез күреп торасыз: без сөйләшеп утырган арада гына да фатир сорап керделәр. Аннан соң хуҗалык эшеннән бушап булмый. Бездән ит, сөт сорыйлар. Бу югарыдан килә. Бер уйлаганда, аңлашыла, сүз безнең

тия, совет җәмгыятенең житәкче һәм юнәлеш бирүче көченнән баш тартса да, ул барыбер әйдәүче ролен үтәр, дип уйлыйм. Мин үзем, мәсәлән, үзгәртеп коруны җитәкли алырлык башка көч күрмим.

**— Сез күппартиялелеккә каршы...**

— Модага ияреп, күп партияләр таләп итүчеләр бар. Монда илдә туган хәлдән чыгып эш итәргә кирәк. Әгәр берничә партия төзелә икән, власть өчен көрәш башланачак. Ә бу — куркыныч нәрсә. Платформа проектында әйтелгәнчә, партия үзенең политик лидер булуын саклап калырга тиеш. Монда һәрнәрсә бизмәнгә салып эш итүне сорый. Партия үзен эштә күрсәтергә, дибез. Ләкин күп нәрсә әлегә сүздә генә. Мәсәлән, XIX Бөтенсоюз партия конференциясендә байтак кына файдалы, кызыклы фикерләр әйтелде, резолюцияләрдә чагылыш тапты. Ләкин күп нәрсә тормышка ашырылмый калды.

**— Моны нәрсәне күздә тотып әйтәсез?**

— Шул ук партия һәм совет органнарының функцияләрен аеруны гына алыйк. Бөтен властьны Советларга дип күпме сөйлибез, ә нинди үзгәреш бар? Иң элек Советларга экономик рычагларны бирми торып, ул бөтен властьны үз кулына ала алмаячак. Бу проблемаларга КПССның XXVIII съездында ачыклык кертелер, дип уйлыйм. Шунысын да әйтергә телим, монда башлангыч партоешмалар зур роль уйнарга тиеш. Аларга югары партия органнары эшенә йогынты ясый алырлык шартлар тудырырга кирәк.

**— Платформа проектында башлангыч оешмаларның хокукларын киңәйтү турында әйтелә. Без, башлангыч оешмалар — партиянең нигезе, дибез. Әмма ул нигез бик нык түгел бит әле.**

— Без аларга мөстәкыйльлек бирергә омтылабыз. Ләкин гел без уйлаганча гына килеп чыкмый. Идеология активы җыелышында шундыйрак фикер әйтелде: башлангыч оешмаларда әлләни үзгәреш сизелми. Дөрес әйтәләр. Башлангыч партоешмаларга җибәрелә торган язу-сызу кимесә дә, алар әле аппарат житәкчелегендә [illegible] ли. Кайберләре үзләренең активлыкларын арттырдылар. Әмма бу активлык оешма эшендә ничек чагыла? Платформа проекты буенча фикер алышу вакытында коммунистлар үз фикерләрен ачыктан-ачык белдерделәр. Мәсәлән, ни өчен взносларның күбрәк өлеше башлангыч оешмаларда калмый. Узган ел өч проценты калды калуын. Ләкин взносларның яртысын калдыру турында сүз бара. Югыйсә, күргәзмә агитация өчен дә партоешма секретаре колхоз председателенә яки совхоз директо[illegible]

Без кадрлар сайлап алуда башлангыч партоешмаларга тулы мөмкинлек бирдек. Алар фикерен исәпкә алып эш итәбез. Мәсәлән, «Байрак» колхозына председатель итеп колхозчылар үзләре Илшат Равилевны сайлап куйдылар. «Таң» колхозы партия оешмасы секретарен коммунистлар ике кандидатура арасыннан сайлап алдылар.

**— Сез, Вагыйз Васыйлович, башлангыч оешмаларга партиягә алуда мөстәкыйль эш итү, үзләренә инициатива бирү турында сөйләдегез. Ә КПССтан чыгуга ничек карыйсыз?**

— Монда да төрле фикерләр бар. Мин үзем шулай уйлыйм. Теләгән кешеләр чыксын. Нигә андыйларны партиядә көчләп тотарга? Безнең район партия оешмасында да үз ихтыярлары белән партиядән чыгучылар булды. Инде икенче күзлектән якын килик. Арча поселогыннан пенсионерлар Г. Миннебаева, З. Ногманова гариза язып КПССтан чыктылар. Алар башта Уставны боздылар: взнос түләмәделәр, җыелышка йөрмәделәр. Ә башлангыч оешма андыйларны үгетләп йөрергә тиеш түгел. Үзләре гариза язганчы чыгарырга кирәк.

Чыннан да, без, башлангыч партоешмалар — партиянең нигезе, дибез. Бу положение искерде, дигән фикердә торучылар да бар. Тулаем партия үзе яңара икән, аның түбәнге оешмалары да, аларның эш алымнары да үзгәрә. Властьны Советларга бирү унаеннан, башлангыч оешмалар эшчәнлегендә политик методлар өстенлек алачак. Әмма ничек кенә булса да, бөтен нәрсә башлангыч партия оешмаларында хәл ителә. Алар үзгәрә икән, бөтен партиядә үзгәреш булачак.

Төп эшеннән азат ителмәгән секретарьларга түләү мәсьәләсен дә уңай хәл итәргә вакыт. Нинди генә тырыш, намуслы секретарь булмасын, ул төп эшенә зыян китереп, җәмәгать эшен тиешенчә алып бара алмый.

**— Хәзер партия хезмәткәрләренә өстенлекләрне бетерү турында сөйлиләр. Аларның эш хакын күтәрү дә халыкта ризасызлык тудырды.**

— Партия органнарында эшләү хәзерге шартларда бик авыр. Безнең хезмәткәрләр бернинди өстенлекләрдән файдаланмыйлар. Эш хакына килгәндә, бер партия хезмәткәрләренә генә түгел, гомумән, күп кенә башка тармакларда да ул артты. Ләкин партия комитетларында эш хакын арттыру, минемчә, иртәрәк булды.

**— Демократик централизм турында нәрсә әйтә аласыз?**

— Платформа проектында демократик централизм принцибы турында әйтелә. Без Уставтагыча калдыру ягында түгел. Әлеге хәлендә ул команда-административлык методын хәтерләтә. Аңа демократик рух бирергә кирәк. Бөтенләй алып ташлар[illegible]

[illegible] үз өстебезгә шулай бәхетсез-лек булып төшсен әле!

Татарстанда тәкъдим ителгән үзидарә һәм үзфинанслау механизмы нормативтан тыш табышны һәм товарларны үз республикабызда калдыру мөмкинлеген күздә тота, ә менә нормаларны — дәүләт **заказларын** һәм лимитларны — тулысынча югары инстанцияләр билгели. Башкача әйткәндә, РСФСР безгә план күрсәткечләрен үз ихтыяры белән арттыра ала. Кайда монда үзидарә? Кайда монда халыкларның хокуклары! Юк алар!

**ТАССР бюджеты** РСФСР [illegible] өстәвенә, бу елга ул 48 миллион сум дефицит белән билгеләнде. Ә бит без илгә 2,5 миллиард табыш китерәбез. Эш хакыбыз да, бурычларыбыз да менә шушы дефицит белән бәйләнгән ләбаса. Нинди гөнаһлары өчен Татарстан халкы Россия алдында мәңгелек бурычлы соң? Кайда монда үзфинанслау? Юк ул. Татарстанның РСФСР белән мөнәсәбәтләрен «вассал» (бәйлелек) мөнәсәбәтләр дип кенә әйтергә мөмкин.

Безнең экономик һәм социаль проблемаларыбызны бары тик бер шарт үтәлгәндә генә — республиканың политик статусын үзгәрткәндә генә хәл итәргә мөмкин. Хәзер республика статусы турындагы мәсьәлә гомумиләштерелгән лозунг булып түгел, ә Татарстанның мөстәкыйльлеген киңәйтү һәм ССР Союзы чикләрендә аның договор мөнәсәбәтләренә күчүе буенча байтак практик адымнар булып килеп баса.

Без балаларыбызның киләчәге өчен җаваплы. Без республиканың киләчәге өчен җаваплы. Мәскәү үз проблемаларын кайгырта. Үзәк министрлыклар һәм ведомстволар хәзер үзләренең чиксез зур аппетитлары белән трансреспублика монополияләренә әйләнеп беттеләр, предприятиеләрнең, республикалар һәм өлкәләрнең табышын умырып алырга гына торалар. Аларның комсызлыгының чиге юк.

Экономик кризистан чыгу өчен без бары тик үз көчебезгә, үз кулларыбызга гына таяна алабыз. Үз хокукларыбызны тулысынча аңларга һәм үз ихтыярыбызны ачык белдерергә тиешбез. Безнең беренче хокукыбыз — үз җиребезгә **үзебез хуҗа** булу. Татарстан үз җирен һәм табигый ресурсларын үз ихтыяры белән идарә итәргә хаклы. СССР кул куйган халыкара пактларда: «Бер генә халык та берничек хәлдә дә үз карамагында булган яшәү средстволарыннан мәхрүм ителә алмый», — дип язылган. Димәк, җиргә, нефтькә, урман һәм суларга министрлыклар түгел, ә без үзебез хуҗа булырга тиеш. Чынлыкта исә, киресенчә килеп чыга. Министрлыклар җиребезне ТатАЭС, АлАЗ төзү өчен тартып алалар, уңдырышлы җирләребезне су астында калдыралар. Берсен дә бездән сорап-нитеп тормыйлар. Компенсациясе дә юк. Нефть чыгарудан, промышленность предприятиеләре һәм гидроэлектростанцияләр эшләүдән килә торган зыян бары тик ТАССРның үз исәбенә генә каплана. Безгә үзәк министрлыклар сала торган зыянны үз кесәбездән — әйткәнемчә, 48 миллион сум дефицит белән бирелә торган бюджетыбыздан чыгарып түлибез. Менә шу[illegible] хөкүмәтенә вәкаләтләр бирер иде. Безнең кулда союз министрлыкларының республика халкы мәнфәгатьләренә каршы килә торган карарларын туктатып тора ала торган закон булырга тиеш.

Үзәк тарафыннан халыктан тартып алынган тагын бер хокук бар, ул — **хезмәтең өчен тиешенчә алу** хокукы. Без илебезгә бик зур табыш бирәбез. Әмма үзебездә торак, мәктәпләр, больницалар җитмәүдән интегәбез. Китапларны һәм музей хәзинәләрен саклар урыныбыз юк, акыл иләребез читкә китеп бара, фәнни һәм мәдәни потенциал бик нык кимеде. Татарстан республикасының акчасы юк, аның каравы эшләргә, эшләргә һәм тагын бер тапкыр эшләргә хокукы бар. Безгә Татарстанның **бюджет мөстәкыйльлеген һәм налог инициативасы хокукын билгели торган закон кирәк.** Бюджетыбызның Мәскәү чиновниклары башбаштаклыгына түгел, ә үз хезмәтебезгә бәйле булуы кирәк. Шундый законнан башка бездә берниндң үзфинанслау һәм үзидарә булмаячак.

Ниһаять, безгә республиканың **экономик мөстәкыйльлеге** турында закон кирәк. Ул республика экономикасында **структур** үзгәрешләр үткәрергә, промышленностьны кешеләргә йөз белән борырга мөмкинлек бирер иде. Безгә авыл хуҗалыгын, азык, җиңел, җирле промышленностьны, хезмәт күрсәтү сферасын, инфраструктураны үстерү өчен гадәттән тыш чаралар күрергә кирәк. Без Мәскәү аппетитына бәйсез булган эчке куллану базары булдырырга тиешбез.

Югарыда санап кителгән барлык бу законнар республиканың экономик мөстәкыйльлеге базисын тәшкил итә алыр һәм политик суверенитетны киңәйтү юлыннан алга таба ясалган гаять зур адым булыр иде.

Республиканың **политик статусы** үзара бәйләнгән **өч нәрсәдән** тора. Болар — экономик мөстәкыйльлекне, республика гражданнарының абруй-дәрәҗәсен, татар милләтенең үзбилгеләнүен тәэмин итү. Һәр өчесенең уртак тигезләүчесе бар: ул — **республика белән үзәк арасында тигез хокуклы һәм үзара файдалы мөнәсәбәтләр булдыру.** Менә шушы мөнәсәбәтләр договор белән нигезләнгәндә генә экономик мөстәкыйльлек, республика гражданнарының абруй-дәрәҗәсе һәм татар милләтенә ихтирам турында сүз алып барырга мөмкин. Бөтен дөньяга үзенең нәтиҗәлелеген күрсәтә торган нормаль халыкара практика менә шундый. Безнең ахыргы максатыбыз — компетенцияләрне бүлү турында Татарстанның СССР белән договорын төзү.

Кайбер иптәшләр, милләтара низаглардан куркып калып (андыйлар бигрәк тә руслар арасында очрый), гомумән, дәүләтнең милли формаларын кире кага башладылар. Андыйлар хәзер үрнәк итеп АКШны китерәләр. Иң кызыгы шунда, Россиядә **штатлар** төзү идеясе татарлар тарафыннан революциягә кадәр үк тәкъдим ителгән идея бит ул. Ләкин бүген СССРны штатларга бүләргә тәкъдим итүчеләр АКШтагы штатларның хокукларын күз алдына китерә алмыйлардыр, күрәсең. Бездә бер генә союздаш республика да Америка штатларын[illegible] алыштырылачак. Европага күз салыгыз, анда гаять көчле интеграция процесслары бара, ә милли экономикаларның мөстәкыйльлегенә һич тә бозылмый. Экономик мөстәкыйльлек бюрократлык интеграциясе өчен түгел, ә чын интеграция өчен шарт булып хезмәт итә ала. Мәсәлән, хәзер Чаллыдан Балтик буе республикаларына бетон әйберләр ташыйлар. Кемгә файдалы бу? Татарстангамы? Россиягәме? Балтик буенамы? Ул бары тик бюрократиягә файдалы. Татарстанның экономик мөнәсәбәтләре күптән инде гомумсоюз мөнәсәбәтләренә әверелде, чөнки безнең продукциянең 85 проценты гомумсоюз буйсынуындагы предприятиеләрдә җитештерелә. Менә шуңлыктан РСФСР органнары хәзер безнең өчен экономик үсешне тоткарлый торган артык буын гына булып тора.

Федератив мөнәсәбәтләр халыклар арасында **ышаныч** урнаштыруны күздә тота. Бу ышаныч үткәннәргә дә, хәзергегә дә кагылырга тиеш. Үзәк матбугат татарларның тарихи үткәне турында нипләр генә язып бетермәде. Мондый ялган стереотипларны бетерү өчен әле күп еллар кирәк булыр. Кызганычка каршы, үзәк матбугат үз ялгышларын төзәтергә җыенмый да бугай.

Карыйк әле, хәзерге, «яңартылган» Россиядә Татарстанга нәрсә тәкъдим ителә? РСФСРның яңа Конституциясе буенча Милләтләр палатасы булдырыла. Аның 107 нче статьясы нигезендә вәкиллекнең түбәндәге нормасы билгеләнә: һәр автономияле республикадан өчәр кеше, ә калган автономияле берәмлекләрдән берәр депутат. Аның каравы өлкәләр, крайлар, Мәскәү һәм Ленинград шәһәрләре барысы бергә 63 тавыш алалар, бу исә калган барлык автономияле берәмлекләрнекә кадәр. Татарстаннан — өч депутат, ә рус телле Россиядән — 63! Менә сиңа халыклар арасында ышаныч! Әгәр дә инде автономияле берәмлекләрдән сайланган депутатларның яртысына якыны руслар да булса, ул чагында калган башка милләтләр белән чагыштырганда русларның өстенлеге өч тапкыр күбрәк булачак. Мондый ныклык запасы нигә кирәк соң? Мин моны өлкән туган принцибын юридик яктан беркетү генә дип карыйм. Мондый мәгънәсез Конституция булдыру кемгә кирәк булды икән? Мондый Конституция Россия халыклары арасында ышанмаучылык хисе уяту өчен бюрократиягә кирәк булгандыр. Мондый халыклар белән идарә итүе җиңелрәк, югары постта утыруы җиңелрәк. Нәкъ менә бюрократлар бербөтен һәм бүленмәс Россия яклы. Ерак Көнчыгыш республикасы, мөстәкыйль Себер, Урал, Идел буе, суверен Татарстан һәм Башкортстан нәкъ менә шуларны куркыта.

Татарстан ни өчен союздаш республика була алмый соң? Моны бүген нигезле итеп аңлатырга мөмкин түгел. Шуңлыктан каршы як түбәндәге тезисны китереп куя: **«Эгоистлар»** булырга ярамый, башкалар турында уйларга кирәк. Әгәр Татарстан союздаш республика булса, мондый очракта башка автономияле республика[illegible]нан чыгып карыйбыз. Болай ярамый.

Татар культурасы — дөнья культурасының аерылгысыз өлеше, һәм үз республикабызда бара торган процессларга бездә **планетакүләм караш** булырга тиеш. Җир цивилизациясе милли культуралар җирлегендә үсә. Аларны бердәйләштерү — мәдәниятне ярлылануга, [illegible] түгә китерә, ә аларн[illegible] [illegible]ләндерү, киресенч[illegible] тәр[illegible] моннан коткар[illegible] бул[illegible] безне өчен кечк[illegible]ге бар[illegible] кешелек [illegible] әби үзе уйнаган, у[illegible] халык[illegible] [illegible] бары [illegible] [illegible]ратив мөнәсәбәтләр[illegible] [illegible]лаганда без халыкара [illegible] танылган принципларыдан, нормалар һәм договорлардан чыгып эш итәргә тиеш. Шуңлыктан РСФСР Конституциясендә 107 нче статьяның барлыкка килүе, СССР Югары Советының автономияле берәмлекләр белән исәпләшмәве, Россиядә һәм Советлар Союзында татарларны күрмәскә тырышуы бик сәер. Татарларны Россия халкы дип кенә карарга ярамый, татарлар һәм татар мәдәнияте — гомумкешелек культурасының, гомумдөнья цивилизациясенең аерылгысыз өлеше.

Татарстан — ике зур культура: татар һәм рус культурасы үзара янәшә яши торган республика. Политиканы билгеләгәндә шушы факттан чыгып фикер йөртергә кирәк. Тегесе белән дә, монысы белән дә санашмау политиканы уңышсызлыкка китерәчәк. Республикабыз территориясендә яшәүче барлык кешеләр өчен Татарстан — уртак Ватан, һәм безгә экономик мөстәкыйльлекне, политик суверенитетны тормышка ашыру өчен гражданлык килешүе кирәк. Татар иҗтимагый үзәге: «Руслар, Татарстаннан китегез!», — дигән лозунгны гаепли. Безнең хәрәкәткә яла ягарга тырышучы провокаторлар өндәве бу. Моның максаты бер генә — русларны Татар иҗтимагый үзәгенә каршы кую. Без: «Татарларны кыйна — Россияне коткар», — дигән лозунгны да гаеплибез. Монысы да провокаторлар эше. Һәр ике лозунгны бер үк кул яза, күрәсең.

Илебез кыен идеологик кризис кичерә. Коммунизм идеяләренең дәрәҗәсе төште. Әлегә яңа идеалларыбыз юк. Безгә иске догмалардан ваз кичәргә һәм конкрет эшләр белән шөгыльләнергә, республикабызны коткару өчен ашыгыч чаралар программасы кабул итәргә кирәк. Безгә мөстәкыйльлек һәм үз республикабызны үзебез идарә итү өчен чын хокуклар кирәк.

ТАССР Югары Советының яңа составы эшне җир һәм табигый ресурслар турында законнар, республика халыкларының суверен хокуклары, бюджет мөстәкыйльлеге һәм налог инициативасы турында законнар кабул итүдән башларга тиеш. Ләкин тулысынча Югары Советка гына ышанып ятарга да ярамый. Гражданлык инициативасы кирәк. Дәүләт — ул без! Республика — ул без, аның гражданнары! Республиканың киләчәге өчен без җаваплы.

**Рафаэль ХӘКИМОВ.**

[illegible] Үзгәртеп коруның алга бармавында бөтен гаепне партиядән күрәләр. Сүз дә юк, аннан гаепне алып ташларга беркем дә җыенмый. Ә ни өчен без үзенә тапшырылган вазифаны үти алмаган коммунистлардан тиешенчә таләп итмибез. Шул ук вакытта партия аппаратыннан, урындагы партоешмалардан гаеп эзләү гадәткә керде. Без моңа кадәр өстән кушканны үтәп килдек. Шуңа күрә югары оешмалар да үз гаепләрен танырга тиешләр. Әгәр һәр коммунист бар егәрлеген җигеп, намусы [illegible] партия үзенең авангардлык ролен үти алмаячак. Коммунист булып та партияне, теләнә нәрсә килсә, шуны әйтеп, сүгеп йөрүчеләр дә бар бит.

**— Партия аппаратын күбрәк тәнкыйтьлиләр. Ул һаман искечә эшли, дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә. Хәтта партия аппараты кирәкми, диючеләр дә бар.**

— Партияне демократияләштерү шартларында партаппаратны без ничек итеп күрергә телибез? Әмма Платформа проектында бу нәрсә ачык билгеләнмәгән. Гомуми һәм берничә сүз белән генә әйтелгән. Ләкин аппарат кирәк. Ул сайлап куелган партия органына, мәсәлән, райкомга хезмәт итәргә тиеш. Хәзергә киресенчә килеп чыга. Яшерен-батырын түгел, соңгы сүзне бит партия комитеты аппараты әйтә. Аппарат сайлап куелган органга буйсынырга тиеш. Моңа кадәр бу органны форма[illegible] идеология эшенә өстенлек бирергә тиеш. Шул юнәлештә эшебезне үзгәртеп корырга тырышабыз. Бер генә көн дә аппарат хезмәткәрләренең башлангыч оешмаларда, хезмәт коллективларында булмый калганы юк. Монда эшнең яңа формалары таләп ителә. Без терлекчеләр, механизаторлар белән очрашуларны җайга салып җибәрдек. Шундый ук очрашулар интеллигенция, ветераннар белән дә уза. Мәсәлән, «Мәктәп көне» үтк[illegible]дек. Анда райком һәм [illegible] бюро членнары, ата-а[illegible]лар катнашты. Ачык [illegible]ресләрдә булдык. Уку-укы[illegible] проблемалары турында сөйләштек. Сүз дә юк, проблемалар күп. Әмма аларның мөмкин булганнарын вакытында хәл итәргә тырышырга кирәк.

Безне урынлы тәнкыйтьлиләр. Идеология активы киңәшмәсендә милли аяк киемнәре җитештерү берләшмәсе партия оешмасы секретаре Розалия Шәяхмәтова болай диде: «Соңгы вакытта идеология фронтында сүлпәнлек сизелә. Бердәм политкөннәрне дә үткәрми башладык». Яңа Кенәрдә булган чагында халык сәүдә, көнкүреш, транспорт эшенә кагылышлы сораулар бирделәр. Ни өчен газ кертмисез? — диделәр.

**— Болар бит — совет, хуҗалык органнары эше. Райком газ кертеп йөрергә тиешме?**

— Властьны Советларга бирергә, дип әйтәбез әйтүен, тик алар моңа әзер түгел әле. Элеккеге гадәт буенча юк кына нәрсәне хәл итәргә дә райкомга киләләр. Әмма ничек кенә булмасын, пар[illegible] [illegible] ясый алырлык шартлар тудырырга кирәк.

**— Платформа проектында башлангыч оешмаларның хокукларын киңәйтү турында әйтелә. Без, башлангыч оешмалар — партиянең нигезе, дибез. Әмма ул нигез бик нык түгел бит әле.**

— Без аларга мөстәкыйльлек бирергә омтылабыз. Ләкин гел без уйлаганча гына килеп чыкмый. Идеология активы җыелышында шундыйрак фикер әйтелде: башлангыч оешмаларда әлләни үзгәреш сизелми. Дөрес әйтәләр. Башлангыч партоешмаларга җибәрелә торган язу-сызу кимесә дә, алар әле аппарат җитәкчелегендә эшли. Кайберләре үзләренең активлыкларын арттырдылар. Әмма бу активлык оешма эшендә ничек чагыла? Платформа проекты буенча фикер алышу вакытында коммунистлар үз фикерләрен ачыктан-ачык белдерделәр. Мәсәлән, ни өчен взносларның күбрәк өлеше башлангыч оешмаларда калмый. Узган ел өч проценты калды калуын. Ләкин взносларның яртысын калдыру турында сүз бара. Югыйсә, күргәзмә агитация өчен дә партоешма секретаре колхоз председателенә яки совхоз директорына ялынырга тиеш. Секретарь тагын җитәкчегә бәйле булып чыга. Коммунистлар партиягә алу турында да сүз кузгаттылар. Әлегә кадәр интеллегенциянең иң яхшы вәкилләре керми калды. Эшче, колхозчы булсын, дидек. Шуның нәтиҗәсендә әйбәт кадрларны югалттык. Башлангыч оешма партиягә кемне алу мәсьәләсен үзе хәл итсен.

[illegible] хәл ителә. Алар тагәрә икән, бөтен партиядә үзгәреш булачак.

Төп эшеннән азат ителмәгән секретарьларга түләү мәсьәләсен дә уңай хәл итәргә вакыт. Нинди генә тырыш, намуслы секретарь булмасын, ул төп эшенә зыян китереп, җәмәгать эшен тиешенчә алып бара алмый.

**— Хәзер партия хезмәткәрләренә өстенлекләрне бетерү турында сөйлиләр. Аларның эш хакын күтәрү дә халыкта ризасызлык тудырды.**

— Партия органнарында эшләү хәзерге шартларда бик авыр. Безнең хезмәткәрләр берниндн өстенлекләрдән файдаланмыйлар. Эш хакына килгәндә, бер партия хезмәткәрләренә генә түгел, гомумән, күп кенә башка тармакларда да ул артты. Ләкин партия комитетларында эш хакын арттыру, минемчә, иртәрәк булды.

**— Демократик централизм турында нәрсә әйтә аласыз?**

— Платформа проектында демократик централизм принцибы турында әйтелә. Без Уставтагыча калдыру ягында түгел. Әлеге хәлендә ул команда-администраторлык методын хәтерләтә. Аңа демократик рух бирергә кирәк. Бөтенләй алып ташларга да ярамый. Партиянең урындагы оешмалары аның политикасын тормышка ашыралар. Димәк, партия үзенең түбәнге буыннарына җитәкчелекне көчәйтергә тиеш. Хәзер күп нәрсә партиянең абруен күтәрүгә бәйле. Вакыт көтми. Аның кадерен белеп, һәр минутын файдалы эшкә җигәргә кирәк.

Әңгәмәне **М. АБДУЛЛИН** алып барды.

РЕПЛИКА

## СУГЫШ ИНВАЛИДЫН САЙЛАТМАДЫЛАР

Минем тормыш иптәшем II группа сугыш инвалиды. Ул 43 нче елдан бирле аяксыз. Башка төрле чирләре дә бар аның. Кыш көне өйдән бөтенләй чыкмый дип әйтергә була. Сайлау көнне 114 нче мәктәпкә минем өчен дә сайларсың дип, паспортын биреп кертте. Үзем сайлаганда әйтеп карадым: «Ул керә алмый, авырый, үзем генә сайлап чыгыйм әле», — дидем. Сайлау комиссиясе членнары каршы килде. «Кеше өчен сайларга ярамый, үзебез өегезгә ящик белән барырбыз», диделәр. Инвалид, авыру кеше кичке сәгать 10 га кадәр көтеп утырды. Аның янына килеп сайлатучы булмады. Ул шулай итеп, үзенең тавыш бирәсе кешесенә — инвалидлар советы рәисенә тавыш бирүдән мәхрүм булды.

Сайлауда гына түгел, башка җирләргә барсаң да шундый салкын карыйлар аларга. Сугыш беткәнгә 45 ел тула. Алар хәзер санаулы гына калып баралар. Шулай булса да, алар өчен бик кайгыртмыйлар, дип әйтеп булмый. Инвалидларның йөри алганнары күп. Алар үз кирәкләрен үзләре юллап йөри, өйләренә телефоннар да керттерәләр. Аяксыз, кулсыз, сугыштан инвалид булып кайткан кешеләрне күбрәк карарга кирәктер дип уйлыйм. Телефон станциясенә баргач, безгә әле салына да башламаган станция әзер булгач, кертәбез дип вәгъдә итәләр.

**И. ГЫЙБАДУЛЛИНА.**
Казан.

## МУЛ САВЫМ АЛУЧЫЛАР

Рәсемдә «Һәр сыердан уртача савымны быел 4000 килограммга якынайтырга!» дигән максат куеп эшләүче алдынгылар белән танышасыз. Алар барысы да Түбән Кама районының «Кызыл Зәй» совхозыннан.

Астагы рәсемдә: звено җитәкчесе Зоя Петрова. Ул сыер савучы булып 21 ел эшли инде. Ире Михаил да — фермада терлекче. Тормышлары матур, өч бала үстерәләр.

Өстәге рәсемдә (сулдан уңга): мул савым осталары Сәвирә Садыйкова, Анна Павлова, Бәнат Ахунова, Халисә Мифтахова, Зоя Дмитриева һәм Тоня Порфенова.

М. Шакирҗанов фотолары.

# Әлки

№ 43 (1593)

«СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» КУШЫМТАСЫ

Әдәбият • Сәнгать • Культура • Тел • Тарих


Моннан 85 ел чамасы элек, 1905 елның 13 ноябрендә, В. И. Ленинның «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» дигән мәкаләсе дөнья күрде. Пролетариат юлбашчысы анда марксистик эстетиканың нигез ташын тәшкил иткән ике мәсьәләне — әдәбиятта, сәнгатьтә партиялелек һәм язучының, сәнгать эшлеклеләренең иҗат иреге мәсьәләләрен күтәрде. Анда, аерым алганда, мондый юллар бар:

«Әдәбият эше гомуми пролетар эшенең бер өлеше булырга, бөтен эшчеләр сыйныфының бөтен аңлы авангарды тарафыннан хәрәкәткә китерелүче бер бердәм, бөек социал-демократик механизмның «тәгәрмәче һәм винтигы» булырга тиеш. Әдәбият эше оешкан, планлы, берләшкән социал-демократик партия эшенең состав өлеше булырга тиеш».

«Социалистик пролетариат партияле әдәбият принцибын алга сөрергә, бу принципны үстерергә һәм аны мөмкин кадәр тулырак һәм бөтенрәк формада тормышка ашырырга тиеш».

«Бәхәс юк, бу эштә (әдәбият эшендә — ред.) шәхси инициативага, индивидуаль һәвәслекләргә күбрәк иркенлек, фикергә һәм фантазиягә, формага һәм эчтәлеккә иркенлек тәэмин итү һичшиксез кирәк. Болар бар да бәхәссез, ләкин болар да тик шуны гына исбат итәләр ки, пролетариатның партия эшенең әдәбият өлеше пролетариатның партия эшенең башка өлешләре белән шаблонлы рәвештә тиңләштерелә алмый».

«Әдәбиятчылар партия оешмаларына, әлбәттә, керергә тиешләр. Нәшриятлар һәм складлар, кибетләр һәм уку заллары, китапханәләр һәм төрле китап сәүдәләре — болар барысы да партиянеке булып, аңа отчет бирергә тиешләр».

«Җәмгыятьтә яшәп тә, җәмгыятьтән азат булу мөмкин түгел».

## НӘРСӘ УЛ ПАРТИЯЛЕ ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ИҖАТ ИРЕГЕ?

Диктаторлык власте хөкем сөргән һәм аннан соңгы торгынлык елларында В. И. Ленинның күп идеяләре, фикерләре еш кына ялгыш, бөтенләй бозылып аңлатылды, хәтта кайчакларда мәкерле ниятләрне тормышка ашыру өчен корал итеп файдаланылды.

Илебездә башланган үзгәртеп кору, демократия, хәбәрдарлык уңаеннан, «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе республикабыз язучыларына, галимнәренә, сәнгать эшлеклеләренә, киң катлау укучыларга түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итә:

**1. В. И. Ленинның «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» дигән хезмәтендәге идея һәм фикерләрне тормышка ашыруда нинди тайпылышлар булды?**

**2. Бүгенге көндә партия белән әдәбият-сәнгать арасындагы мөнәсәбәтләрне ничегрәк күз алдына китерәсез, үз иҗатыгызга аның тәэсирен ничек тоясыз?**

**3. «Иҗат иреге», сезнеңчә, нәрсә ул? Безнең җәмгыятьтә иркле иҗат итүгә комачаулаучы нинди киртәләрне җимерергә кирәк?**

## АКЫЛ ҺӘМ КҮҢЕЛ КУШКАНЧА

1. Аерым шәхес һәм төркемнәр тарафыннан Октябрь социалистик революциясенең кирәклегә үк инкарь ителгән, марксизм һәм ленинизмга һөҗүмнәр башланган бер заманда бу сорауга ерактанрак килеп җавап бирмичә булмый.

В. И. Ленинның мәкаләсендә үткәрелгән төп идея дөрес идеме һәм бу мәкалә үзен акладымы?

Дөрес иде, чөнки башлыча эшчеләр сыйныфының мәнфәгатен күзәтеп мәйданга килгән РСДРП(б)ның якындагы бурычы самодержавиене аударуга юнәлтелгән көрәштә авангардлык итү иде. Моның өчен ул, йомарланган йодрыктай, бердәм һәм бербөтен булырга, аңа хезмәт итә торган матбугат һәм әдәбият партиянең олы максатына, **тик шуңа гына** хезмәт итәргә, ягъни партияле булырга, партиялелек принцибын үткәрергә тиеш иде.

Мәкалә үзен аклады, дип ышанам, чөнки мин, марксизм-ленинизм тәгълиматын дөрес дип табу белән бергә, Октябрь котылгысыз һәм кирәк иде, дигән карашта торам. Революцион матбугат партиялелек принцибына корылмаган булса, Февраль һәм Октябрь революцияләре, белмим, шулай җиңел һәм аз кан белән узарлар иде микән? Бу матбугат партияле булу өстенә, Советлар власте либераль һәм вак буржуаз газета-журналларны чикләмәсә («Каледин бомбаларына ялганлау бомбалары өсти алмыйбыз» — В. И. Ленин), гражданнар сугышының ничек тәгәлләнәсен кистереп әйтеп булмый.

Тайпылышлар? Һай шулай гына булган булсачы! Сүздә, матбугат битләрендә һәм вуз аудиторияләрендә партиялелек принцибы, әлбәттә, нигездә дөрес аңлатылды. Ә эштә? Бөтен власть үзәк партия аппараты, тагын да төгәлрәге, бер кеше кулына күчеп, хата артыннан хата, җинаять артыннан җинаять эшләнә, илнең үткәне һәм хәзергесе ялган призмасы аркылы күрсәтелә башлагач, В. И. Ленин алга сөргән партияле әдәбият принцибыннан күп нәрсә калмады. Ул талантлы һәм үзфикерле әдип һәм сәнгатькәрләрнең башына төшә торган күсәк итеп кулланыла башлады. Соңгы вакытларга кадәр бу принцип партия аппаратында утыручы чиновникның мактавы яисә хурлавы, хуплавы яисә тыюы рәвешендәрәк аңлашылып килде.

2. Бу сорауга да туп-туры итеп җавап биреп булмый. Чөнки, барыннан да элек, партиянең үзен үзгәртеп корасы бар. Ул, карьерист, чиновник, карак, эчкече һәм бүтән төр икейөзле кешеләрдән тора торган балласттан котылып һәм асыл мәгънәсендәге **демократик** централизм принципларына нигезләнеп, чын социализм, гуманлы социализм төзергә керешкән халыкның авангардына әверелергә тиеш. Шуннан соң ленинчыл партиялелек идеясе мөһим бер корал булып кабат әйләнеп кайтыр. Аның кирәклеге тагын бер нәрсәгә бәйләнгән. Бүген баш калкыта башлаган һәм партиягә әверелеп бара торган политик төркемнәр дә соңгы вакытта партияле карашлар үткәрә башладылар. Шулар янында **коммунистик** партиялелек гыйльми нигездән үсеп чыкканлыгы, дөреслек һәм объективлык югары ноктасы булуы белән аерылып торырга тиеш.

Тәэсиргә килсәк, партком, райком, горкомнардан гаепсез килеш алган каты шелтәләрдән башка, файдалы тәэсир татыганым юк. Үземне Коммунистлар партиясе әгъзасы итеп хәл кылу исә миндә җаваплылык һәм намуслылык тойгыларын һәрдаим куәтләндереп торды. Иҗат эшендә болар ифрат кирәк.

3. Иҗат иреге ул — кемнәргәдер ярашырга тырышудан, акча һәм шөһрәт артыннан куудан, карьерага омтылудан азат булып, илкөн алдында, халык каршында җаваплылык хис иткән хәлдә, үзең белгәнчә, акыл һәм күңелең кушканча иҗат итү. Комачаулаучы киртәләр? Юк алар бүген! Хәтта бакчабызга кереп, борыны белән җирне казып, агач-куак һәм чәчәк-гөлләребезне корытучылар каршыннан да киртәләр алып ташланды. Митинг-җыелышларда «Долой партия!» дип кычкырулар, яһүдләргә каршы погромга чакырулар яисә Николай Романов гаиләсен аяк өсте басып яд итүләр гадәти хәлгә әверелде. Кайбер газета һәм журнал сәхифәләреннән марксизмны, Ленинны, Октябрьне дегеткә буяган мәкаләләр укыйбыз, ачык итеп әйтелмәсә дә, реставрациягә чакыру авазларын ишетәбез. Кинонлы, күргәзмәләрне, күп кенә журнал һәм газеталарны порнография басып китте.

Теләсә нинди демократик илнең конституция һәм законнарында уголовный җинаять саналган күренешләр — иҗтимагый стройны җимерергә чакыру, милләтләрне сугыштырырга маташу һәм порнография тарату фикер һәм иҗат иреге сылтавы астында тиешле бәясен алмый тора.

Фикер һәм иҗат [illegible] яклау белән бергә, [illegible]ның: «Җәмгыятьтә яшәп тә, җәмгыятьтән азат булу мөмкин түгел», — дигән сүзләренә чын күңелемнән кушылуымны белдерәсем килә.

**Ибраһим НУРУЛЛИН,**
филология фәннәре докторы, профессор.

Гамил АФЗАЛ

## Җир-су кайгысы

### (Эшче белән крестьян диалогы)

Налог түли-түли ил яшәде,
Утыртканы үстә бакчада.
Авыл өчен берни эшләмәде
Ак патша да, кызыл патша да.

...Мужикны кыс, дигән иде Бабай,
Эшләсен дә куйсын табынга!
Мужик хәзер юаш түгел алай,
Башы эшли икән аның да.
Кәгазьдә ул политика зирәк,
Уйланасың тыныч кичләрдә:
Ә халыкны туйдырырга кирәк,
Азык-төлек җитми, нишләргә?

— Бар агай, кит, авылыңа сыпыр,
Автобуслар йөри, юл такыр.
Анда сиңа саф һавалы хутор,
Сандугачлар сайрап уятыр.
Анда сиңа тал яфраклы иртә,
Елгасында сикерә чабаклар.
Бу шәһәрдә синнән ипи китә
Культуралы тәмлетамаклар.
Бар, агай кит, колхозыңа сыпыр,
Йөрмә шәһәрдә таптанып.
Икмәк өчен сиңа рәхмәт укыр
Кәгазь язып торган бар халык.
Анда сине яшел урман көтә,
Романтика тулы басулар,
Йолдызлы кич, сандугачлы иртә,
Һәм хуҗасыз калган җир-сулар.
Анда рәхәт, юллар туры сиңа,
Кызыл вымпел тотып барырсың,

Басу баһадиры булырсың да,
Почет грамотасы алырсың...

Агай әйтә: — Сез оста сөйлисез,
Мин баһадир, имеш, киң күкрәк,
Грамота, кызыл вымпел, дисез,
Нигә кирәк миңа ул чүпрәк!
Сезгә җайлы, өстән бурыч төшкәч,
Менә түрең, әнә бусага.
Крестьян да ахмак түгел, иптәш,
Чүт-чүт кенә надан булса да.
Өйрәтәләр, вәкилләр бик ишле,
Портфель тотып карап торырга.
Мин бит мең ел иген иккән кеше,
Кайчан чәчеп, кайчан урырга
белмиммени!
Белмәгәнгә күрә,
Кукуруз чәч, дисез хәзер сез.
Нигә кирәк миңа кырык түрә,
Нигә бездә мужик кадерсез!

— Тукта әле, кызып китмә алай,
Эшче сыйныф та бик тырышты,
Эшче бирер сиңа шифер, калай,
Терелтергә кирәк тормышны.
Җир бирәләр әнә,
йөз гектар ал,
Бояр кебек яшә җиреңдә,
Без тырышсак кына булыр ул мал,
Ленин бабай торсын түреңдә.
Социалистик ярыш ачып җибәр,
Утырт суган, кишер, кәбестә.

— Рәхмәт, туган!
Ышанам мин сиңа,
Без дә эшләмәсәк, кем эшләр!
Иркен сулап алга барыр дөнья,
Гөлләр үсәр, пешәр җимешләр...

## Ирек яулаганда

Бунтарь идек, Ирек яулап йөрдек,
Тулы Ирек булсын инсанга!
Көлеп торсын бәйсезлек тә хөрлек,
Ни сөйләсәң, ниләр кылсаң да!

Ни теләсәк, шуны эшләп йөрик,
Сандугачтай шагыйрь җырласын,
Булсын безгә хәбәрдарлык, Ирек,
Безне беркем тыеп тормасын!

Кыю басып, оҗмахларга керик,
«Ярамый» дигән сүз булмасын!
Һәр фикерне шигъри гөлгә төрик,
Җир җәннәте итик дөньясын!

Менә Ирек килде, чып-чын Ирек,
Сөенегез, дуслар иркендә!
Ирек тотып, гөлбостанга кердек,
Ни эшләргә — белми беркем дә.

Юк, егетләр, безгә түрә кирәк,
Аяк тибеп безгә кычкырсын,
Премия язсын сирәк-мирәк,
Ярыш оештырсын, эш кырсын!

Өйрәнгәнбез алай-болай итеп,
Язын чәчеп, көзен урырга,
Шелтәләр һәм күрсәтмәләр көтеп,
Алдашып һәм куркып торырга...

## Сүз диңгезе

Әллә ничек үтеп китте яшьлек,
Гаҗәпләнеп карап торабыз.
Гомер буе матур сүзләр чәчтек,
Хәзер менә сүзләр урабыз.

Газет-журнал тулы сүз диңгезе,
Телевизор тулы сүз генә.
Ничек түзәр инде Заман күзе,
Сүз диңгезен ишеп йөз генә!

Дөнья кайный, талаш-ызгыш бара,
Хокук, власть кирәк һәркемгә.
Юмарт булып, власть биреп кара
Демагоглар дигән артельгә!

Һәр итәкнең хан буласы килә,
Баш буласы килә дөньяга.
Тал-тирәкләр гөжли искән җилгә,
Ярдан-ярга тулып су ага...

## Аптырашта

Әмма батырлар күбәя,
Хәвефле еллар үткәч.
Үлгән арсланга тибү —
Егетлек түгел, иптәш.

Син дә батыр, мин дә батыр,
Ә элек куян идек.
Шөкер әле, баш исән, дип,
Елмаеп куйган идек.

Күрсәтмә көтеп утыру
Безнең бу җанга сеңгән.
Күләгәдә посып тору —
Кадерле һәммәсеннән.

Тик утырып алла бирмәс,
Селкенеп карыйк әле.
Барыр юлны белер-белмәс
Булса да, барыйк әле...

## Җан тынычлыгы

Якыннарга шыпырт кына явызлык эшләп торып,
Туң йөрәк — түрә алдында телеңне тешләп торып,

Җан тынычлыгы телисең тавышсыз-гаугасыз бер,
Лаеклы ялга чыгасың, дачага аласың җир.

Тәкерәп политикага, шау-шулы урамнарга,
Дачада ятасың килә, су сибеп суганнарга.

Синнән дә акыллылар бар, синнән дә акыллылар,

Онытылмаска тиешле җырлар

## БЕР СӘЯХӘТ КӨНДӘЛЕГЕ

сы гына килеп чыкты. Туйдан соң берничә көн үткәч, мин аларны клубка чакыр-

алга сөрергә, бу принципны үстерергә һәм аны мөмкин кадәр тулырак һәм бөтенрәк формада тормышка ашырырга тиеш».

«Бәхәс юк, бу эштә (әдәбият эшендә — ред.) шәхси инициативага, индивидуаль һәвәслекләргә күбрәк иркенлек, фикергә һәм фантазиягә, формага һәм эчтәлеккә иркенлек тәэмин итү һичшиксез кирәк. Болар бар да

ныйлды.

Илебездә башланган үзгәртеп кору, демократия, хәбәрдарлык уңаеннан, «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе республикабыз язучыларына, галимнәренә, сәнгать эшлеклеләренә, киң катлау укучыларга түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итә:

**1. В. И. Ленинның «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» дигән хезмәтендәге идея һәм фикерләрне тормышка ашыруда нинди тайпылышлар булды?**

**2. Бүгенге көндә партия белән әдәбият-сәнгать арасындагы мөнәсәбәтләрне ничегрәк күз алдына китерәсез, үз иҗатыгызга аның тәэсирен ничек тоясыз?**

**3. «Иҗат иреге», сезнеңчә, нәрсә ул? Безнең җәмгыятьтә иркле иҗат итүгә комачаулаучы нинди киртәләрне җимерергә кирәк?**

сизм-ленинизм тәгълиматын дөрес дип табу белән бергә, Октябрь котылгысыз һәм кирәк иде, дигән караштa торам. Революцион матбугат партиялелек принцибына корылмаган булса, Февраль һәм Октябрь революцияләре, белмим, шулай җиңел һәм аз кан белән узарлар иде микән? Бу матбугат партияле булу өстенә, Советлар власте либераль һәм вак буржуаз газета-журналларны чикләмәсә («Каледин бомбаларына ялганлау бомбаларын өсти алмыйбыз» — В. И. Ленин), гражданнар сугышының ничек тәгәлләнәсен кистереп әйтеп булмый.

Тайпылышлар? Һай шулай гына булган булсачы! Сүздә, матбугат битләрендә һәм вуз аудиторияләрендә партиялелек принцибы, әлбәттә, нигездә дөрес аңлатылды. Ә

дына әверелергә тиеш. ...нан соң ленинчыл партиялелек идеясе мөһим бер корал булып кабат әйләнеп кайтыр. Аның кирәклеге тагын бер нәрсәгә бәйләнгән. Бүген һәм баш калкыта башлаган һәм партиягә әверелеп бара торган политик төркемнәр дә соңгы вакытта партияле карашлар үткәрә башладылар. Шулар янында коммунистик партиялелек гыйльми нигездән үсеп чыкканлыгы, дөреслек һәм «объективль[illegible] югары ноктасы булуы б[illegible]н аерылып торырга тиеш.

Тәэсиргә килсәк, партком, райком, горкомнардан гаепсез килеш алган каты шелтәләрдән башка, файдалы тәэсир татыганым юк. Үземне Коммунистлар партиясе әгъзасы итеп хәл кылу исә мин-

газеталарны порнографиягә басып китте.

Теләсә нинди демократик илнең конституция һәм законнарында уголовный җинаять саналган күренешләр — иҗтимагый стройны җимерергә чакыру, милләтләрне сугыштырырга маташу һәм порнография тарату фикер һәм иҗат иреге сылтавы астында тиешле бәясен алмый тора.

Фикер һәм иҗат[illegible] яклау белән бергә, Ленинның: «Җәмгыятьтә яшәп тә, җәмгыятьтән азат булу мөмкин түгел», — дигән сүзләренә чын күңелемнән кушылуымны белдерәсем килә.

**Ибраһим НУРУЛЛИН,**
филология фәннәре докторы, профессор.

Басу баһадиры булырсың да,
Почет грамотасы алырсың...

Агай әйтә: — Сез оста сөйлисез,
Мин баһадир, имеш, киң күкрәк,
Грамота, кызыл вымпел, дисез,
Нигә кирәк миңа ул чүпрәк!
Сезгә җайлы, өстән бурыч төшкәч,
Менә түрең, әнә бусага.
Крестьян да ахмак түгел, иптәш,
Чүт-чүт кенә надан булса да.
Өйрәтәләр, вәкилләр бик ишле,
Портфель тотып карап торырга.
Мин бит мең ел иген иккән кеше,
Кайчан чәчеп, кайчан урырга
Белмиммени!

Белмәгәнгә күрә,
Кукуруз чәч, дисез хәзер сез.
Нигә кирәк миңа кырык түрә,
Нигә бездә мужик кадерсез!

— Тукта әле, кызып китмә алай,
Эшче сыйныф та бик тырышты,
Эшче бирер сиңа шифер, калай,
Терелтергә кирәк тормышны.
Җир бирәләр әнә,
йөз гектар ал,
Бояр кебек яшә җиреңдә,
Без тырышсак кына булыр ул мал,
Ленин бабай торсын түреңдә.
Социалистик ярыш ачып җибәр,
Утырт суган, кишер, кәбестә.
Үзең эшчән, хатының да чибәр,
Бала-чага үстер бер дистә.

Башын чайкый агай: — Шулай, шулай...
Шома политика — карурман,
Андый тәртип сезнең өчен уңай,
Мужикны алдауга корылган.
Хаклык эзләп кайда барып йөрмә,
Түрәләрдән күңел кайтырлык.
Безнең өчен штраф та төрмә,
Ялган геройлык та батырлык...
Колхозларны, совхозларны алыйк,
Чәчәк аткан тормыш күрмәдек.
Уртак малны эт җыймас, ди халык,
Булсын-булсын, диеп йөрмәдек.
Алдым ди мин фәлән чаклы гектар,
Мең пот итеп налог салырлар.
Кайчан бетәр, кайда килеп җитәр
Мужик малын алдап алулар!
Башың булса, чутлап кара юри,
Кая бара Ватан-анабыз!
Үзебезнең икмәк кырда чери,
Алтын биреп читтән алабыз.
Ярый әйдә, алам йөз гектар җир,
Корымасын суы, урманы.
Машина бир миңа, права бир,
Яңартырга кирәк дөньяны...

...тау —
Егетлек түгел, иптәш.

Син дә батыр, мин дә батыр,
Ә элек куян идек.
Шөкер әле, баш исән, дип,
Елмаеп куйган идек.

Күрсәтмә көтеп утыру
Безнең бу җанга сеңгән.
Күләгәдә посып тору —
Кадерле һәммәсеннән.

Тик утырып алла бирмәс,
Селкенеп карыйк әле.
Барыр юлны белер-белмәс
Булса да, барыйк әле...

## Җан тынычлыгы

Якыннарга шыпырт кына явызлык эшләп торып,
Туң йөрәк — түрә алдында телеңне тешләп
торып,

Җан тынычлыгы телисең тавышсыз-гаугасыз
бер,
Лаеклы ялга чыгасың, дачага аласың җир.

Төкереп политикага, шау-шулы урамнарга,
Дачада ятасың килә, су сибеп суганнарга.

Синнән дә акыллылар бар, синнән дә
акыллылар,
Җан тынычлыгы кирәкми, гөбертеп
аксын сулар!

Изгелек эшләп кешегә, үкенеп-сызланып бер,
Тәмугның түренә чаклы җиңеңне
сызганып кер!

Көн саен үзгәреп торган дөньяны күзәт әле,
Ялгыш та төзәт хатаңны, ялгыш та төзәт әле!

Йөз кабат җиңеп-җиңелеп, сызланып янсын
йөрәк,
Дөньяны тартып барырга тынгысыз җаннар
кирәк.

Тап-такыр юллар буенча теркелдәп
җайдан гына,
Җан тынычлыгы телидер зиһенсез хайван
гына.

**В. АРШИНОВ** рәсеме.

Онытылмаска тиешле җырлар

# БЕР СӘЯХӘТ КӨНДӘЛЕГЕ

Мәскәүгә чакыру кәгазе алгач, клуб мөдире Лидия Андреевна: «Без анда нәрсә алып барырбыз икән?», дип уйга калды. Югалып калмый мөмкин түгел иде, чөнки Мордва Каратае фольклор ансамбле репертуарында йөз иллегә якын төрле жанрдагы җыр, такмак һәм дистәгә якын төрле күренеш бар. Мәскәүгә барырга ике атна калганда якынча программа әзер иде инде. Аңа озын көйләр, бәйрәм җырлары һәм кыска такмаклар, урам көйләре керде. Репетицияләр уңышлы узды. Шулай итеп, әзер программа белән сәфәр чыгып киттек. Поезд төнге сәгать 11 дә китәргә тиеш иде. Казанда безне республика мәдәният-агарту фәнни-методик үзәге директоры Р. Г. Гыйләҗев һәм әлеге үзәкнең фольклор коллективлары буенча методисты А. П. Шкода каршы алдылар, ә кичен поездга кадәр озаттылар.

Юлда барганда без купеда акрын гына репетиция ясап бардык. Янәшәдәге татар хатыны гаҗәпләнеп: «Үзегез, мордвалар без, дисез ,ә җырларыгызны татарча җырлыйсыз», диде. Анна Сергеевна Лаврухина, елмаеп: «Без Татарстанда яшибез бит, татарча да җырлыйбыз, кирәк икән, русча да», диде һәм шунда ук русча шаян җырлар яңгыратып җибәрде.

Мәскәүдә беренче көнне ансамбль пластинкага яздыру студиясендә эшләде. Яздыру озакка сузылды. Кунакханәгә соң гына, арыпталып кайтып җиттек. Икенче көнне иртәнге сәгать уннан бергә кадәр репетиция ясадык, ә кичен, иң җаваплы эш — РСФСР Композиторлар берлегенең концерт залында чыгышыбыз башланды.

Концертта илебезнең төрле почмакларыннан 9 коллектив — Брянск, Архангельск өлкәләре, Краснодар крае, Мари, Коми, Төньяк Осетия һәм Тува АССРлардан фольклор ансамбльләре катнашты. Әлеге концерт залда утыручыларда зур тәэсир калдырды.

Иртәгесен безнең группаны янадан пластинкага яздыру студиясенә, бу юлы күп каналлы яздыру дип аталганына алып киттеләр. Бу исә халык музыка иҗатын фәнни өйрәнү максатларында эшләнә икән. Эш шунда ки, Мордва Каратае фольклор ансамбле күп тавышка җырлый һәм һәр партия (ягъни һәр тавыш) аерым магнит тасмасына яздырылды.

СССР Союзлар йортының Колонналы залы сәхнәсендә чыгыш ясавыбыз аеруча истә калды. Бу болай булды: кире кайтыр юлга билетларыбыз алынган, поезд сәгать икедә китә. Әмма алдагы көнне кичен, сәгать сигезләр тирәсендә, РСФСР Композиторлар берлегеннән кунакханә номерына Союзлар йортының Колонналы залында РСФСР композиторларының VI съезды утырышы башланачагын һәм ул башланыр алдыннан каратайлылар фольклор ансамбленең чыгыш ясавын үтенүләрен әйтеп шалтыраттылар. Без иртәгә китәбез ич инде, дип караган идем. «Һич тә борчылмагыз, чыгыш ясаганнан соң үзебез вокзалга илтербез», — диделәр. Ризалашырга туры килде. Шулай итеп, безгә вокзал урынына илебезгә даны таралган концерт залына барырга туры килде. Барып җиткәч, тагын бер тапкыр гаҗәпкә калдык: барлык фольклор коллективлары арасыннан тик безне генә чакырганнар икән.

Ни өчен Каратай фольклор ансамбле чыгышы композиторларда шул кадәр кызыксыну уяткан соң? Каратайлылар үзләренең акрын, уйчан лирик җырларын башкарган вакытта, беренче чиратта, бай, күптавышлы бизәкләр белән аралашкан моңнарга сокланасың. Һәр тавышның көе үзенә бер төрле, ә инде аерым тавышларның бергәлектәге яңгырашы аеруча сокландыра. Каратай җырлары (урам, бәйрәм, туй җырлары һәм озын көйләр), рус көйләре, бигрәк тә шаян җырлары белән, охшаш. Шуңа күрә мордва-каратайлылар татар такмакларын кайвакыт рус көйләренә дә җырлыйлар.

Мәскәүдә чыгыш ясап кайткан ансамбльгә Мордва-Каратай авылы клубы мөдире Лидия Андреевна Тонина җитәкчелек итә. Аның улы Вячеслав Андреевич — гармунчы. Анна Сергеевна Лаврухина һәм апалы-сеңелле Екатерина һәм Анна Сергеевна Школькиналар, Анна Андреевна Толчинина, Семен Егорович Пушканов, Андрей Григорьевич Балякаев — җырчылар.

Фольклор ансамбле өчен узган елның ахырында тагын бер истәлекле вакыйга булды: алар үзләренең иҗади-отчет концертларын күрсәткән көннәрдә Татарстан Мәдәният министрлыгы карары белән коллективка халык коллективы дигән мактаулы исем бирелде.

Юлда кайтканда, мин Лидия Андреевнадан ансамбльнең ничек барлыкка килүе турында сорадым.

— Андрей Григорьевич Балякаев кызын кияүгә бирде, — дип сөйли башлады ул. — Мине дә туйга чакырдылар. Шул чакта минем туйда җырлана торган йола җырларын башкаруымны сорадылар. Балякаевларның туганы миңа кушылып җырлый башлады. Ике куплетны без бары тик икәү генә җырладык. Аннан соң Анна Сергеевна һәм Андрей Григорьевич үзе дә кушылды. Ярыйсы гына килеп чыкты. Туйдан соң берничә көн үткәч, мин аларны клубка чакырдым. (Әйтеп киткәнемчә, Лидия Андреевна клуб мөдире булып эшли, быел шунда эшли башлавына 22 ел була). Башта туйда җырлаган җырларны кабатладык. Аннан соң рус һәм татар җырларын җырлап карадык. Әбиләребез һәм бабаларыбыз җырлаган җырларны искә төшердек, аз гына үзгәрешләр белән аларны үз репертуарыбызга керттек. Менә шулай оештык, — дип тәмамлады ул сүзен.

Борынгы җырлар, шулай итеп, яңадан халыкка кайтты. Бу авыл мәдәнияте үсешендә сөенечле адым булса, Мордва-Каратай авылында кирпечтән 100 урынга исәпләнгән яңа клуб төзелә башлавы да шатлыклы хәл. Тик шунысы кызганыч, кайчандыр 600 гә якын кешеле авылда хәзерге вакытта барлыгы 117 кеше генә яши.

Кама Тамагы районының Мордва-Каратай авылында яшәүчеләр, үзләрен мордвалар дип санасалар да, мордва телен якынча да белмиләр, һәм алар үзләренең бу якларга ничек килеп чыгуларын да әйтә алмыйлар. Аларның язулары да, сөйләүләре дә татарча. Хәзерге вакытта үз телен белүчеләр районда гына түгел, бәлки РСФСРда да бик аз калганнар. Бәлки, аларны ныклап өйрәнергә кирәктер? Тагын күпмедер вакыттан алар бөтенләй бетәчәк бит.

**Р. ФӘЙЗРАХМАНОВ,**
Кама Тамагы районы мәдәният бүлеге мөдире.

# МОҢЛЫ ТУГАННАР

Күптән түгел Казан телевидениесе аша керәшен татарларының фольклор концерты күрсәтелде.

Безнең 36 фатирлы подъездда гына да төрле милләт кешеләре: татарлар, руслар, башкортлар, чувашлар, яһүдләр, мордвалар яши, кайберәүләр аралаш милләтле: ире — татар, хатыны — рус, хатыны — чуваш, ире — мари һәм башка интернациональ гаиләләр күп. Бик тату яшибез, керешеп-йөрешеп, хәл белешеп торабыз. 16 фатирда татарлар яши, шулардан өч гаилә керәшен татарлары, алар да аралашып киткән. Мәсәлән, Семен дәдә — керәшен, ә хатыны Мәрзия апа — әле дә үз динен тотучы мөселман карчыгы. Мин үзем дә башкортлардан, ә хатыным мишәр кызы.

Безнең фатирда зур экранлы төсле телевизор булганлыктан, керәшен гаиләләре бу концертны карарга дип безгә керделәр. Дөресен әйтсәм, үзебезнең бу тапшыруны карарга ниятебез юк иде, ләкин күрше хакы... Янәшә генә фатирдагы мишәр гаиләсе дә безгә кушылды, көтелмәгәндә кечкенә генә бер клуб килеп чыкты.

90 минутка сузылган бу тапшыруны барыбыз да сокланып, тын алмыйча карадык. Безгә, моңарчы гел татар сәнгать осталарының концертларын, чыгышларын карап-тыңлап өйрәнгән тамашачыларга, бу концерт һич көтелмәгән яңалык, сюрприз булды. Нигә моңарчы үзенчәлекле гүзәл милли бизәкле, татарларның шактый өлешен тәшкил иткән керәшеннәрнең мондый талантын әлегәчә бездә шулай тулы һәм эчтәлекле итеп күрсәтми килгәннәр? Сөендерде, кайчак көендерде, моңайтты, елатты, шатландырды бу концерт. Менә нинди талантлар бар икән керәшен татарлары арасында!

Татар милләтенең бер өлешен кем көчләп чукындырганын без беләбез бит! Керәшен татарларының бирәдә бер гаебе дә юк, алар моны үзләре теләп, ялварып алмаган. Моңа биш йөз илле ел вакыт үтте. Әмма алар әлегә кадәр үзләренең татар телен, милли гореф-гадәтләрен, милли җырларын, моңнарын саклап киләләр генә түгел, аларны тагын да җанландыралар, баеталар икән. Моңлы, җырлы туганнарыбыз турында бу тапшыруны оештыручыларга чын йөрәктән рәхмәт белдерәбез, һәм бу концерт тагын бер кабатланыр дип өметтә калабыз. Безнең фатирда җыелган тамашачылар исеменнән

**Р. САФАРОВ,**
сугыш һәм хезмәт ветераны.

Казан.

«Спартак» берләшмәсендә эшләүче Райнә ханым Вәлиева үзенең игезәк кызлары белән татарча әлифбаны бик яратып гарәп язуы нигезендә өйрәнәләр.

С. Биктимеров фотосы.

# ТУГАН ҖИРЕНЕҢ БАЛАСЫ ИДЕ...

(Хәсән Сарьянның тууына 60 ел тулу уңаеннан)

1960 елның яз-җәй айлары үтеп китте. Көз җитте.

Хәбәрләшеп торырбыз дип аерылышкан булсак та, ни өчендер Сарьяннан хат-хәбәр күренмәде. Мин инде: «Берәр эшкә урнашкандыр, тынычлангандыр...» — дип уйлый башлаган идем.

Ә ул — Хәсән Сарьян — октябрь аеның янгырлы-юеш бер көнендә хәбәрсез-нисез генә килде дә керде! Радиокомитетка, минем эш бүлмәсенә.

Кочаклашып күрештек. Исәнлек-саулык, хәл-әхвәл сорашу китте.

— Менә, килдем әле... — дип фикерен әзеп кенә әйтеп бетермичә туктап калды Сарьян.

— Килеп, яхшы иткәнсең. Мин үзем дә бирегән күчәргәрәк торам әле, — дидем мин.

— Нишләп? Кая күчәсең?

— Балалар газетасы «Яшь ленинчы» яңадан ачыла. Шунда димлиләр.

— Ала-а-й... Бәлки, миңа да урын табылыр шунда, ә?

— Бәлки... Сөйләшергә кирәк булыр.

Хәсән Сарьянның Казанга килүе шулай булды. Ул ялгызы гына килгән. Уфада сөйләшенгәнчә, танышу-белешү, эш эзләп карау өчен дип килгән иде ул.

Казан ана мәрхәмәтле булды. Озак та үтмәде, Сарьян «Азат хатын» журналы редакциясендә җаваплы секретарь булып эшли башлады.

Килгән айларында берара Сарьян миндә дә кунгалап йөрде. Әмма минем фатир шартлары бик кысынкы чак: өч бүлмәле фатирның ике бүлмәсендә — биш-алты кешелек гаилә, бер бүлмәсендә — без. Шул бер бүлмәдә ирле-хатынлы икебез, яшь бала...

Килеп керер иде дә Сарьян, ике кулы белән ишек яңагына таянып, бусагага басып килеш кенә җыр су[illegible] җибәрер иде:

Илаш еркәйдең ай
кәккүге юк,
Уд Уралкайыма
кайтайым...

Шулай моңлана иде Сарьян... Әлбәттә, җиңел булмагандыр аңа: гаиләсе Уфада калды, үзенең торыр куышы юк...

Аның хатыны Фирүзә ханым Уфаның кинидер бер техникумында укыта иде булса кирәк. Кечкенә Рифкать ул вакытларда кем кулында булгандыр — әйтә алмыйм.

Әмма Хәсән Сарьян җебен тешмәде, югалып калма...

«...Агыйдел!

Бармы безнең чын татар җырларында синнән дә күп җырланган гайре бер елга!..

Әгәр дә мин елына бер синә кайтып, чабатасыз малай чагым кебек, иртә таңда салкын чыклар ярып буйларыңны бер әйләнмәсәм; чык күзедәй ак суыңда сары сагышларымны бер басмасам; бабамнарның сөяге түшәлгән җылы туфрагыңа битем куеп орынмасам — мин үземне башка җирдә, хәтта Казанымда да бу тикле дә нык ватанлы тоймас идем.

И иртәләрең ак томанлы
Ак Иделем!»

Хәсән Сарьян үзенең «Туган як хикәяләре» (1972) исемле китабын «Туган як моңы» дигән нәсер-уйлану белән ачып җибәреп, әнә шулай язган иде. Шунда ук ул: «Мин Агыйдел буйларының искитмәле ямена карап, миңа каләр унике буын элек болгар угланы Гәрәй бабабызның яр-юлдашы, карендәш-якыннары белән Казан йорты Масрадан баш бирмичә чыгып киткән, арлар иле аша ике Идел кичеп, бу җирләрдә торак тапкан чагын гүя үзем күргәндәй күз алдына китерә алам...» дип яза. Шуннан Сарьян, Агыйделгә бәйле рәвештә, үзенең унике буын нәсел-нәсәбенең тарихын сөйләп бирә. Аның һәр чорының тарихына, шул җирләрдә яшәүче башка кавем халыклар язмышына кушып сөйли. Үз уй-хисләрен: «...ярдан ярга тибеп, колындай уйнаклап, Агыйделем ага... И минем туган җирем — унике буын буена сулап туймас сулышым!..» дип тәмамлый Сарьян.

Иә, кайсыбыз тагын үз туган җирләре, үз нәсел-нәсәбе турында моннан да көчле, моннан да хисле итеп әйтеп бирә ала? «...Ярдан ярга тибеп, колындай уйнаклап...» — моны бит болай матур, җанлы итеп шагыйрьләребез[illegible]нең дә бик күбесе яза алмый.

Хәсән Сарьян минем иҗатымның да нәкъ менә шул ягын — үз күңеленә якын булганын тотып алып бик матур мәкалә язган иде. «Туган җиренең шагыйре» дип атала иде ул мәкалә. Аны башта «Социалистик Татарстан»да (1976 ел, 18 апрель), аннары «Уеңны уйдырып сал...» дигән китабында (1977) бастырып чыгарды.

Чын мәгънәсендә җир кешесе иде Сарьян. Табигать баласы иде. Идел буеннан бакча җире алып, шунда казынып-чокынып йөргән көннәре иң бәхетле көннәре булгандыр, ахры. Сарьянның...

Күпме язучылар белән, шул исәптән, рухи якын булган дуслар белән дә, ачылышлы булырга туры килә иде. Өстән тыялар, ә җаваплылыкны син күтәрергә тиеш...

Менә шундый шартларда бик авырлык белән генә басылып чыккан «Уеңны уйдырып сал...» дигән китабына автографын Сарьян:

«Марс дуска —

Бу китап фәкать синең тырышлык аркасында дөнья күрде. Сиңа озын, тигез гомер телим. Иҗади уңышлар сиңа.

Автор Х. Сарьян.
11. 01. 78» —

дип язган да «фәкать» сүзенең астына сызып куйган.

Их, Сарьян дус... Миңа озын гомер теләгәнсең дә бит, үзеңә теләмәдеңме икәнни соң? Китабыңны язып бүләк иткәннән соң нибары сигез ай да ун көн генә яшәргә калган булган икән бит үзеңә...

Әйе, Хәсән Сарьян яшьли китте, уйламаган-көтмәгәндә китеп барды ул. Аңа әле кырык сигез генә яшь иде. Танылган язучы булып өлгереп-пешеп җиткән генә чагы иде. Язасы да язасы иде әле аңа! Бүгенге көннәрне күрәсе, иркенәеп бер иҗат итәсе иде... Өстәлендәге язу машинкасында җөмләсе яртылай өзелеп калган кәгазь битен күргәч, үзебезнең дә йөрәкләр өзелеп төшәрдәй булган иде...

Юкса, таза, тыгыз бәденле кеше иде Сарьян. Физик эшне бик яратты. Менә дигән балта остасы иде. Аның «Әткәм һөнәре» повесте нәкъ менә шул балта остасы булуыннан чыгып язылган да. Аннары Сарьян бик ярдәмчел иде. Бер-бер каккалыйсы-суккалыйсы эшең булдымы, хәзер ялт иттереп эшләп тә бирә.

Менә шулай тыныч-матур гына яши идек әле без. [illegible]ре, Сарьянның бабаларыныкы кебек хикмәте бар иде. Бакчада эшләгәндә башын ул һәрвакыт яулык белән тасмалап, кысып бәйләп йөри иде. Ләкин сәламәтлегеннән бер дә зарланмый иде алай.

1978 елның 21 сентябре көнне Хәсән Сарьян кинәттән генә вафат булды. Без аны берaз сибәләп-пыскаклап торган моңсу көндә җир куенына салдык. Үзе яраткан җир куенына...

Без — сугыш елларының ач-ялангач, ятим бабалары — байтак каләмдәшләребезне шулай яшьли югалттык. Ләбиб Айтуганов, Тәүфикъ Камалиев, Гази Ма...

---

ТАССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясенә кандидатлар

# СӨЕНСЕННӘР ӘЛЕ САБЫЙЛАР

Мәктәпләрдә туган телебезнең тыны беткән чорларда «Туган тел»не Гимн итеп, эчке бер бирешмәү, сагышлы тантана һәм өмет белән җырлый идек. Татар телендә укытучылар һөнәр алыштырырга мәҗбүр елларда ана телебез өзелмәгән соңгы мәктәп — Балалар әдәбияты булды. Фидакарьләр максатка тугры иде — сабый күңеленә шигъри сүз булып кереп калырга, онытылудан сакларга тырыштылар. Шул сирәк сафтагылар арасында, укытучыларча әйтсәк, Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин да бар. Мөгаллим улы... үзе дә укытучы. Сабаклары: телебезгә мәхәббәт, кешелеклелек тәрбияләү. Балалар әдәбиятында Г. Тукай, Б. Рәхмәт, Ә. Фәйзи традицияләрен дәвам итеп, шушы жанрда да үзенчәлеген тапкан талантлы шагыйрь. Форма ягыннан оста һәм кызыклы, эчтәлеге белән мавыктыргыч ачышлары бар.

Бүгенге мең дә берне белүче баланы авызыңа-әсәреңә карату өчен ни сөйләвең, ничек язуың бик мөһим. Шагыйрьне күңелдәш итеп таныйлар икән, хикмәте — әсәрләренең балачакның үзедәй табигый булуында. Күзендә ярату, сүзендә мөлаемлык күрәләр, димәк. Рухи «дефицитка» — ачык колач-ачык күңелгә, үзен аңлаучыга тартыла балалар. Канат астына борын төрткән бәбкә сыман, сабыйлар да җан җылысы эзли...

Р. Миңнуллиндай балачагын онытмаганнар күп түгелдер. Кеше дигән адәм баласы сәер бит ул: иң яхшы хәтерләгәне балачагы аның, «онытканы» да шул — баласы хәлен аңламый башлый, уртак тел табалмый! Сәбәбе — тигезсезлектә, җәмгыятебездә таралган чир — түрә булып, командалык итеп, «акыллы күрсәтмәләр» биреп өйрәтүдәдер? Ата-ана белән бала арасында читләшү дигән «Берлин стенасы» шулай үсә. Шул стена артында аерым утрау булып яшәүче балалар бакчасы, бигрәк рәшәткәле мәктәп, аннары... чәнечкеле коймалы балалар колонияләре... Читләшү еш кына бусына да китерә...

Әле дә, бәхеткә, баланың күңел «телен» аңлаучы «сакаллы сабыйлар» бар. Робертның популярлык сере дә әнә шул балалар белән уртак сыйфатларында — ихласлык, тапкырлык, шаянлыкта. Юмор торгынлык елларында ла рәсмиләнтән тәмам гарык бала күңелен, әдәбиятның сәламәт саклаган хасият булды. Шигырьләрендә олылар дөньясына торгына тоташтырган бик га[illegible] Юмор, сатира — рухи хәрәкәтлек, байсезлек билгесе, демократия юлдашы.

Робертның балаларга әйтер сүзе — китаплары берберартлы чыга тора. Шулардан иң укучылар яратып өлгергән соңгыраклары Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә тәкъдим ителде. Менә алар: «Безнең авыл зоопаркы» (1988), «Җәйнең яшел аты» (1987), «Балачак бәйрәмнәре» (1985). Мәскәүдә, русчага тәрҗемәдә дөнья күргәннәре: «Наш тигренок» (1987, «Малыш» нәшрияты), «Глядит в окошко человек» (1986, «Детская литература» нәшрияты). Бусында Сергей Михалковның кереш сүзе бар: «Күңелсез китапларны, гәрчә алар бик файдалы һәм акыллы булса да, беркем укырга яратмый. Роберт Миңнуллин күңелле һәм кызыклы итеп яза. Бик рәхәтләнеп укыдым...» — дигән атаклы «Степа абый»ның авторы. Робертның шигырьләре илебездә төрле телләргә тәрҗемә ителде. «Детская литература» журналында да яхшы бәя алды. Шунда ук аның иҗат портреты да басылып чыкты.

Югарыда әйтелгән «Балачак бәйрәмнәре»н укыгач, Сибгат ага Хәким дә аны балалар әдәбиятының казанышы дип бәяләде. «Социалистик Татарстан» газетасының 1985 елгы 21 декабрь санында Р. Миңнуллин иҗатын күзәтеп: «...җырларын яратуыма карамастан, башлап аның балалар өчен язылган шигырьләре турында фикер әйтергә булдым», — диде олкән шагыйребез. Балалар әсәрләрен олылар да укуын истә тотып, татар халкында, «бер миллионга бер балалар шагыйре туры килә», — дигән кызыклы чагыштыру әйтте. Сирәк сәләтләргә аеруча игътибар кирәк, дияе иде. Халык шагыйренең «Гөлҗәүһәрнең оныклары» исемле әлеге мәкаләсе милләтебезнең бүгенге һәм туар оныкларын да кайгыртуы иде. «Ә балачак шушындый «Бәйрәмнәр»дән башлана. Мин мондый бәйрәмнәрнең күбрәк булуын теләр идем», — дигән сүзләре соңгы теләге булган икән — вафатына ярты ел гына калган... Шагыйрь урамына бәйрәм килүен күреп әле дә сөенер, хуплау сүзләре табар иде Сибгат ага.

Адәм баласы гомере буе балачак тойгы-тәэсирләре белән «туенып» яши. Әйтик, безгә әнис орлыгының тәме рәхәт болыннарны, печән есе бәйрәмнәрен хәтерләтә. Нәни бөртеккә болын сыйган, болында — балачак! Шул истәлек күңелне имин матурлыкка көйләп, иркәләп тора... Шәһәрдә үскән беләүгә орлыкны бирәм, тәмләп карый да сәерсенеп йөзен чытә... Балачак хәтерендә юк ул аның, болын тулы тәмь юк, сагынырлык тәм [illegible] Бала чакта укылган шигырьләр дә нурланып күңел төбендә ята. Өлкәнәйгәч тә тормыш «тәмләткеч» буларак кирәк алар, әйбәт күңелле булу өчен кирәк. Р. Миңнуллинның шигъри болынында андый хис-әнисләр күп. Халык иҗатының шифалы чәчәкләренә, сүз-хәзинәләренә, күркәм гореф-гадәтләр сабантуйларына тоташкан әсәрләр алар. Авылдамы, шәһәрдәме, шул тәмнәрне татып үскәннәрнең балачак бәйрәмнәре гомергә истә калыр.

Күңелле, тыныч, имин бу-

чыны бергә, мәгънәле гамәлләрнең кызыгын-тәмен белеп калсын бала. Матурлыкны танып, шәфкать-мибербанны тоеп үссен. Хыяллар канатланып, үзенә ышаныч туган, шәхес нигезләнер зур бер дәвер бу. Роберт иҗатында әнә шул эзләнүчән, бер үк вакытта тыныч та, тынгысыз да, хәвефле дә балалар дөньясы. Безнең балалар әдәбияты, бүтәннәргә караганда, тормышка якын булуы, борчыган, җанга тигән мәсьәләләрен күрсәтүе белән көчле. Авторның менә бу шигыренең исеме, белеп торам, сәеррәк тоелыр: «Кечкенә бер авылдагы кечкенә бер башлангыч мәктәптә укучы кечкенә малайлар турындагы моңсу шигырь»... Кечкенә дә кечкенә... ә бит зур проблема! Шигырьнең озын-зур исеме үк шуңа ишарә.

«Беләсезме, ничәү без?
Бөтенебез — бишәү без!
Биш партада — бишебез.
Мәктәптә биш кеше без»,

— ди әлеге «перспективасыз», ягъни киләчәксез авылда укучы бала. Бишәү — бер кул бармаклары гына — сыңар кул... Киләчәксез авыл — «перспективасыз тел» дигәндәй сискәндерә...

Робертның шигырьләре туган телнең гомерен озайта торган чын, саф, халыкчан телдә язылганнар. Сурәтләнгән малайлар-кызлар да шуңа җанлы-җисемледер, шуңа яраттырадыр. Нинди сыгылмалы, тере, канатлы сүзләре очып-уйнап торган телебез бар, дип шөкерана кылып куясың. Рәвешең, рухың, иманың телдә, бабайлар васыяте, яшәү догасы ул... Шагыйрь юктан да кызык таба кебек. Юктан түгел — сүздән таба, сүз эчендәге хикмәтне табарга өйрәтә. Кайчакта шигырь баланың хәйләсез сөйләме сыман. Алданма, Хуҗа Насретдиндай беркатлыга салышкан тиктормасның сынап каравы ул! Балалар шагыйре булып туарга кирәк, дигәнне телгә талант дип тә аңлыйм. Бәхетең шунда. Бәхетсезлегең дә — булмаса, кемгә үпкәлисең... Балалар шигырендәге урынсыз бер сүз дә тегәрмәч астындагы таш сыман шигырь-арбаны аударуы ихтимал...

Р. Миңнуллин сынчы оста турындагы бер шигырендә «тылсымчы» дигәнне «тылсынчы» дип уйната. Сүз белән сын тудыручы буларак аның үзен дә «телсынчы» диярга була.

Шигырьләре җанга ятышлы, җырга ятышлы — композиторлар бик теләп көй язып торалар. Балаларга дигәннәре дә өч-дүрт дистәдән артыктыр. Бүләккә күрсәтелгән китапларда да бар алар. Шунысы кызык, балалардан кайчак өлкәннәр эләктереп ала. Әйтик, «Әни кирәк» җыры шулайрак булды. Хәер, балалар да ап-

рындагы бүтән җырларны бер дә өлкәннәрнеке дип тормыйлар. Әле әти-әниләр белән бергәләп җырлаганнары күпме! Бигрәк әйбәт, уйтойгылары бер дигән сүз, шагыйрь уртак хисләр тапкан. Бу җырлардан япа-ятимнәрнең үзәге ничек өзеләдер дип уйланып каласың...

Тормыш тоташ бәйрәм түгел шул. Кырыслыгын, каршылыкларын да яшерми шагыйрь. Нәкъ менә шуларны җиңү өчен күңел тотрыклыгы кирәк, көчле булып үссеннәр, шыңшып-борешеп яшәрлек булмасыннар, ди. «Мин көрәшергә тиеш!» җырындагы малай шундый:

«Көрәшче булган
бабамнар,
Көрәшче мин үзем дә.
Ә минем кебек малайлар
Мәңләгән Җир йөзендә», — дип әйтә ала ул. «Малайлар сөйләшә» шигыренә колак салыйк, әнә ничек уй йөртә замана балалары: «Ә мин начальник булам, йөрим «Волга»да гына!» «Ә мин кибетче булам!» — дип һөнәр сайлаучы яшьтәшләрен тыңлап, берсе: «Ә миңа әни үскәч куша КЕШЕ булырга!» — дип үзенчә йомгаклап куя. Намус, вөҗдан, әхлак, әдәп дип сөйләшмәсәләр дә, гомергә нинди буласылары шушы сабый чакларда хәл кылына, юллар сайлана...

«Әйдәгез, дуслашабыз!» дигән җыр милләтара мөнәсәбәтләр кискенләшкән бер вакытта аеруча актуаль яңгырый:

«Җирне саклап
калалмабыз,
Дуслашмаган килеш без.
Шуңа күрә барыбыз да
Дус булырга тиеш без!»

Мәңге какшамас тоелган чакырулар гамәлдән төшкәндә дә шагыйрьнең бер шигыренә исем иткән: «Бөтен дөнья балалары, берләшегез!» дигән өндәве үз көчендә калыр. Тату булсыннар, дөнья аларга, алар яшисе, киләчәк аларныкы. Роберт шигырьләрендә бүгенге яшәешебезнең кайнар сулышы бар, тематикасы тормышның төрле якларын колачлый.

Р. Миңнуллин турында, балалар язучысы, дип язам. Беләсез, танылган олылар шагыйре дә ул. Лирик Роберт уйчан, тирән хисле, балалар Роберты зирәк, җитез, шаян вә наян. Рәхмәт инде, юмор-күчтәнәчләрен балаларга дип саклап тора. Ике Робертны ярыштырмастан, балалар өчен эшләгәнен әдәбиятыбызда вакыйга дип саныйм. Ул моны ике дистә еллык иҗаты белән раслап килә. Анда-санда балалар өчен язгалаган каләмдәшләргә дә рәхмәт. Әмма Роберт тумыштан балалар шагыйре, аның гомерлек максаты шул.

Язучының иң зур җәмәгать эше — иҗаты дип саныйм. Әлбәттә, савапка эшләнә торган бүтән бурычла...

нин исемендәге Совет балалар фондының Татарстан бүлеге идарәсе рәисе буларак Р. Миңнуллинның үз вазифасын ничек үтәвен күрергә туры килә. Кем әйтмешли, үзең түземлек бир: ятимханәләр, ятимнәр хәлен, имгәтелгән язмышлар фаҗигасен, аһ-зарын, күз яшьләрен, мохтаҗлыгын күңелгә сыйдырырга, күтәрергә кирәк... Ул нарасыйларның һәркайсы: «Кайсыгызның кулы җылы? Бәйлисе бар йөрәкне...» дия алыр иде. Роберт абыйларының кулы җылы, тулы ятимнәрне генә түгел, таш бәгырьләр ташлаган әниледән әнисез, әтиледән әтисезләрне дә кайгырта...

Балалар фонды оешу турында сүз чыккач та Татарстан бүлеге рәисе итеп Р. Миңнуллинны уйлаган идем. Балаларны кайгыртып телевидениедә күп еллар «Шигъри тәлгәшләр» тапшыруын оештыручы, бердәнбер балалар газетасы «Яшь ленинчы» редакторы, балалар әдәбияты секциясе җитәкчесе, танылган балалар язучысы... Бала җанлы, күркәм сабырлыкка ия кеше. Рухи халәте белән үз яшеннән олы тоела ул миңа. Сыңар канат — яшьли әтисез калу иртә өлгерткән, бүтәннәрне кайгыртырга, җаваплылыкка өйрәткән. Сугыш чоры балаларына — безнең буынга бик таныш бу...

Әле генә булып узган сайлауларда Р. Миңнуллинның Татарстан Югары Советына депутат итеп сайлануын халыкның ышаныч белдерүе һәм яңа җаваплылык өстәве дип карыйм.

Каян ала әдип көчне, илһамы нинди чыганаклардан?

Туган җир көч бирә, дип язабыз. Туры мәгънәсендә дә шулай икән. Галимнәр сынап караган: имәнгә сөялеп торсаң, куәтең арта — туган җир үз көчен сиңа күчерә икән. Шул хакта укыгач, бер фоторәсем күз алдыма килде. Еш күрәм мин аны: мәһабәт гәүдәле дәү әтисенең аякларына сыенган малай... Ул да бит дәү әтисе аша үзе күрмәгән бабаларына тоташкан, ә нәсел-нәсәбе белән милләтенә, туган җиренә береккән — дәрман алып тора. Тамырлары тирәндә, буыннар, гасырлардан килә рухи кодрәт... Борынгылар шәҗәрәне «нәсел агачы» дип бик белеп әйткән: көч бирә торган мәңге тере имән ул!

Туган тел язмышы, милләтебез яшәве турында ачыктан-ачык борчулы сүз барган бу елларда балалар тәрбиясенә, әдәбиятына игътибар артты. Тукай бүләгенең «Балалар әдәбияты һәм сәнгате әсәрләре өчен» дип махсус тәгаенләнгән булуы — моның бер чагылышы. Әйе, зур бүләккә вакыйга булырдай әсәрләр генә лаек. Бүген безнең балалар әдәбиятында андый автор бар, ул — шагыйрь Роберт Миңнуллин, дип ышанып әйтә алабыз.

Килгән айларында бераз Сарьян миндә дә кунгалап йөрде. Әмма минем фатир шартлары бик кысынкы чак: өч бүлмәле фатирның ике бүлмәсендә — биш-алты кешелек гаилә, бер бүлмәсендә — без. Шул бер бүлмәдә ирле-хатынлы икебез, яшь бала...

Килеп керер иде дә Сарьян, ике кулы белән ишек яңгына таянып, бусагага басып килеп кенә җыр сузып җибәрер иде:

Ялан еркәйдең ай
кәккүге юк,
Уд Уралкайыма
кайтайым...

Шулай моңлана иде Сарьян... Әлбәттә, җиңел булмагандыр аңа: гаиләсе Уфада калды, үзенең торыр куышы юк...

Аның хатыны Фирүзә ханым Уфаның ниндидер бер техникумында укыта иде булса кирәк. Кечкенә Рифкать ул вакытларда кем кулында булгандыр — әйтә алмыйм.

Әмма Хәсән Сарьян җебеп төшмәде, югалып калмады. Ул татар язучылары арасында үз урынын тиз таба алды. Тыштан сабыр-салмак күренсә дә, эшчән, дәртле-егәрле егет иде Сарьян. Кыш-яз үтеп, җәй айлары җитүгә, Уфадан гаиләсен дә алып килде. Фатир мәсьәләсе дә уңай хәл ителде. Алар Казан финанс-экономика институты артындагы тау башында — агач йортларның берсендә яши башладылар. Ул фатир Әмирхан ага Еникидән калган иде бугай.

Хәсән Сарьян тиз арада — өч-биш ел эчендә оста хикәяче булып танылды. Аннары «Әткәм һөнәре» (1965), «Бер ананың биш улы» (1976), «Җәза» (1978) кебек җыйнак-тыгыз повестьлар иҗат итте. Тел белемәнә һәм әдәби-тәнкыйтькә багышланган күп санлы мәкаләләр язды. Тәрҗемә өлкәсендә дә уңышлы гына эшләде.

Мин аның иҗатына төпле анализ ясарга җыенмыйм, урыны ул түгел. Анысы — тәнкыйтьчеләр эше. Мин Сарьян турында үзем белгәннәрне генә язам.

Хәсән Сарьянның Казанда үткән унсигез ел гомере безнең күз алдында булды. Хәтта Идел буендагы бакчаларыбыз да янәшә иде. Әйе, Сарьян турында күп сөйләргә мөмкин. Аерым алып сөйлисем килгәне — аның туган якларын сагынуы, шигъри табигатьле рухы-җаны турында.

Үзенең туган ягы Илешне, Агыйдел, Сөн, Базы су буйларын исенә төшергәндә, Сарьян бөтенләй үзгәреп китә иде. Гадәттә сабыр-салмак Сарьян күз алдында шагыйрьгә әйләнә дә куя!

Әле күптән түгел генә Татарстан китап нәшрияты Туфан Миңнуллин төзегән «Агыйделкәй» (1989) исемле бүләк китап бастырып чыгарды. Анда «Агыйдел» сүзе кергән халык җырлары тупланган — дүрт йөздән артык җыр! Шуның ничәсен белә иде икән Хәсән Сарьян? Мин менә шул китапны актарып утырам да, күп кенә җырлар колагыма Сарьян дус тавышы булып яңгырап керәләр... Илләә дә сөенер иде ул бу нәни китап өчен!

...дай уйнаклап, Агыйделем ага... И минем туган җирем — унике буын буена сулап туймас сулышым!..» дип тәмамлый Сарьян.

Нә, кайсыбыз тагын үз туган җирләре, үз нәсел-нәсәбе турында моннан да көчле, моннан да хисле итеп әйтеп бирә ала? «...Ярдан ярга тибеп, колындай уйнаклап....» — моны бит болай матур, җанлы итеп шагыйрьләребезнең дә бик күбесе яза алмый.

Хәсән Сарьян минем иҗатымның да нәкъ менә шул ягын — үз күңеленә якын булганын тотып алып бик матур мәкалә язган иде. «Туган җиренең шагыйре» дип атала иде ул мәкалә. Аны башта «Социалистик Татарстан»да (1976 ел, 18 апрель), аннары «Уеңны уйдырып сал...» дигән китабында (1977) бастырып чыгарды.

Чын мәгънәсендә җир кешесе иде Сарьян. Табигать баласы иде. Идел буеннан бакча җире алып, шунда казынып-чокынып йөргән көннәре иң бәхетле көннәре булгандыр аның. Сарьяннар участогында ике зур имән бар иде. Шуның берсе астына кертеп, үз кулы белән сандык шикелле җыйнак-пөхтә йорт җиткерде. Агач-такта ише әйберләргә бик кытлык чаклар иде. Юктан бар итеп салды йортын Сарьян. Имән туры килгән күп кенә бакчачылар агачларын кистеләр-төпләделәр. Сарьян кисмәде. Алай гына да түгел, икенче зур имәне төбендә ул дүрт сутыйга да тулмаган бакча җиренең дүрттән бер өлеше кадәрен чирәмен дә күтәрмичә калдырды. Ничек бар шулай, кыргый бер «болын» хәлендә. Җәй буена сулар сибеп, шул үз «болынын» кадерләп-карап тотар иде. Икешәр мәртәбә печәнен дә чабып ала... Хәзер дә ул яшел кишәрлек шулай кыргый хәлендә тора. Анда кыр чәчәкләре үсә, куе-куе булып юа күтәрелә...

Яшерен-батырын түгел, Сарьян ярлы яшәде. (Ә кайсы татар язучысы байлыкмуллыкта, бал-май эчендә генә яши соң?!) Ул күп яза алмады, аз язды. Һәр язганы йөрәгеннән сыгылып-саркып кына чыгар иде. Ул коньюнктура дигәнне, көнем өчен дигәнне белмәде. Әдәбиятка бер вакытта да хыянәт итмәде, итә алмады. Үзе исән чакта Хәсән Сарьянның татар телендә нибары алты китабы чыгып калды. Юкарак кына алты китап... Язганнарының байтагы, шул исәптән югарыда телгә алган «Ноктaлы өтер» исемле сатирик повесте да, дөнья күрә алмыйча, сөзелеп кала барды. Ни әйтәсең, торгынлык еллары иде. Бик кысынкы, кысылган еллар. Матди кысынкылыктан битәр, рух кысынкылыгы...

Мин Татарстан китап нәшриятында баш редактор булып эшли идем. Ул елларның албастыдай басып торган тынчу һавасы искә төшкәндә, әле һаман да күңелләрне болгата... Югары оешмаларга чакыртып, «каләмгә бастырып» җанынны ашый торган заманнар иде ул.

ле кеше иде Сарьян. Физик эшне бик яратты. Менә дигән балта остасы иде. Аның «Әткәм һөнәре» повесте нәкъ менә шул балта остасы булуыннан чыгып язылган да. Аннары Сарьян бик ярдәмчел иде. Бер-бер каккалыйсы-суккалыйсы эшең булдымы, хәзер ялт иттереп эшләп тә бирә.

Менә шулай тыныч-матур гына яши идек әле без. Тәрес, Сарьянның баш авыртуы кебек хикмәте бар иде. Бакчада эшләгәндә башын ул һәрвакыт яулык белән тасмалап, кысып бәйләп йөри иде. Ләкин сәламәтлегеннән бер дә зарланмый иде алай.

1978 елның 21 сентябре көнне Хәсән Сарьян кинәттән генә вафат булды. Без аны бераз сибәләп-пыскаклап торган моңсу көндә җир куенына салдык. Үзе яраткан җир куенына...

Без — сугыш елларының ач-ялангач, ятим бабалары — байтак каләмдәшләребезне шулай яшьли югалттык. Ләбиб Айтуганов, Тәүфикъ Камалиев, Газиз Мөхәммәтшин, Зиннур Насыйбуллин, Ренат Рәхимов, Егор Уткин, Мәсгут Шәрифуллин...

Белмим, кем ничектер, әмма мин үзем боларның барысын да үткән сугыш корбаннары дип саныйм. Сугыш кыравы суккан, ачылып өлгерә алмый калган чәчәкләр булдылар алар...

Миндә Хәсән Сарьянның тавышы язылган магнитофон тасмасы бар. Үзен сагынганда еш кына мин шул тасманы тыңлыйм. Сарьянның салмак тигез тавышы моң булып күңелгә инә. Сарьян дус инде менә ничәнче мәртәбә яңадан минем белән сөйләшә...

«Мин сүземне юкка гына туган җир дип башламадым, — ди ул. — Чөнки туган җирнең туфрак җылысын, үз халкының күкрәк җылысын йөрәк ите белән тоймаган шагыйрь минем йөрәгемә дә керә алмый, аңа шулай ук башка халыклар күңеленә дә юллар ябык була. Үзеңнең туган җиреңнең, үз халкыңның син булмаганда кыен булачак бер күзәнәге булганда гына син юлны башкаларга да киң ярырсың... Без туган җиребез баласы бит!»

Туган җирендә туйганчы яши генә алмадың, Сарьян...
Ә синең яраткан Агыйделең һаман шулай ага да ага, ага да ага... Үз сүзләрең белән әйткәндә, «ярлары да кеше гомере сыман, кителепкителеп кенә юыла тора, юыла тора...»
Хәсән Сарьянның бакчасындагы имәннәре һаман шулай шаулап утыра. Таза имәннәрдәй буй җиткереп, үзләре әти булган өч улы — Рифкате, Булаты, Айдары — гаиләләре белән бакчага килеп тулган көннәрдә имән төбендәге яшел «болын»да балалар чыр-чуы тынмый. «Болгар угланы Гәрәй бабай»дан соңгы унөченче-ундүртенче буын татар балаларының — Сарьян оныкларының куанычлы чыр-чулары бу. Аларда Хәсән Сарьян каны да ага — тормыш елгасы, Агыйдел кебек, һаман алга омтыла.

Марс ШАБАЕВ.

* Арлар — удмуртларны элек шулай атап йөрткәннәр. Х. Сарьян искәрмәсе.

күңел «телен» аңлаучы «сәвәллы сабыйлар» бар. Робертның популярлык сере дә әкә шул балалар белән уртак сыйфатларында — ихласлык, тапкырлык, шаянлыкта. Юмор торгынлык елларында да рәсмилектән тәмам гарык бала күңелен, әдәбиятның сәламәт саклаган хасият булды. Шигырьләрендә олылар дөньясына, тормышка тоташтырган бик га...

Юмор, сатира — рухи хөрлек, бәйсезлек билгесе, демократия юлдашы.

Робертның балаларга әйтер сүзе — китаплары бербер артлы чыга тора. Шулардан инде укучылар яратып өлгергән соңгыраклары Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә тәкъдим ителде. Менә алар: «Безнең авыл зоопаркы» (1988), «Җәйнең яшел аты» (1987), «Балачак бәйрәмнәре» (1985). Мәскәүдә, русчага тәрҗемәдә дөнья күргәннәре: «Наш тигренок» (1987, «Малыш» нәшрияты), «Глядит в окош-

безгә әнис орлыгының тәме рәхәт болыннарны, печән өсте бәйрәмнәрен хәтерләтә. Нәни бөртеккә болын сыйган, болында — балачак! Шул истәлек күңелне имин матурлыкка көйләп, иркәләп тора... Шәһәрдә үскән бәрәүгә орлыкны бирәм, тәмләп карый да сәерсенеп йөзен чыта... Балачак хәтерендә юк ул аның, болын тулы гүзәлек юк, сагынырлык тәм

Бала чакта укылган шигырьләр дә нурланып күңел төбендә ята. Өлкәнәйгәч тә тормыш «тәмләткеч» буларак кирәк алар, әйбәт күңелле булу өчен кирәк. Р. Миңнуллинның шигъри болынында андый хис-әнисләр күп. Халык иҗатының шифалы чәчәкләренә, сүз-хәзинәләренә, күркәм гореф-гадәтләр сабантуйларына тоташкан әсәрләр алар. Авылдамы, шәһәрдәме, шул тәмнәрне татып үскәннәрнең балачак бәйрәмнәре гомергә истә калыр.

Күңелле, тыныч, имин булырга тиеш балачак. Уены

ман. Алдамла, Хуҗа Насретдиндай беркатлыга салышкан тиктормасның сынап каравы ул! Балалар шагыйре булып туарга кирәк, дигәнне телгә талант дип тә аңлыйм. Бәхетең шунда. Бәхетсезлегең дә — булмаса, кемгә үпкәлисең... Балалар шигырендәге урынсыз бер сүз дә тәгәрмәч астындагы таш сыман шигырь-арбаны аударуы ихтимал...

Р. Миңнуллин сынчы оста турындагы бер шигырендә «тылсымчы» дигәнне «тылсынчы» дип уйната. Сүз белән сын тудыручы буларак аның үзен дә «телсынчы» диярга була.

Шигырьләре җаңга ятышлы, җырга ятышлы — композиторлар бик теләп көй язып торалар. Балаларга дигәннәре дә өч-дүрт дистәдән артыктыр. Бүләккә күрсәтелгән китапларда да бар алар. Шунысы кызык, балалардан кайчак өлкәннәр әләктереп ала. Әйтик, «Әни кирәк» җыры шулайрак булды. Хәер, балалар да аптырап калмый — әниләр ту-

дөнья балалары, берләшегез!» дигән өндәве үз көчендә калыр. Тату булсыннар, дөнья аларга, алар яшисе, киләчәк аларныкы. Роберт шигырьләрендә бүгенге яшәешебезнең кайнар сулышы бар, тематикасы тормышның төрле якларын колачлый.

Р. Миңнуллин турында, балалар язучысы, дип язам. Беләсез, танылган олылар шагыйре дә ул. Лирик Роберт уйчан, тирән хисле, балалар Роберты әйрәк, җитез, шаян вә наян. Рәхмәт инде, юмор-күчтәнәчләрен балаларга дип саклап тора. Ике Робертны ярыштырмастан, балалар өчен эшләгәнен әдәбиятыбызда вакыйга дип саныйм. Ул моны ике дистә еллык иҗаты белән раслап килә. Анда-санда балалар өчен язгалаган каләмдәшләргә дә рәхмәт. Әмма Роберт тумыштан балалар шагыйре, аның гомерлек максаты шул.

Язучының иң зур җәмәгать эше — иҗаты дип саныйм. Әлбәттә, савапка эшләнә торган бүтән бурычлары да аз булмый. В. И. Ле-

җир үз көчен сиңа күчерә икән. Шул хакта укыгач, бер фоторәсем күз алдыма килде. Еш күрәм мин аны: маһабәт гәүдәле дәү әтисенең аякларына сыенган малай... Ул да бит дәү әтисе аша үзе күрмәгән бабаларына тоташкан, ә нәсел-нәсәбе белән милләтенә, туган җиренә берекән — дәрман алып тора. Тамырлары тирәндә, буыннар, гасырлардан килә рухи кодрәт... Борынгылар шәҗәрәне «нәсел агачы» дип бик белеп әйткән: көч бирә торган мәңге тере имән ул!

Туган тел язмышы, милләтебез яшәве турында ачыктан-ачык борчулы сүз барган бу елларда балалар тәрбиясенә, әдәбиятына игътибар артты. Тукай бүләгенең «Балалар әдәбияты һәм сәнгате әсәрләре өчен» дип махсус тәгаенләнгән булуы — моның бер чагылышы. Әйе, зур бүләккә вакыйга булырдай әсәрләр генә лаек. Бүген безнең балалар әдәбиятында андый автор бар, ул — шагыйрь Роберт Миңнуллин, дип ышанып әйтә алабыз.

Шәүкәт ГАЛИЕВ.

# Кандидатурасы калсын

ТАССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясенә тәкъдим ителгән кандидатлар белән танышкач, анда Мөхәммәт Мәһдиев исемен дә күреп, шатланып, горурланып куйган идем.

Әйе, Мөхәммәт абый Мәһдиев — бу олы бүләккә күптәннән лаеклы әдип. Соң булса да, уң булсын, дигән әйтем бар.

Кызганычка каршы, безнең талантларыбызны вакытында торгынлык еллары «хуҗалары» күрмәде. Әлбәттә, торгынлыкның «үз геройлары», «үз талантлары», «үз галимнәре» күп булды шул.

Үзгәртеп кору чорының гадел хөкеме чын талантларга да, ниһаять, юл ачты. Иҗат юлларындагы киртәләр алып ташланды.

Бүгенге көн әдәбиятында Мөхәммәт Мәһдиев — гаять киң мәйдан тоткан күренекле әдип. Аның кайсы гына әсәрен укысаң да, алар халыкчан, искиткеч җор тел белән, аңлаешлы һәм җиңел язылганнар. Һәр әсәр үзенә җәлеп итә, аны кайта-кайта укыйсың.

Мөхәммәт абый безнең иң мөхтәрәм, иң яраткан укытучыбыз да әле. Менә инде ул чирек гасырдан артык В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында совет чоры әдәбиятын укыта. Аның лекцияләре җанлы, мәгънәле, тормышчан һәм ифрат гыйбрәтле уза. Их, Мөхәммәт абый кебек зыялы укытучылар күбрәк булсын иде, дип тә куясың.

Мөхәммәт абый «Социалистик Татарстан» газетасының 7 март санында Г. Тукай премиясенә кандидатлар исемлегеннән үзенең кандидатурасын алуын игълан иткән иде. Әмма безнең яраткан, мөхтәрәм укытучыбыз, язучыбыз М. Мәһдиевнең кандидатурасы калсын иде.

Аның урыны, һичшиксез, Г. Тукай премиясе лауреатлары арасында.

Ф. МАКАРОВА.

Казан.

# Яклыйбыз

1989 ел өчен ТАССРның Г. Тукай исемендәге премиясенә кандидатлар исемлегендә, ниһаять, И. Сәлахов, М. Мәһдиев кебек мөхтәрәм затларның исем-фамилияләрен күрү насыйп булды. Шәхес культы корбаны буларак, лагерьларда үзе кичергән коточкыч вакыйгаларны, ачы хакыйкатьне «Колыма хикәяләре» кебек фаҗига-хроника аша халыкка җиткерүче җанлы шаһит буларак та өлкән әдибебез Ибраһим ага Сәлахов ул премиягә бик лаек дигән фикердә торам. Ихтирам һәм игътибарны һәр кешегә үзе исән чакта күрсәтергә кирәк.

Халык мәнфәгатьләрен уйлап, газета битләрендә авылны терелтү, татар халкының һәм теленең язмышы турында борчылып, гаделлек өчен янып-көеп көрәшүче, үткен фикерле әдип һәм галим Мөхәммәт Мәһдиев үзе генә ни тора?!

Авыл җире, аның табигате һәм кешеләре генә түгел, чорыбыз өчен бик тә кирәкле, әмма җитешми торган әдәп, әхлак мәсьәләсе аның һәр әсәрендә кызыл җеп булып сузыла.

Сугыштан соңгы еллардагы авыл халкының авыр тормышын үткен, йөгерек, җор телле әдип кенә шулай үзенчә (Мәһдиевчә), уен уйдырып салып тасвирлый ала.

Әсәрләре, Ф. Миңнуллин әйткәнчә, «тормышның үзеннән дә чынрак», яшь аралаш көлдерә дә, җырлата да, яшьлекне сагындырып елата да...

Газетада бирелгән (7.03. 1990) М. Мәһдиевнең үз кандидатурасын алуы турындагы белдерүе хафага салып, бу язманы сезгә юлларга мәҗбүр итте. «Фронтовиклар», «Кеше китә — җыры кала», «Ут чәчәге», «Мәңгелек яз», «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү» кебек әсәрләре басылган әдип, әдәп йөзеннән, үз кандидатурасын алса да, Г. Тукай исемендәге премияләр комитеты аның әсәрләрен яратып укучы бик күпләрнең фикерләрен игътибарда тотар, дип ышанам. Без, М. Мәһдиев яше белән дә, хезмәтләре белән дә сөекле шагыйребез бүләгенә күптән лаек, дип саныйбыз.

Г. ҺАДИЕВА,
укытучы.

Сарман.

# «Ничек экстремист булырга?..»

Башкортстанда яшәүче әдип Айдар Хәлим 1988 елда «Дружба народов» журналында «Телем минем — дустым минем» дигән мәкалә белән чыгыш ясый. Анда сүз, нигездә, ана теленең кадерен белү кирәклеге турында бара. Башкортстанда татарлар тупланып яшәгән төбәкләрдәге мәктәпләрдә татар телендә укыту бетерелеп, башкортча укытуга күчү кебек тискәре күренешләр турында ачынып языла. Кызганычка каршы, бу бәлаңың «остан» — республиканың шул чактагы җитәкчеләре «тырышлыгыннан» башлануы дәлилләргә нигезләнеп күрсәтелә.

Ростов кинохроникасы студиясе режиссеры Василий Голубниченко шул конфликтны сюжет нигезенә салып «Ничек экстремист булырга?..» дигән документаль тасма төшергән. (Операторы — Семен Эпштейн).

Әмма фильм һич тә әлеге конфликтлы ситуацияне анализлау белән генә чикләнми. Ул тел мәсьәләсенең халыкның узаңы, милли мәдәни үсеше, һәр шәхеснең җәмгыятьтәге иҗтимагый-сәяси роле кебек проблемаларны кузгата.

Пресса йортында әлеге документаль фильм республика журналистларына күрсәтелде. Соңыннан фильмның режиссеры Василий Голубниченко һәм әдип Айдар Хәлим белән әңгәмә булды. Фильмның актуальлегенә югары бәя бирелде. Журналистларның уртак фикерен белдереп, тәнкыйтьче Мансур Вәлиев:

— Василий Голубниченконың бу эшен рус интеллигенциясенең батырлыгы дип бәяләргә кирәк, — диде.

Журналистлар шулай ук режиссерның «Гаулар кара башлык астында» дигән документаль фильмын да карадылар.

И. ГАЗИЗОВ.

Рәсемдә: Айдар Хәлим һәм Василий Голубниченко.

Р. Галиев фотосы.



# РУМЫНИЯ ЦИРКЫ ЙОЛДЫЗЛАРЫ

Казан циркында Румыния циркы артистлары гастрольләре башланды. Ике бүлектән торган тамашада өйрәтелгән маймыл, тюлень, пеликан, буар елан, попугай, дуңгыз, төлке һәм башка җанварлар чыгыш ясый. Фотохәбәрчебез А. Андронов әлеге рәсемнәрне әнә шул тамашадан төшереп алган.



# МИЛЛӘТ ТУРЫНДА КАЙГЫРТЫП

Торган саен тормыш катлаулана. Киң куллану товарларының, азык-төлекнең кибет киштәләреннән юкка чыгуы, кыйммәтчелек, төрле гаделсезлек күренешләре, бюрократчылык һәммәбезнең күз алдында. Ил буенча милли мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе, канлы-фаҗигале бәрелешләр җанны тетрәтә.

Татарстандагы халыклар арасында милли мөнәсәбәтләрдә алай тышка бәрелеп торган конфликтлар, кискенлекләр булмаса да, татар халкының проблемалары хәл ителми, кайберләре катлаулана гына бара. Борчылырлык, уйланырлык хәлләр дә бар. Аларны күрмәмешкә салыну сәяси сукырлык булыр иде. Узган ел СССР халык депутатлары итеп Казан шәһәреннән бер генә татар да сайланмады. Быел РСФСР халык депутатларын сайлауда республика буенча шундый тенденция ачык күренә. Руслар күп яшәгән регионнарда татар кандидатларының депутат итеп сайланмау очраклары аз түгел.

Татар теленә дәүләт статусы бирү мәсьәләсен ...

... киң халык массаларына таянып башкара.

Һәрберебезне борчый, илне тетрәтә-какшата торган мондый хәлләрне төзәтүгә халык массаларын тагын да киңрәк тарту максатыннан чыгып, 17 мартта Казанда Татар иҗтимагый үзәге советының пленумы үткәрелде.

Пленумда Үзәк оештыру съездыннан соң башкарган эше турында ТИҮ идарәсе рәисе М. Ә. Мөлеков доклады тыңланды. ТИҮ рәис-координаторы Г. А. Файзрахманов мәдәни-милли автономия һәм Татар иҗтимагый үзәгенең Татарстаннан читтәге бүлекләренең эше турында доклад белән ...

... кеше катнашты. Катнашучыларның географиясе киң булу Татар иҗтимагый үзәге бүлекләренең Киевтан алып Новосибирск, Төмәнгә хәтле, Ташкенттан алып Воркутага кадәр араларда төзелүен һәм эшләвен күрсәтте.

Пленум барышында күренгәнчә, ТИҮнең бүлекләре халкыбызның хокукларын яклау, мәдәниятен, мәгарифен үстерү, халкыбызны милләт буларак саклап калу, яшь буынны тәрбияләү буенча зур эш алып баралар. Урыннардагы партия, совет аппаратының бу өлкәдәге эшен яхшырту буенча киң халык массаларын күтәрәләр.

ТИҮ бүлекләре ...

Төмән, Воркута һәм башка шәһәрләрдә эшләп килә. Ләкин бу эшләр җирле партия, совет аппаратының бюрократик каршылыгы белән тоткарлана, газета чыгару, татарча укыту, радио, телевидение тапшырулары оештыру гаять кискенлек белән башкарыла.

Пленумда мәдәният-милли автономия мәсьәләләре буенча җитди сөйләшү булды. Татар халкы компактлы яши торган урыннарда милли авыл Советлары, районнар, милли округ һәм өлкәләр төзү зарурлыгы турында, бу максатны тормышка ашыруда практик чаралар турында карар кабул ителде.

... шөгыльләнү буенча ТИҮнең Юныс Камалетдинов җитәкчелегендә махсус комиссиясе эшли. Комиссия кайтырга теләгән милләттәшләребезгә ярдәм итү буенча барлык бүлекләр белән элемтәдә тора.

ТИҮнең Башкортстан бүлеге рәисе, Башкортстан партия өлкә комитетының вакытлы бюросы әгъзасы профессор Марат Рамазанов Башкортстандагы татарларның проблемаларын хәл итү, татар-башкорт мөнәсәбәтләрен дөрес алып бару эшләре белән таныштырды.

Тикшерелгән мәсьәләләр буенча барлыгы 12 резолюция кабул ителде. Алар арасында Татарстан телеграф агентлыгы төзү зарурлыгы, Татарстанда милли университет төзү, «Татарстан яшьләре» газетасын «Татар яшьләре» исемле бөтенсоюз газетасына әйләндерү кирәклеге, статусны үзгәртү буенча Татарстан һәм Башкортстанның бердәм хәрәкә...




# КУРСАВИ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

«Социалистик Татарстан» газетасының 16 ноябрь (1989 ел) санында («Бер кашык дегет») Г. Лотфи минем бер мәкаләмдә Г. Курсави кабере турында төгәлсезлек җибәрелүе турында язган иде. Мин моңа ачыклык кертүне кирәк дип саныйм.

Габделнасыйр Курсави (1776—1812) — үзенең эшчәнлеге белән татар иҗтимагый фикере тарихында тирән эз калдырган шәхес. Юкка гына Галимҗан Ибраһимов аны прогрессив хәрәкәтнең беренче карлыгачы дип атамады. Ул уннан артык хезмәт язды һәм аларда мәгърифәтчелек һәм реформаторлык идеяләрен күтәреп чыкты. Г. Курсави беренчеләрдән булып тәкълидчелеккә каршы тәнкыйть уты ачты, һәртөрле фанатизмны, искегә ябышып ятуны гаепләде, үз халкын фән яктылыгына һәм прогресска өндәде.

Мәгърифәтче галимнең тормышы озын булмады. 1812 елны ул туган иленнән хаҗ сәфәренә чыгып китә һәм, юлда чума белән авырып, Истамбул шәһәрендә үлеп кала.

Узган ел Төркиягә фәнни конгресска барырга чыккач, без филология фәннәре докторы Ә. Г. Кәримуллин белән башта ук үзебезнең алга бу бөек шәхеснең каберен зиярат кылу бурычын куйган идек (бу сәфәр турында безнең юлъязмаларыбыз «Социалистик Татарстан»ның узган елгы 7, 10, 11 октябрь саннарында басылды).

Истамбул туфрагына аяк басу белән без Г. Курсавиның кабере турында сораша башладык. Бездә булган хәбәрләргә караганда, ул Өскөдарда Солтан Хәмит мәчете янындагы каберлектә күмелгән булырга тиеш иде. Әмма башта ук Өскөдарда андый мәчет булмавы, Истамбулда Солтан Хәмитнең бары тик төрбәсе генә булганлыгы ачыкланды. Биредә яшәгән татарлардан да, үткәннән хәбәрдар булган төрекләрдән дә Курсавиның күмелүе мөмкин булган башка каберлекләр турында сораштырып карадык, әмма белүче булмады.

Конгресс барган көннәрнең берсендә Әнкарадан безнең янга Мәхмүт Таһир әфәнде килеп чыкты. Төркиягә баруыбыз турындагы юлъязмаларыбызда без аның киң эрудицияле, татар җанлы, аның тарихын һәм мәдәниятен белүче, аларны пропагандалаучы кеше булуы турында инде язган идек. Бу күркәм кеше Курсави белән дә бик якыннан торып шөгыльләнгән (илгә кайткач, безгә Лондоннан аның бу зур мәгърифәтчебез турындагы мәкаләсе урнаштырылган бер фәнни җыентык та килеп төште). Аны Курсавиның күмелү урыны да кызыксындырган һәм ул үзенең фикердәшләре белән бергәләп дүрт ел дәвамында мәгърифәтче-галимнең каберен эзләгән, аның күмелүе мөмкин булган барлык каберлекләрне йөреп чыккан. Аның өчен бу максатта игътибарга иң лаеклы каберлек Өскөдардагы Солтан Җәмигъ мәчете янындагы Карача Әхмәт каберлеге була. Бу — зур һәм иске каберлек.

Башка төрки халыклардагы кебек үк, төрекләрдә дә каберлекләргә игътибар һәм ихтирам зур. Әмма, дөньядагы һәр нәрсә кебек, каберлекләр дә картаялар, еллар аларның өслеген дә, алар турындагы хәтерне дә тигезли бара. Үзебезнең Казаныбызда да күп кенә борынгы каберлекләр өстендә хәзер шәһәр мәхәлләләре (кварталлары) утыра. Карача Әхмәт каберлеге дә шундыйрак язмышка дучар була. Истамбул үзенең борынгы чикләрен үтеп, Босфор һәм Мәрмәр диңгезенең киңлегына чаклы чыккач, Өскөдарда зур төзелешләр башлана һәм әлеге каберлек өстеннән, аны бүлгәләп, заманча салынган юллар сузыла. Нәтиҗәдә бу каберлек өч кисәккә бүленеп кала. Әйтелгән игелекле кешеләр боларның һәркайсын бик җентекләп йөреп чыгалар, әмма Курсави каберен таба алмыйлар.

Мәрҗани исә узган гасырның 70 елларында үзенең хаҗ сәфәре вакытында бу кабер янында була, аның өстенә таш куелганлыгы турында да язып калдыра. Моннан соң инде 160 елдан артык гомер узган. Мәрҗани күргән каберне еллар җир белән тигезләгәнме, әллә башка бик күбәүләр өстеннән үткән кебек үк, Курсави кабере өстеннән дә соңгы елларда салынган юллар узганмы?! Тәәссефкә каршы, белә алмадык, бары юлдан узышлый ул каберлекне карап, башларыбызны иеп китү белән канәгатьләнә алдык.

Кешеләр яши, китә... еллар, гасырлар хәтта аларның каберләрен дә тигезли. Әмма олы шәхесләрдән тарихта тирән эзләр кала. Габделнасыйр Курсави да шундыйлардан. Вафатыннан соң узган 2 гасырга якын вакыт эчендә аның да кабере тигезләнгән. Шулай да халкыбызның күңелендә, тарихында, мәдәниятендә ул тирән эз калдырды. Без аны һәрвакыт тәкъдир итеп искә алабыз һәм киләчәк буыннар да аның истәлеген нык сакларлар, ул күтәргән яктылык идеяләрен, мәгърифәт идеяләрен югары күтәреп барырлар дип өметләнәбез.

Я. АБДУЛЛИН,
РСФСР һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, философия фәннәре докторы, профессор.

Реплика

# «Сагыз» түгел, «чәйнәмә»

«СТ»ның 4 нче март санында әдәбият белгече Рафаэль Мостафинның «Борынгы бер сүзлек турында» «ачышы» басылды. Тобол халык училищесы татар теле укытучысы священник Иосиф Гигановның 1804 елда Петербургта чыккан русча-татарча сүзлеге белән тагын бер буын укучыларны таныштыруны уңай күренеш ...

... тологлар тарафыннан да ул аркылыга-буйга тикшереп чыгылган. Ләкин бу — киләчәктә дә, бигрәк тә татар телен яңача үстерү чорында, аны өйрәнүне туктатырга ярый дигән сүз түгел.

Мәкаләдә хәзерге әдәби телнең формалашуы, аның диалектлар белән мөнәсәбәте мәсьәләләрен күз алдына китерү профессиональлектән шактый ерак тора. Бик күп ...

... күрә Р. Мостафинның «Татарның бүгенге басма ике тел сүзлеге дә (татарча-русча) шул ук И. Гиганов тарафыннан төзелгән һәм 1801 елны Петербургта басылган» дип язуы татарча-русча сүзлекне генә ике телдә була икән дип уйлаудан килә. Бу — бер, икенчедән, 1801 елда И. Гигановның сүзлеге түгел, ә «Татар теле грамматикасы» басылган.

# МИЛЛӘТ ТУРЫНДА КАЙГЫРТЫП

Торган саен тормыш катлаулана. Киң куллану товарларының, азык-төлекнең кибет киштәләреннән юкка чыгуы, кыйммәтчелек, төрле гаделсезлек күренешләре, бюрократчылык һәммәбезнең күз алдында. Ил буенча милли мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе, канлы-фаҗигале бәрелешләр җанны тетрәтә.

Татарстандагы халыклар арасында милли мөнәсәбәтләрдә алай тышка бәрелеп торган конфликтлар, кискенлекләр булмаса да, татар халкының проблемалары хәл ителми, кайберләре катлаулана гына бара. Борчылырлык, уйланырлык хәлләр дә бар. Аларны күрмәмешкә салыну сәяси сукырлык булыр иде. Узган ел СССР халык депутатлары итеп Казан шәһәреннән бер генә татар да сайланмады. Быел РСФСР халык депутатларын сайлауда республика буенча шундый тенденция ачык күренә. Руслар күп яшәгән регионнарда татар кандидатларының депутат итеп сайланмау очраклары аз түгел.

Татар теленә дәүләт статусы бирү мәсьәләсен хәл итү юлында да каршылыклар ачык.

Илебезнең төрле төбәкләренә сибелгән татар халкы башка милләтләр арасында, шул исәптән милли мөнәсәбәтләр кискенләшкән республикаларда да яши.

Демократия шартларына туры килеп бетми торган сайлау законнары кабул ителеп гамәлгә кертелде, сайлауларга хәзерлек, аларны үткәрүдә төрле бозулар бар.

Бу хәлләр Татар иҗтимагый үзәге каршына катлаулы проблемалар куйды. Үзәкнең идарәсе утырышларында болар тикшерелә, хәлгә анализ ясала, төрле чаралар билгеләнә. Халык хәрәкәте буларак, Татар иҗтимагый үзәге үзенең эшен киң халык массаларына таянып башкара.

Һәрберебезне борчый, илне тетрәтә-какшата торган мондый хәлләрне төзәтүгә халык массаларын тагын да киңрәк тарту максатыннан чыгып, 17 мартта Казанда Татар иҗтимагый үзәге советының пленумы үткәрелде.

Пленумда Үзәк оештыру съездыннан соң башкарган эше турында ТИҮ идарәсе рәисе М. Ә. Мөләков докладын тыңланды. ТИҮ рәис-координаторы Г. А. Файзрахманов мәдәни-милли автономия һәм Татар иҗтимагый үзәгенең Татарстаннан читтәге бүлекләренең эше турында доклад белән чыкты. Татарстанның статусын үзгәртүне хәзерләү һәм тормышка ашыру чаралары турында, илебездә һәм Татарстанда барлыкка килүче күппартиялелек һәм бу ситуациягә, КПССның Демократик платформасы группасына ТИҮнең мөнәсәбәте турында, Алабуга автомобиль заводы төзү, Татарстанда житештерүче көчләр һәм демографик политика турында, «Идел» турист-ял лагеренда татар яшьләренең ике атналык очрашуын үткәрү турында һәм башка мәсьәләләр каралды.

Пленум эшендә 30 дан артык союздаш, автономияле республикадан, өлкәдән, Татарстан шәһәрләре, районнарыннан 130 дан артык кеше катнашты. Катнашучыларның географиясе киң булу Татар иҗтимагый үзәге бүлекләренең Киевтан алып Новосибирск, Төмәнгә хәтле, Ташкенттан алып Воркутага кадәр араларда төзелүен һәм эшләвен күрсәтте.

Пленум барышында күренгәнчә, ТИҮнең бүлекләре халкыбызның хокукларын яклау, мәдәниятен, мәгарифен үстерү, халкыбызны милләт буларак саклап калу, яшь буынны тәрбияләү буенча зур эш алып баралар. Урыннардагы партия, совет аппаратының бу өлкәдәге эшен яхшырту буенча киң халык массаларын күтәрәләр.

ТИҮ бүлекләренең эшчәнлеге белән Ульяновскида, Богырысланда, Чиләбедә һәм башка өлкәләрдә татарча газеталар чыга башлады. Мәскәү, Ижевск, Төмән, Свердловск, Пермь, Ульяновск, Куйбышев, Чиләбе шәһәрләрендә һәм башка урыннарда татар телендә радио һәм телевизион тапшырулар бара. ТИҮнең җирле оешмалары булган һәр шәһәр, районда татар мәктәпләре, класслары, якшәмбе татар мәктәпләре эшли, уку планына кертеп яки факультатив рәвештә татар теле, әдәбияты укытыла, балалар бакчаларында татар группалары ачыла. Мондый класслар һәм мәктәпләр Ташкент, Оренбург, Богырыслан, Куйбышев, Ульяновск, Пермь, Свердловск, Новосибирск, Төмән, Воркута һәм башка шәһәрләрдә эшләп килә. Ләкин бу эшләр җирле партия, совет аппаратының бюрократик каршылыгы белән тоткарлана, газета чыгару, татарча укыту, радио телевидение тапшырулары оештыру гаять кискенлек белән башкарыла.

Пленумда мәдәният-милли автономия мәсьәләләре буенча житди сөйләшү булды. Татар халкы компактлы яши торган урыннарда милли авыл Советлары, районнар, милли округ һәм өлкәләр төзү зарурлыгы турында, бу максатны тормышка ашыруда практик чаралар турында карар кабул ителде.

Татарстанга союздаш республика статусы бирүне юллау Пленумда төп мәсьәлә булды. Татарстанны суверен союздаш республика итеп игълан итү — Татарстан Югары Советына яңа сайланган депутатлар эше, дигән фикергә килсенде. Бу эшне хәзерләү өчен 60 кешегә якын составта гражданнар комитеты билгеләнеп, халык тикшерүенә 18 мартта җыелышка чыгарылды.

Төрле регионнардагы татар халкының хәле, бигрәк тә Урта Азия һәм башка регионнарда татарларның куркып-калтырап яшәүләре, туган илләренә сыену урыны эзләп кайтырга әзерләнүләре турында сүз күп булды.

Кайтучы милләттәшләребезне эшкә урнаштыру, демографик проблемалар белән Юныс Камалетдинов житәкчелегендә махсус комиссия эшли. Комиссия кайтырга теләгән милләттәшләребезгә ярдәм итү буенча барлык бүлекләр белән элемтәдә тора.

ТИҮнең Башкортстан бүлеге рәисе, Башкортстан партия өлкә комитетының вакытлы бюросы әгъзасы профессор Марат Рамазанов Башкортстандагы татарларның проблемаларын хәл итү, татар-башкорт мөнәсәбәтләрен дөрес алып бару эшләре белән таныштырды.

Тикшерелгән мәсьәләләр буенча барлыгы 12 резолюция кабул ителде. Алар арасында Татарстан телеграф агентлыгы төзү зарурлыгы, Татарстанда милли университет төзү, «Татарстан яшьләре» газетасын «Татар яшьләре» исемле бөтенсоюз газетасына әйләндерү кирәклеге, статусны үзгәртү буенча Татарстан һәм Башкортстанның бердәм хәрәкәте турында, Иҗтимагый үзәкнең матбугат органын булдыру, республика матбугатында ТИҮнең платформасын бастыру турында һ. б. резолюцияләр бар.

Пленум милләтебез язмышы өчен зур кайгыртучанлык, чын интернационализмны ныгыту зарурлыгы шартларында үтте. Татар халкының милли проблемаларын рус һәм башка халыклар арасында аңлату, төрле проблемаларны чишүдә бергәләп эшләүгә зур игътибар бирелде. Шул ук вакытта шовинизмга юл куймау зарурлыгына да игътибар ителде.

Габделбәр ФӘЙЗРАХМАНОВ,
тарих фәннәре кандидаты, Татар иҗтимагый үзәге рәис-координаторы.

---

«Зәңгәр экран» янында уйланулар

# Диңгездән бер тамчы...

Соңгы вакытта үзәк телевидениедән Татарстан турында, гомумән, халкыбызның культурасын, сәнгатен һәм тормышын чагылдырган тапшырулар береаз артты. Узган елның февралендә бу исемлекне «Илебез театрлары күрсәтә» дигән рубрика астында РСФСРның М. Горький исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, язучы Аяз Гыйләҗевның «Өч аршын җир» дигән әсәре буенча фильм-спектакль башлап җибәрде. Бу спектакльдә халкыбызның бөтен ил белән бергә күргән ачы язмышы сурәтләнә. Бөтенсоюз тамашачысына бу әсәрне күрсәтү үзенә бер тес ала һәм горурлык та өсти.

Ул — Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының үзәк телевидениедән күрсәткән бишенче спектакле. Без бу коллективка яңаданяңа уңышлар телибез.

Март аенда РСФСРның атказанган артисты Зилә Сөнгатуллинаның «Телевизион бенефис»ы булып узды. Опера солисткасы булса да, Зилә Сөнгатуллина үзенең тапшыруын татар халык җыры «Гөлҗамал» белән башлап җибәрүе белән күңелгә ниндидер якты хисләр өстәде. Шуның белән бергәттән Көнбатыш Европа, совет һәм рус операларыннан катлаулы әсәрләр башкаруы җырчының зур талантка ия булуын раслады, бу хакта тапшыруны алып баручы музыка белгече Гүзәл Сәйфуллина кабат-кабат әйтеп узды.

Җәй азагында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына багышланган зур күләмле «Галиәсгар Камал исемендәге» тапшыруны бер сәгать буенча театрның баш режиссеры, СССРның халык артисты Марсель Сәлимҗанов алып барды. Үзе житәкләгән театр турында, аның хәзерге көндәге репертуары, Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»еннән алып хәзерге көндәге классикага тиң булган Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакльләре турында ашыкмыйча, горурлык белән сөйләве тамашачыны зур уйлануларга китерә.

Гасыр башында «Сәйяр» күчмә труппасыннан башланып киткән һәм хәзерге вакытта илебезнең иң яхшы театрларыннан исәпләнгән Г. Камал исемендәге театр турында, хатерем ялгышмаса, Бөтенсоюз экраны алдында мондый зур күләмле беренче тапшыру булды ул.

Европа елешендәге мөселман диния нәзарәтенең оешуына 200 ел һәм Идел буе болгарларының ислам динен кабул итүенә 1100 ел тулу уңае белән 21 һәм 31 августта «Вакыт» информацион программасыннан тапшырылган зур күләмле репортажлар да телевизор карауচылар игътибарын җәлеп иткәндер.

Ел азагында Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры Фанис Яруллинның «Шүрәле» балет-спектаклен күрсәтте.

«Шүрәле» балеты СССРның Зур театрында, Киров исемендәге Ленинград опера һәм балет, шулай ук Чехословакия, Венгрия, Польша һәм башка чит ил балет театрларында башкарылса да, халкыбызның Габдулла Тукай әсәренә нигезләнеп язылган «җәүһәр ташы» бөтенсоюз тамашачысына бик аз билгеле иде. Ниһаять, Ф. Яруллинның күренекле «Шүрәле» балетын бөтен ил карый алды.

Моннан тыш, үзәк телевидениедән Татарстанның дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты, шулай ук «Ләйсән» һәм «Сорнай» (ике тапкыр) фольклор ансамбльләре татар фольклор музыкасы (биш тапкыр) концертлары күрсәтелде.

Казан дәүләт культура институтының халык кораллары һәм музыка училищесының тынлы (өч тапкыр) оркестр коллективлары катнашында республикабызның танылган җырчылары Зөһрә Сәхабиева, Ания Туишева, Хәйдәр Бигичев, Рафаэль Ильясов һ. б. чыгыш ясадылар.

Җырчылар Х. Ишбулдин, Р. Ибраһимов, литаврист И. Сабирьяновның аерым концертлары, композиторлар Рәшит Кәлимуллин һәм Вадим Усмановка багышланган махсус тапшырулар булды.

Казан телевидение һәм кинохроника студияләренең үзәк телевидениедән күрсәтеп узган һәм минем карашка уңышлы башкарылган тасмалары: «Җир йөзендә мәхәббәт булганда» («Идет любовь по свету») дигән фильм-концерты, «Кооперациянең кайтуы» («Возвращение кооперации»), «Бу аңлаешсыз Галимҗанов» («Этот непонятный Галимзянов»), «Алдыңа кабат кара» («Оглянись вперед»), «Борынгы гармун» («Старая гармонь»), «Саклану законы» («Закон сохранения») дигән телевизион һәм документаль фильмнар.

Илебезнең үзәк телевидениесеннән 1989 елны республикабызга багышланган кырык ике тапшыру булды. Ә менә 1988 елны барысы егерме тугыз тапшыру булган. Сан буенча аерма бармы? Бар, әлбәттә. Республикабызга багышланган тапшырулар сан ягыннан бер ярым мартабага арткан. Һәм шулай ук, минем уйлавымча, сыйфат ягыннан да уңай үзгәрешләр күп. Шулай булгач, шатланырлык урын бар. Бигрәк тә Г. Камал театрына багышланган тапшыру, «Телевизион бенефис», спектакль премьералары, фольклор ансамбльләренең чыгышлары, телевизион һәм документаль фильмнар ошады. Алга таба да мондый сыйфатлы тапшыруларны, бигрәк тә татар драматургларының әсәрләрен фильм-спектакль итеп төшереп, телевизион бенефислар, профессиональ һәм фольклор ансамбльләренең, үзешчән коллективларның чыгышларын үзәк телевидение өчен күбрәк әзерләп бирергә кирәк.

Беренчедән, халкыбызның культурасын, сәнгатен, тормышын һәм бигрәк тә тарихын илебез күләмендә аз беләләр әле. Көнбатышта урнашкан республикаларда, Украинада, Белоруссиядә, Молдавиядә һәм Балтик буе республикаларында бөтенләй белмиләр, дип әйтсәк тә дөрес булыр иде.

Шулай итеп, халкыбызның культурасын, сәнгатен һәм тормышын илебез күләмендә пропагандалау өчен үзәк телевидениедән, бигрәк тә «СССР халыкларының милләтара аралашуы» дип игълан ителгән икенче Бөтенсоюз программасыннан тулырак файдаланырга иде. Моның өчен, әлбәттә, көчле материаль база кирәк.

КПССның Башкортстан өлкә комитеты бюросы 1989 елның декабрь аенда, Башкортстанда нәфис, документаль, фәнни-популяр, уку-методик, реклама-информацион кино һәм видеофильмнар төшерү буенча «Башкортстан» киностудиясен булдырырга карар кабул итте. Күршеләр, күрәсең, «югарыдан» күрсәтмәләр көтеп ятмасна уйлаганнар, һәм бүгенге көндә БАССР Министрлар Советы һәм республика Мәдәният министрлыгы тиешле әзерлек эшләре алып бара.

Икенчедән, бөтен ил буенча таралган милләттәшләребез безнең җырларыбызга, гомумән, сәнгатебезгә сусап яшиләр. Мәсәлән, Пермь өлкәсендә яшәүче 200 меңгә якын татар халкына. КПССның Пермь өлкә комитетының идеология бүлеге мөдире В. Степченко хәбәр итүенчә, өлкә телестудиясе буенча татар телендәге тапшырулар һәр кварталга бер тапкыр гына оештырыла. Бу бит диңгездәге бер тамчы су кебек кенә.

Татарстанда нәфис фильмнар студиясе булдыру бөтен илгә таралган 7 миллионга якын татар халкының рухи ихтыяҗын канәгатьләндерүгә зур өлеш кертә алыр иде.

Р. ФАЯЗОВ,
инженер.

---

Истамбул туфрагына аяк басу белән без Г. Курсавиның кабере турында сораша башладык. Бездә булган хәбәрләргә караганда, ул Өскодарда Солтан Хәмит мәчете янындагы каберлектә күмелгән булырга тиеш иде. Әмма башта ук Өскедарда андый мәчет булмавы, Истамбул үзенең борынгы ...

... берлекләр дә картаялар. Еллар аларның өслеген дә, алар турындагы хәтерне дә тигезли бара. Үзебезнең Казаныбызда да күп кенә борынгы каберлекләр өстендә хәзер шәһәр мәхәлләләре (кварталлары) утыра. Карача Әхмәт каберлеге дә шундыйрак язмышка дучар була.

... саклаулар, ул күтәргән якты идеяләрен, мәгърифәт идеяләрен югары күтәреп барырлар дип өметләнәбез.

Я. АБДУЛЛИН,
РСФСР һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, философия фәннәре докторы, профессор.

---

Реплика

## «Сагыз» түгел, «чәйнәмә»

«СТ»ның 4 нче март санында әдәбият белгече Рафаэль Мостафинның «Борынгы бер сүзлек турында» «ачышы» басылды. Тобол халык училищесы татар теле укытучысы священник Иосиф Гигановның 1804 елда Петербургта чыккан русча-татарча сүзлеге белән тагын бер буын укучыларны таныштыруны уңай күренеш дип санарга кирәк. Ләкин ул сүзне белеп сөйләүгә — компетентлыкка корылса, тагын да яхшы булыр иде, хәтта лексикографларга да файдасы тияр иде.

Автор фикеренчә, бу сүзлекне хәтта күп кенә тел галимнәре дә белми, имеш, һәм ул файдаланылмаган да. Әйтергә кирәк, сүзлекне 1950 нче еллардан алып, хәзергә кадәр булган студент-филологлар яхшы беләләр. Аның турында татар тел гыйлеме тарихына караган хезмәтләрдә дә җитәрлек язылган. Лексикографлар һәм диалектологлар тарафыннан да ул аркылыга-буйга тикшереп чыгылган. Ләкин бу — киләчәктә дә, бигрәк тә татар телен яңача үстерү чорында, аны өйрәнүне туктатырга ярый дигән сүз түгел.

Мәкаләдә хәзерге әдәби телнең формалашуы, аның диалектлар белән мөнәсәбәте мәсьәләләрен күз алдына китерү профессиональлектән шактый ерак тора. Бик күп диалекталь берәмлекләрне һәм И. Гигановның үз калькаларын әдәби сүзләргә каршы куюы да бик шикле булып кала. Мәсәлән, «жвачка» сүзенә әдәби телдә кабул ителгән «сагыз» бармый, янәсе, И. Гигановның «жвачка»дан ясалган «чәйнәмә» калькасы яхшырак булып чыга. «Жвачка» — сагыз инде ул, «чәйнәмә» — киң мәгънәле ясалма калька сүз, ул «белмичә сөйләү», «күп сөйләү»не дә эченә ала.

И. Гигановның бу хезмәте — ике тел сүзлеге. Шуңа күрә Р. Мостафинның «Татарның бүгенге басма ике тел сүзлеге дә (татарча-русча) шул ук И. Гиганов тарафыннан төзелгән һәм 1801 елны Петербургта басылган» дип язуы татарча-русча сүзлекне генә ике телдә була икән дип уйлаудан килә. Бу — бер, икенчедән, 1801 елда И. Гигановның сүзлеге түгел, ә «Татар теле грамматикасы» басылган.

Тарихчы яки филолог-галим XIX йөз башына карата «борынгы» сүзен дә кулланырга тиеш түгел иде. Әчтәлек буенча компетентлык җитмәсә дә, Рафаэль Мостафин бу мәкаләсе белән яхшы эш башлаган. Татар тарихында файдалы эш башкарган шәхесләрне җентекләп өйрәнү бездә чынлап та җитәрлек түгел. Моны, һичшиксез, тиешле югарылыкка куюалда торган зур бурыч булып кала бирә.

М. ЗӘКИЕВ,
профессор.

---

## Әйтсәң сүз чыга

«Әйтсәң сүз, төртсәң күз чыга» дигәннәр. Әмма, ничек кенә булмасын, язучы Роберт Батулланың «Татарстан яшьләре» газетасындагы (30 январь, 1990 ел) ярты сәгатьлек фәлсәфәсен укып чыккач, дәшми калу мөмкин түгел. Һәм ни өчендер бу иптәш «Социалистик Татарстан»да басылган мәкалә буенча «Татарстан яшьләре» газетасыннан торып ук ата? Ярый, анысы автор эше булсын ди. Гаҗәпләндерә торганы шул: мәкаләнең соңгы өч баганасы һич кенә дә автор атап, ачык хат итеп язган кешегә — Ә. Галимҗановка кагылмый, Кызып китеп, читкә тайпылу гына булып тора.

Хәзер инде бәхәснең асылына күчик. «Социалистик Татарстан» газетасының 15 декабрь, 1989 елгы санындагы мәкалә Р. Батулланы бәхәскә чакырамы? Һич юк. Әйтик «урыс» дигән сүз латин алфавитында ук инде «рус» дип языла иде. Бу ике язылыш арасында зур бер киртә ята бит, Батулла иптәш. Сез яклаган «урыс» сүзе татарны мыскыллау формасында йөрде һәм йөри. Әти-әнисе балаларын «әй, урыс, тал чыбыгы кирәкме?», «Төш, урыс, иманыңны укытырмын», «Мин сиңа бирәм әле, урыс!» һ. б. шундый мәгънәдә тирги иде. Сез, язучы буларак, сүзнең бер генә хәрефен дөрес кулланмауның нәрсә китереп чыгарганын яхшы белергә тиешсез. Әмма теләмисез. Татарны мескен итеп санавыгыз да әнә шуңа барып тоташа. Кешеләр алфавит турында фикер алышкан икән, аның ни гаебе бар? Өч хәрефне яклаган, латин алфавитын кире каккан Ә. Галимҗановның Дәүләт Думаларына, Б. ханым язганнарга, «томана» укытучыларга ни катнашы бар?!

Сез, Батулла иптәш, «өч хәрефне әштер-өштер китереп, болай да буталчык кагыйдәләрне без сиксәннән арттырып җибәрәчәкбез» дип куркасыз. Ә үзегез шул өч хәрефне әштер-өштер китереп, яшьләр газетасының (бигрәк тә укучылар алдында укытучыларны гаепләп) дүрттән бер өлешен алырга батырчылык иткәнсез түгелме соң!

Беләм, сезнең Ә. Галимҗановка «тиз язуга күнеккән язучыларыбызга яңа кагыйдә, өстәмә хәрефләр белән язарга өйрәнәсе булыр» дигән сүзләре өчен ачуыгыз килгәндер. Әмма ачу беркайчан да турылыклы киңәшче була алмый. 35 ел газетада эшләп, минем моңа дистәләрчә тапкыр иман китергәнем бар. Гомумән, якыннан белмәгән, аның хезмәтләре белән таныш булмаган кеше исеменә ачык хат язып, аны гаепсездән гаепләү сезнең өчен, Батулла иптәш, көчсезлек авазы булып тора. Һәм сез ул дуамал хатыгыз өчен Ә. Галимҗанов алдында гафу үтенергә дә батырчылык итә алырсыз дип ышанам.

Сез Ә. Галимҗановка ачык хатыгызда мәшһүр Тукайның бер шигырен исегезгә төшергәнсез. Минем дә бу язмамны Габдулла Тукайның «Шүрәле»се белән тәмамлыйсым килә. Сез белеп торасыз: яңа алфавит кертү турында ТАССР Югары Советы Указ чыгарды, Татарстан АССР Министрлар Советы карар кабул итте, СССР Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең Тел, әдәбият, тарих институты да шундый ук карарга килде.

Я, әйтегез инде, шуннан соң да сезнең фикерне кабул итмәгән кешеләргә кызыгуыгыз былтыр кысканга быел кычкыру булып чыга түгелме соң, Батулла туган!

Галим ШӘЙХИЕВ,
СССР Журналистлар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.
Буа шәһәре.

---

## ИСЕМЕ — «УМЫРЗАЯ»

Омск шәһәрендә интернациональ дуслык клубы ачылды. Ул «Нойес лебен», «Молдәр» һәм «Умырзая» дигән немец, казах, татар-башкорт милли клубларын берләштерә. Яңа берләшмәгә профсоюзларның өлкә советы булышлык итә.

Клубны ачу тантанасы «Юбилейный» мәдәният йортында булды. Анда халык иҗаты, милли ризыклар күргәзмәсе оештырылды, китаплар сатылды. Бәйрәм зур концерт белән тәгәлләнде.

Ю. ШПАКОВ.

Культурабыз тарихыннан

# Гаяз Исхакый Каюм Насыйри турында

Каюм Насыйриның «Нәмүнә яки әнмүзәҗ» исемле хезмәтен кулыма алу белән, аның алгы катыргы битенең эчке ягына ябыштырып куелган бер язмага күз төшердем. Язманың ахырындагы «Мехәммәт Гаяз әл Исхакый» дигән имза үзенә җәлеп итте. Шундук җәяләр эчендә «Тәрҗеман» дигән сүз дә бар.

Яшермим, башта: әллә бу Гаяз Исхакый кулъязмасымы, дип уйлап алдым. Әмма «Ышбу китабның мәснәфе Габдулкаюм әфәнденең вафаты 1902 сәнә 35 нче номер «Тәрҗеман» газетасында язылгандыр», дигән сүзләрне укыгач, әлеге фикерем юкка чыкты. Тиздән бер игелекле адәмнең Гаяз Исхакый тарафыннан язылып, К. Насыйри үлеменнән соң «Тәрҗеман» газетасында да бастырылган некрологны күчереп, ябыштырып куйганлыгын аңладым.

Эзләнә торгач, «Тәрҗеман» газетасының 15 сентябрьдә чыккан әлеге саны да табылды. Ул үземнең китапханәмдә үк яшеренеп яткан икән. Некрологның ике телдә — русча һәм татарча — басылуы ачыкланды.

Мәгълүм булганча, кырымлы Исмәгыйль Гаспринский 1883 елда Бахчасарай шәһәрендә рус һәм Кырым татарлары телләрендә «Тәрҗеман» («Переводчик») исемле атналык (соңга таба атнага ике тапкыр) газета чыгара башлый.

«Тәрҗеман» шул заманда төрки телдәге халыклар өчен Россиядә беренче һәм бердәнбер газета булган. Тик 1905 елгы буржуаз-демократик революция нәтиҗәсендә генә башка төрки халыкларда да, шул җөмләдән безнең татарларда да, үз телләрендә газета-журналлар барлыкка килә.

«Тәрҗеман» бик еракларга тарала. Аны Россиянең төрле почмакларында гына түгел, Төркия, Кытай кебек башка илләрдә дә укыйлар. Моңа кадәр без «Тәрҗеман» газетасына җитди игътибар бирми килдек. Әмма аның белән төплерәк танышу Идел буе татарларының культура ягыннан үсешендә аның билгеле бер урын тотуын күрсәтә.

1914 елда вафат булганына кадәр (31 ел буена) «Тәрҗеман»га Исмәгыйль Гаспринский җитәкчелек итә — нәшире дә, редакторы да ул үзе. И. Гаспринский үзен киң офыклы, тирән эрудицияле һәм талантлы журналист-оештыручы итеп кенә түгел, бәлки тәҗрибәле педагог итеп тә таныта. Ул Кырымда җәдит мәктәпләр ача, алар өчен әлифба китабы һәм дәреслекләр иҗат итә.

Татарның күренекле әдибе Гаяз Исхакый, бөек мәгърифәтчебез Каюм Насыйри дөнья куйгач, аның хезмәтләрен ихтирам итү йөзеннән, нәкъ менә «Тәрҗеман» газетасыннан файдалана. Некролог атналыкның, югарыда әйтелгәнчә, 35 нче санында басылып чыга.

Үзе исән чакта Каюм Насыйриның игелекле хезмәте, мәгърифәтчелек нуры таратуы турында, ай-һай, татарлардан берәрсе нинди дә булса язма уңай фикер әйттеме икән?! Некрологның иң әһәмиятле ягы шунда, бөек мәгърифәтченең бай иҗатын югары бәяләп, аны мактап беренче саллы сүзне шул чорның күренекле әдибе Гаяз Исхакый әйткән. Бер дә арттырмыйча әйтергә мөмкин: заманы өчен бу — зур батырлык! Тик соңга таба гына Каюм Насыйрины чөеп мактый башлыйлар.

«Тәрҗеман»дагы русчага тәрҗемә итеп урнаштырылган некролог тексты астына редакция үзеннән түбәндәге юлларны өстәгән: «Мәрхүм үзе исән чакта җәмәгать тарафыннан аңа тиешле бәһа бирелмәде. Әмма үлү вакыты бездән ераклашкан саен, аның исеме һаман югарырак бәяләнә барыр һәм аның игелекле авыр хезмәтенә бер генә гыйбадәт багышланмас».

«Тәрҗеман» газетасының зур өметләр белән әйтелгән күрәзәлеге безнең көннәрдә чын мәгънәдә акланды. Чыннан да, бөек мәгърифәтчебезнең игелекле хезмәтләрен татар халкы торган саен күбрәк ихтирам итә бара.

Хәзер сүзне некрологның авторы Гаяз Исхакыйга бирик. Язмада авторның тел-стилен сакларга тырышылды. Шулай да кайбер алынма сүзләрнең мәгънәсенә төшенүнең кыен булуын искәртү урынлы булыр.

«Габделкаюм әфәнденең вафаты

(Казандан мәктүб)

Беренче вә мәшһүр мөхәррирләремездән Габдулкаюм әфәнде әл Насыйри август 22 дә бу дар фәнәдән чинелде (бу дөньядан китте, — Ф. И.) вә җөмлә билеңләре яс мәгънәви я далдырды (һәм аны белгән барлык кешеләрне тирән кайгыга калдырды). Мәрхүм яздыклары вә нәшер итдекләре әсәре илә Русия вә госманлы мәмләкәтләрендә мәгълүм бер зат гали әлкадәр иде (олы бәһалы кеше иде — Ф. И.).

Лисан (тел — Ф. И.) вә әдәбиятемезә бөек хезмәт итмеш бу адәм казанлы улып 77 сәнәлек (еллык — Ф. И.) гомеренең илле сәнәсени мөхәррирлеккә вируб фәндән, тарихдан 38 төрле әсәр йазуб нәшер итмештер. «Ләһҗәй татари» исемендәге логате унбишь мең сүзи хавадыр (сүзлеге 15 мең сүзне эченә алды — Ф. И.). Дилемезиң балталама пек гуам уари улдыйгы бер заманда парийә башлуб дилемезең гүзәл бер дил улә биләхесини мидана куймыш мәрхүм Габделкаюм әфәндедер (Телебезнең тупас, кара халык теле булган бер заманда ул аның килачәктә гүзәл бер тел булачагын майданга куйды — Ф. И.). Йалңыз вә аның өйчен кыямәте кадәр йад улначакдыр (шуңа күрә аны кыяматкә кадәр онытмаслар — Ф. И.).

Казанның Сәгыйд хәзрәт мәдрәсәсендә тәхсил голум итдектән соңра (белем алганнан соң — Ф. И.) Каюм әфәнде духовная семинариядә татар диле мөгаллиме улуб унбишь сәнә хезмәт итмешдер. Ахыры бу җәһәтдән чикарылмыш иде. Ләкин семинариядә булындыйгы вакыт бер чук шәйләрдән хәбәр алуб вә русча бик мөкәммәл билуб әфкярине тәнвир итмеш иде (ләкин семинариядә чакта күп нәрсәләрдән белем алып һәм русчаны камил өйрәнеп укымышлылыгын арттырды — Ф. И.). Бәгъде мөстәшрык гаспудин Радлов химаясилә (аннан соң көнчыгышны өйрәнүче Радлов әфәнде ярдәме белән — Ф. И.) татарлар өчен ачылмыш школайә мөгаллим тәгайен иделмеш иде. Ләкин бу җәһәтдән дәхи гызәл улынуб җәмигъ атдеки мәгълүмат селйәсендә тәмам вакытны мөхәррирлеккә вирмеш иде (тагын моннан чыгарыгач, бөтен белемен мөхәррирлек эшенә бирде — Ф. И.). Иң ибтида татарча «Календарь» рузнама нәшер идән бу адәмдер (иң башлап календарь чыгаручы ул булды — Ф. И.). Календарь егерме бишь сәнә дәвам идә килмешер (календарен егерме биш ел буена чыгарды — Ф. И.).

(Рәхмәтулла галия) — (аллаһы тәгалә рәхмәт әйләсен — Ф. И.).

Мөхәммәд Гаяс әл Исхакый».

Халкыбызның тарихына, әдәбиятына һәм тел гыйлеменә кагылышлы әллә ниләр әллә кайларда, әллә кемнәрдә яшеренеп ята торгандыр әле. Аларны эзләргә, эзләргә, өйрәнергә, табарга кирәк. Моңысы инде безнең фәнни оешмаларыбыз һәм фәнни хезмәткәрләребез эше.

Фатих ИБРАҺИМОВ,
педагогия фәннәре кандидаты.

---

Фоат САДРИЕВ

# Адәм әүлиясе

«Казан утлары» журналында быел басылачак күләмле әсәрләрне күпләр белә — алар хакында алдан ук хәбәр итеп куйдык. Әмма ниятләр күпмедер үзгәрмәсә, тормыш тормыш булыр идемени? Редакциягә яңадан-яңа әсәрләр килә, аларның аеруча уңышлылары инде әллә кайчан нәүбәткә баскан бүтәннәрне кысрыклый башлый. Фоат Садриевның «Адәм әүлиясе» быел нәкъ менә шундый «әрсез» повесть булачак.

Ф. Садриевның «Адәм әүлиясе»н укыгач туган беренче хис—шатлык. Бу юлы ул әдәбиятыбыз өчен аеруча тансык сатирик повесть иҗат иткән. Көлдерергә көчәнмичә, азапланмыйча, бер-берсенә охшамаган әллә ничә образ барлыкка китергән. Вакыйгаларны гаҗәп оста үреп, туган телебез энҗе-мәрҗәннәрен урынында җемелдәтеп, каһарманнарының холык-фигылен, килеш-кыяфәтен истә калырлык юмарт детальләр аша сурәтләгән.

«Адәм әүлиясе» — авторның яңа иҗади сәләтен ача, әдәбиятыбызда Ш. Мөхәммәтов, М. Әмир традицияләрен дәвам иттерә торган әсәр. Безнең җитди, кырыс прозабызны ул шаянлык, тапкырлык, якты көлү белән баета.

Бу повесть елның икенче яртысында «Казан утлары»нда тулысынча басылачак. Әгәр сез институтка керергә маташкан беркатлы Әлфәрит, шәһәр чибәркәе Руфина, Әлфәритнең чая әнисе һәм хәйләкәр әтисе, шушы дүрт кеше вә башкалар арасында булган мәзәк, маҗаралар белән танышасыгыз, күзегездән яшь чыкканчы көләсегез килсә, әле моның чарасын күрергә вакыт бар: журналга язылу дәвам итә. Ә хәзергә шушы повестьның башын «Социалистик Татарстан»да укый торырга мөмкин.

Тәүфикъ ӘИДИ,
«Казан утлары» журналының проза бүлеге редакторы.

...Илгизә газ бирде, ул мотоциклның бишегенә сикерде дә Убырлы артыннан элдерттеләр. Альфред, аягүрә басып тибә-тибә:

— Кызурак, кызурак! —дип кычкырганда, бишекнең түбе җимерелеп төште, ул аның ике читенә ябышып, аяклары белән җирдән йөгерә башлады. Менә алар Мөштәфширә карчыкның ямаулы яшел итәге астына керделәр. Итәк, югары күтәрелеп, җилфер-җилфер килеп бара, кортканың ак төскә эре зәңгәр борчак төшкән ыштаны да күренә, тик нишләптер куып җитә, тота гына алмыйлар.

— Акчаны бир! —диде Альфред, аның итәгеннән эләктереп.

— Менә сиңа акча! — Мөштәфширә карчык конвертны авызына кабып чәйни башлады.

Альфред аның колакларын учлап алды да баш бармаклары белән авыз читен ике якка ерырга тотынды. Ләкин шул чак коточкыч хәл булды: Убырлының колаклары әрекмән яфраклары кебек тебе-тамыры белән йолкынып чыкты. Ул борынын шереп боргандай борып алды да, шаркылдап көлә-көлә, Альфредның авызына китереп төртте. Борын боз кебек салкын, лайлалы иде. Альфред тәкеренә-тәкеренә читкә йөгерде, Мөштәфширә карчык борынын болгый-болгый аны куарга керешә. Ул да булмады, борын, әле бер, әле икенче тишегеннән төтен бөркеп, пох-пох ата башлады, аткан саен Альфредның өстенә шыбырдап тозлы су коелды. Куыша торгач, алар Чалмыя елгасының иң текә, иң биек кызыл ярысуз. Сәгать ничә соң әле? Я аллам! Имтихан башланырга ярты сәгать вакыт калган! Ул бит кичә үк теге кешенең өенә барып шушы конвертны тапшырырга тиеш иде. Әнисе: ул кеше үзе институтта эшләми, диде, кемнәрнедер күреп, кемнәр ашадыр хәрәкәт итә, ул сине күреп, белеп калырга тиеш, диде. Бәлкем ул бәндә әле өеннән чыгып китмәгәндер? Очарга, тизрәк барып җитәргә! Юкса, бөтенесе бетә, җимерелә. Очарга, очарга, җир тишегеннән булса да табарга теге кешене!

Ул кабаланып юынгычка барды, кранны боруга, аның тишеге «пырых!» итеп пошкырып җибәрде, Альфредның болай да бер нечкә тамырда асылынып торган йөрәге өзелеп төшеп киткәндәй булды. Күп пошкыра торгач, краннан һиндстан чәе төсле су чыкты, бер чыкты, ике чыкты, аннары ашханәләрдәге чәйгә охшап ага башлады. Альфред бармак очлары белән күзенә шул суны тигереп-тигереп алды да өстенә киенде. Конвертны джинсы чалбарының арткы кесәсенә салып бикен тартты, аның өстеннән әнисе таккан каптырманы эләктерде.

Ул физика китабын тотты да, урамга йөгереп чыкты. Такси-мазар күренмәде, трамвайга утырып, Куйбышев мәйданына кадәр төште, аннары автобуска күчте. Барасы юл ерак, теге кеше Дербышки поселогында ук яши иде. Альфред физика китабын ачты да укый башлады: «Интерференция нәтиҗәсе (нәтиҗә тирбәнешләрнең көчәюе яки кимүе) яктылыкның эллегә төшү почмагына, элләнең калынлыгына һәм дулкын озынлыгына бәйшы белә. Нишләргә? Кычкырыргамы? Пычак белән чәнчерләр дә төшеп калырлар. Алда троллейбуска утырып маташучы кешеләр күренде. Автобус та нәкъ шунда туктады. Альфред кешеләрне бәреп кинәт ишеккә ыргылды, сикереп тә төште, инде ишекләре ябыла башлаган троллейбуска кереп кысылды. Теге егет автобустан төшә дә алмыйча калды. Альфред җиңел сулап куйды, тез буыннарының дер-дер калтыравын сизде. Кесәсен капшап карады, шпана акчаны ала алмаган иде. Бераз баргач, төшеп, такси тотты. Җаны тынычлап, тиешле йортка барып җитте. Менә теге кешенең фатиры. Ах, өйдә булса! Ул кара төймәгә ике мәртәбә басты, эчтә «теллин, теллин» дигән матур тавыш ишетелде. Шул матур тавыш артыннан матур елмаеп бер абый чыксын да: «Килеп җиттеңмени, Альфред апаем!» дип кочаклап алсын иде. Әмма беркем дә чыкмады. Альфред сәдәфкә берьюлы өч мәртәбә басты. Ишек артында эт өргән тавыш яңгырады. Аның эченә җылы керде. Яңа уяналар бугай, шәһәр кешесе озак йоклый бит ул. Ләкин кабат эт тә өрмәде, ишек тә ачылмады. Өченче мәртәбәсендә Альфред бик озак «теллин-теллин» иттереп торды, аңа кушылып эт әрде дә әрде. Ниһаять, аның күңелендә өметле шатлык уятып йозак шалт-шылт итте һәм янәшәдәге ишек ачылып китте. Тартылган чылбыр артында бик нык җыерылган эчке күлмәкле бер карт хатын басып тора иде.

— Ну чиго двонишь, чиго двонишь?! — Хатынның киптерергә элеп куелган мүкне хәтерләтүче озын чәчләре ара-

---

Яңа китап

# ИСЕМЕ МАТУР

Яшь ана чибәр генә бәби алып кайткан. Яшь ата, башын кашып, аңа исем уйлый. Бу — Гомәр Саттаровның Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан яңа китабының тышлыгын бизәүче рәсем. Китапка «Исемең матур, кемнәр куйган?» дип укучыны җәлеп итәрлек исем бирелгән.

Аның кереше болай башлана.

«Бала туды. Дөньяга яңа кеше килде. Өйгә, гаиләгә яңа ямь, ... куаныч, бәхет ... Шуның белән ...

заманнардан алып бүгенге көнгә чаклы исемнәребезнең үсеш эволюциясен тикшереп, татарларда исем кушу принципларын ачыклаган. Күп исемнәрнең мәгънәләрен аңлаткан. Бу — бик кирәк, чөнки мәгънәсен белми кушкан исемнәр соңыннан шатлык китермәскә мөмкин.

Билгеле, балага сирәк ишетелгән оригиналь исем бирү отышлы. Ләкин халык яңарак исемнәрне сайларга яратучан. Нәтиҗәдә яңа дип табылган исемнәр дә артык ...

---

«1918 елның август аенда ак чехлар контрреволюцион офицерлар җитәкчелегендә Чистайга бәреп керделәр... Ак бандитлар өяз башкарма комитеты членнары Огородников һәм Воскресенский, мөселман комиссариаты членнары Бәхтияров, Миңнебаев һәм Чабдаров иптәшләрне дә газаплап үтерделәр...» Комсомол ветераны, Татарстанда комсомол хәрәкәте активистларыннан берсе, Союз күләмендәге персональ пенсионер булган һәм соңгы вакытта Мәскәүдә яшәгән мәрхүм Нур Сәйфинең (без аның белән хатлар алышкан идек) Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Коммунизм таңында» китабыннан (Казан, 1967 ел, 19 нчы бит) алынган юллар бу. Мин әлеге язмамда, газета укучыларын алда санап үтелгән кешеләрнең берсе — авылдашым Минабетдин Миңнебаев белән тулырак таныштырырга булдым.

# КӨРӘШҮЧЕЛӘРНЕ ОНЫТЫРГА ХАКЫБЫЗ ЮК

1918 елның мартында Чистайда мөселман (татар) крестьяннарының беренче өяз съезды чакырыла. Делегатлар арасында Каргалы волостеннан Минабетдин ...

аннан-моннан сорау алгач, берничә солдат аны авылның коньяк читенә алып чыга. Аннары алар, Аръяк күле ягына күрсәтеп:

бояр җирләрен крестьяннарга бүлеп бирүне тормышка ашыруда һәм башка чараларны үткәрүдә җирле власть оешмаларына зур ярдәм күрсәтә. Туган авылы Каргалыда ярлылар комитеты оештыручыларның да берсе була.

Әмма 1918 елның август башында акгвардиячеләр һәм фетнә күтәргән ак чехлар корпусы Чистайны басып ала. Шул моменттан файдаланып, биредәге җирле буржуазия дә баш калкыта. Шулай итеп, шәһәрдә һәм өяздә кара террор башлана.

Сентябрь урталарында ак бандаларның бер өлеше Каргалыда туктала. Шуннан алда гына Минабетдин ата-аналарының, гаиләсенең хәлен белү һәм волость документларын алып китү өчен авылга кайткан була. Шул вакыт чехлар аны авыл куштаннары ярдәмендә әтисенең өендә кулга алалар.

Түрәләр янында тиз-тиз генә

ТАССР 70

кытында аны Миңнебай абзый карамагына калдырып, үзе Себергә эш эзләп китәргә мәҗбүр була. Дөньялар бераз җайлана төшкәч кенә ана белән кыз яңадан бергә булалар һәм 1973 елга кадәр Пермь өлкәсенең Лысьва шәһәрендә яшиләр. Хиҗәстә апа вафат булгач, Һаҗәр яңадан Татарстанга кайта һәм байтак еллар Бөгелмәдә яши.

Аннан соң Пермь өлкәсенең Чусовая шәһәренә күчеп китә. Аларның гаиләсендә хәзер дә Каргалы волость башкарма комитеты тарафыннан 1918 елның 17 июлендә Миңнебаев Минабетдин исеменә бирелгән вакытлы паспорт саклана. Әлеге документтагы мәгълүматларга караганда, ул вакытта М. Миңнебаевка 32 яшь булган.

Әйе, Минабетдин Миңнебаев — Чистай өязендә акгвардиячеләр һәм ак чехлар терроры вакытында Совет властен аякка бастыру, татар халкына үз дәүләтчелеген төзү өчен көрәштә һәлак булган активистларның берсе. Районның, шул исәптән Каргалы авылының олы буын кешеләре аны хәзер ...

Яңа китап

# ИСЕМЕ МАТУР

Яшь ана чибәр генә бәби алып кайткан. Яшь ата, башын кашып, аңа исем уйлый. Бу — Гомәр Саттаровның Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан яңа китабының тышлыгын бизәүче рәсем. Китапка «Исемең матур, кемнәр куйган?» дип укучыны җәлеп итәрлек исем бирелгән.

Аның кереше болай башланып китә.

«Бала туды. Дөньяга яңа кеше килде. Өйгә, гаиләгә яңа ямь, юаныч, куаныч, бәхет өстәлде. Шуның белән бергә яңа туган сабый ата-анасына өстәмә мәшәкатьләр дә китерде. Аларның иң беренчесе — балага исем кушу. Аңа нинди исем бирергә? Бу сорау һәрбер ата-ананы, баланың өлкән туганнарын, кардәш-тумачаларын борчый. Чөнки исем кешегә бер генә мәртәбә бирелә, һәм ул аның гомерлек юлдашына әверелә. Һәр кеше үз исеменә шулкадәр күнегә ки, ул аның туган теленең иң якын, иң газиз, иң кадерле сүзе булып тоела».

Менә шушы кеше гомере буена йөртә торган исемне бирүдә ата-ана зур җаваплылык тоярга тиеш. Исем яңгырашы ягыннан да, эчтәлеге белән дә чын-чыннан матур булсын. Андый исемнәрне каян алырга соң? Һәркем аны үзе уйлап чыгара аламы?

Аерым чорларда балаларга «Рево», «Люция», «Ленинза» кебек ата-ана үзе уйлап чыгарган исемнәр дә бирелде. Ләкин андый исемнәрнең бик күбесе уңышлы булып чыкмады. Аларда милли үзенчәлек сизелми. «Маркс Хәйдәрев» кебек Европа илләреннән алынган кайбер исемнәр дә халыкта урынлы елмаю уята. Сайларга теләсәң, бездә борын-борыннан килә торган традицион матур исемнәр дә аз түгел ич. Күренекле татар-башкорт шагыйре Шәехзадә Бабич әйткәнчә, кеше исемнәре — гаҗәеп бер бакча ул. Профессор Гомәр Саттаров шул бакчага кергән дә, зур фәнни-тикшеренү эше алып барган. Ул борынгы заманнардан алып бүгенге көнгә чаклы исемнәребезнең үсеш эволюциясен тикшереп, татарларда исем кушу принципларын ачыклаган. Күп исемнәрнең мәгънәләрен аңлаткан. Бу — бик кирәк, чөнки мәгънәсен белми кушкан исемнәр соңыннан шатлык китермәскә мөмкин.

Билгеле, балага сирәк ишетелгән оригиналь исем бирү отышлы. Ләкин халык яңарак исемнәрне сайларга яратучан. Нәтиҗәдә яңа дип табылган исемнәр дә артык күбәеп китә һәм аларның бәясе «төшә». Хәзер урта яшьтәге татар хатын-кызлары арасында һәр унынчысы Роза исемле. Альберт исемле ир-егетләр дә санап бетергесез. 1967 елда Татарстанда гына да 300 малайга Альберт исеме кушылган булган.

Автор бу күренешләргә бәя бирү белән бергә, балаларыбызга милли, зәвыклы исемнәрне күбрәк бирүгә игътибарны юнәлдерә.

Китапка 5 меңнән артык татар исемен теркәгән кушымта бирелүе дә уңышлы. Беренчедән, ата-аналар аннан үзләре теләгән исемне сайлап ала алса, икенчедән, ЗАГСлар һәм башка рәсми органнар өчен аларның русча ничек язылышы да күрсәтелгән. Бу — бик әһәмиятле, чөнки моңарчы татар исемнәренең русча язылышында бик күп ялгышларга юл куела иде. Шушы ялгышлар кешеләрнең паспортларына күчеп, шәхесне еш кына кыен хәлгә куя иде.

Моңарчы шулай ук исемнәрнең төрле төбәкләрдә Абдулла — Габдулла, Айнетдин — Гайнетдин рәвешендә төрлечә язылуы традиция буларак яшәп килде. Г. Саттаров бу төрлелекне бетерү максатында исемнең килеп чыгышы ягыннан дөрес вариантын гына (Габдулла, Гайнетдин, Гайнижамал) теркәгән. ЗАГСлар һәм паспорт өстәлләре бу кулланмадан киң файдалансалар, документлар тутыруда, һичшиксез, төгәллеккә ирешербез.

З. ШӘФИГУЛЛИН.

Сәрия ВИЛЬДАНОВА

## Күпме яшәр?

Үз кабыгын үзе алыштырып
Яши әле һаман бюрократ.
Мыштым йөри,
Җае чыга калса,
Елан булып әверелә кабат.
Тәкәллефле булып күренә күзгә,
Җаны боздай булган «беек» хуҗа.
Дилбегәне оста тота белә,
Утта янмый, судан коры чыга.
Бүлеп-бүлеп сата тозсыз җанын,
Өреп тутыра шулай төссез данын.
Әхлагына төшкән нәфес корты,
«Оҗмах» булып күренә торган йорты.
Әшнәләргә өләшә кеше хакын,
Күзләрдә — боз, күңеле — утлы ялкын.
Күпме яшәр тәти бюрократ
Дан хакына керле җанын сатып?

...ров, Миңнебаев һәм Чабдаров иптәшләрне дә газаплап үтерделәр...» Комсомол ветераны, Татарстанда комсомол хәрәкәте активистларыннан берсе, Союз күләмендәге персональ пенсионер булган һәм соңгы вакытта Мәскәүдә яшәгән мәрхүм Нур Сәйфинең (без аның белән хатлар алышкан идек) Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Коммунизм таңында» китабыннан (Казан, 1967 ел, 19 нчы бит) алынган юллар бу. Мин әлеге язмамда, газета укучыларын алда санап үтелгән кешеләрнең берсе — авылдашым Минабетдин Миңнебаев белән тулырак таныштырырга булдым.

...1918 елның август башында ак гвардиячеләр һәм фетнә күтәргән ак чехлар корпусы Чистайны басып ала. Шул моменттан файдаланып, бирдәге җирле буржуазия дә баш калкыта. Шулай итеп, шәһәрдә һәм өяздә кара террор башлана.

Сентябрь урталарында ак бандаларның бер өлеше Каргалыда туктала. Шуннан алда гына Минабетдин ата-аналарының, гаиләсенең хәлен белү һәм волость документларын алып китү өчен авылга кайткан була. Шул вакыт чехлар аны авыл куштаннары ярдәмендә әтисенең өендә кулга алалар.

Түрәләр янында тиз-тиз генә

# КӨРӘШҮЧЕЛӘРНЕ ОНЫТЫРГА ХАКЫБЫЗ ЮК

1918 елның мартында Чистайда мөселман (татар) крестьяннарының беренче өяз съезды чакырыла. Делегатлар арасында Каргалы волостеннан Минабетдин Миңнебаев та була.

Алгарак китеп булса да шуны әйтим, югарыда телгә алынган авторның истәлекләренә караганда, бу съездда күренекле татар революционеры Мулланур Вахитов та катнаша һәм тирән эчтәлекле чыгыш ясый.

Съезд көн тәртибендәге төп мәсьәләләрне караганнан соң, өяз башкарма комитеты каршында Чистай өяз мөселман комиссариатын сайлый. Аның составына Яүширмә авылыннан Нур Сәйфи, Каргалыдан Минабетдин Миңнебаев, Татар Ялтаныннан революционер Кирам Хәмзин (хәзер Чистай шәһәре урамнарының берсе аның исеме белән атала) һәм Мөхлис Билалов (1918 елдан Коммунистлар партиясе члены, мөселман коммунистларының 1918 елның ноябрендә Мәскәүдә үткәрелгән беренче съезды делегаты), башка төбәкләрдән Бахтияров, Чабдаров, Җамалетдинов, Әхмәдиев, Сагъдиев һәм башкалар кертелә. Комиссариатның рәисе итеп К. Хәмзин сайлана.

Комиссариат оештырылуның беренче көннәреннән үк, аның әгъзалары җиң сызганып эшкә керешәләр. 1918 елның апрель башларында, мәсәлән, комиссариат волостьларга агитаторлар җибәрә. Алар арасында комиссариат әгъзалары үзләре дә булалар. Аларның төп бурычы Советларның икенче Бөтенроссия съезды кабул иткән декретларның, аерым алганда крестьяннарга җир бирү турындагы декретның әһәмиятен, Коммунистлар партиясенең эчке һәм тышкы политикасын авыллардагы барлык хезмәт ияләренә җиткерүдән гыйбарәт була.

Шул уңайдан М. Миңнебаев Түбән Никитино (хәзерге Ленино) авылына бара. Ул анда аннан-моннан сорау алгач, берничә солдат аны авылның көньяк читенә алып чыга. Аннары алар, Аръяк күле ягына күрсәтеп:

— Бар, яхшы чакта качып кал! — дип төртеп җибәрәләр.

Минабетдин ышаныр-ышанмас кына авыл очына таба йөгереп китә. Ә бераздан тегеләр берсеннән-берсе уздырып, көлешә-көлешә (янәсе, кем тизрәк итеп ата) аңа мылтыклардан ут яудыра башлыйлар. Минабетдин, эшнең нәрсәдә икәнен аңлап, зигзаг ясап йөгерә һәм якындагы бакчага кереп эзне югалту өчен читәнгә үрмәли башлый. Шул вакыт аңа пуля тия, һәм ул егылып төшә. Шулай да, барлык көчен җыеп, җирдән шуышып баруын дәвам итә. Әмма аның артыннан куып җиткән бандитлар Миңнебаевны штыклар белән чәнечкәләп үтерәләр. Аннары киемнәрен салдырып алып, үзен авыл уртасындагы бер келәт янына китереп ташлыйлар. Янәсе, күрегез, совет яклы кешеләрнең барысы белән дә шулай булачак. Әмма бу вакытта аларның үзләренең дә көннәре санаулы гына калган була...

Минабетдинның фаҗигале үлеме турындагы хәбәр әтисе Миңнебайга да бик тиз барып ирешә. Ул улының җансыз гәүдәсен үзләренә алып кайта. Икенче көнне, ак бандалар киткәч, авыл халкы Минабетдинны Чистай юлына чыгып китә торган юл буендагы беренче (зур) зиратта җирлиләр. Һәм шул көннәрдә комсомоллар аның турында бәет чыгаралар. (Кызганыч, никадәр генә эзләсәм дә, бәетнең тулы текстын хәтерләүчене таба алмадым).

Инде шунысын әйтим, әлеге язманы хәзерләп йөргәндә миңа очраклы рәвештә М. Миңнебаевның бердәнбер кызы Һаҗәр (әтисе һәлак булганда, ул нибары ике атналык кына була) белән очрашырга туры килде. Минабетдинның хатыны Хиҗҗәстә, 1921 елгы ачлык вакытында аны Миңнебай абзый карамагына калдырып, үзе Себергә эш эзләп китәргә мәҗбүр була. Дөньялар бераз җайлана төшкәч кенә ана белән кыз яңадан бергә булалар һәм 1973 елга кадәр Пермь өлкәсенең Лысьва шәһәрендә яшиләр. Хиҗҗәстә апа вафат булгач, Һаҗәр яңадан Татарстанга кайта һәм шактый еллар Бөгелмәдә яши.

Аннан соң Пермь өлкәсенең Чусовая шәһәренә күчеп китә. Аларның гаиләсендә хәзер дә Каргалы волость башкарма комитеты тарафыннан 1918 елның 17 июлендә Миңнебаев Минабетдин исеменә бирелгән вакытлы паспорт саклана. Әлеге документтагы мәгълүматларга караганда, ул вакытта М. Миңнебаевка 32 яшь булган.

Әйе, Минабетдин Миңнебаев — Чистай өязендә акгвардиячеләр һәм ак чехлар терроры вакытында Совет властен аякка бастыру, татар халкына үз дәүләтчелеген төзү өчен көрәштә һәлак булган активистларның берсе. Районның, шул исәптән Каргалы авылының олы буын кешеләре аны хәзер дә зур хөрмәт һәм ихтирам белән искә алалар. Әмма аның һәм Каргалыда Совет властен урнаштыру вакытында һәлак булган башка шундый кешеләрнең якты истәлеген мәңгеләштерү, аларның исемнәрен киләчәк буыннарга җиткерү өчен авылда бернәрсә дә эшләнми диярлек. Югыйсә, бирдәге урамнарга аларның исемнәрен кушу яки элекке волость башкарма комитеты бинасына мемориаль такталар куелса, нинди изге эш башкарылыр иде бит. Шунысы тагын да кызганыч, Минабетдинның кабере дә тәртиптә түгел: тирәсе тотылмаган, язу куелмаган... Хәтта аның күмелгән урынын да хәзер инде Минабетдинның туганнан туганы, Казанда яшәүче укытучы-пенсионер Раисә Миңнебаева һәм кызы Һаҗәр генә белә торгандыр.

Моннан биш ел элек мин болар турында Чистай газетасына язып чыккан идем. Әмма игътибарга алучы булмады. Шундый битарафлыкка күңелем түзмичә, мин бу мәсьәләне республика газетасында яңадан күтәреп чыгарга һәм Каргалы авылы партия, совет органнарының игътибарын тагын-тагын бер тапкыр шуңа юнәлтергә кирәк дип таптым. Чөнки, беркем дә, бернәрсә дә онытылырга тиеш түгел бит!

Фәргать НУРУЛЛИН,
СССР Журналистлар берлеге әгъзасы, Бөек Ватан сугышы ветераны.

РӘСЕМДӘ: Чистай өяз мөселман комитетының бер төркем әгъзалары. Март, 1918 ел. Уңнан беренче (утырган) Минабетдин Миңнебаев.

Искәрмә: рәсемнең төп нөсхәсе Чистай крайны өйрәнү музеенда экспозициядә.

...лептәр куып җитә, тота гына алмыйлар.

— Акчаны бир! — диде Альфред, аның итәгеннән эләктереп.

— Менә сиңа акча! — Мөштәфширә карчык конвертны авызына кабып чәйни башлады.

Альфред аның колакларын учлап алды да баш бармаклары белән авыз читен ике якка ерырга тотынды. Ләкин шул чак коточкыч хәл булды: Убырлының колаклары әрекмән яфраклары кебек төбетамыры белән йолкынып чыкты. Ул борынын шөреп боргандай борып алды да, шаркылдап көлә-көлә, Альфредның авызына китереп тертте. Борын боз кебек салкын, лайлалы иде. Альфред тәкерәнә-тәкерәнә читкә йөгерде, Мөштәфширә карчык борынын болгый-болгый аны куарга керешге. Ул да булмады, борын, әле бер, әле икенче тишегеннән тәтен бөркеп, пох-пох ата башлады, аткан саен Альфредның өстенә шыбырдап тозлы су коелды. Куыша торгач, алар Чалмыя елгасының иң текә, иң биек кызыл ярына килеп җиттеләр. Убырлы аска очты. Альфред бик кызу йөгереп килде дә, ярдан аяклары белән этенеп, аның артыннан аска сикерде һәм... башы белән дыңк итеп өстәл читенә бәрелде. Аның маңгае тумыштан каты, ә агач аннан да катырак булганлыктан, бәрелү көче йокысын шундук ачты, өстәлдәге бер кефир шешәсе, эчендәге сыеклыгын агыза-агыза тәгәрәп килеп, борынына төшкәч, аның күзеннән утлар күренде. Дөньясының асты өскә килгере! Шушы гына җитмәгән иде!

— Уф-ффф! — диде ул, башын эчтән лом белән чокуларын тоеп. Суккан саен өттереп чатный... Ул авыз, ул тел!.. Дөньяда булырга мөмкин булган иң тәмсез әйберләрнең бөтенесен җыеп авыз эченә изгәннәр дә телне шуның белән аңкауга ябыштырганнар диярсең... Аның ак колгадай гәүдәсе, тире астында гел шуышып торучы бугаз төене, озын беләкләре, эре чәчкә төшерелгән трусигыннан ике кәрәк сабы шикелле тырпаеп чыккан аяклары манма су һәм җиңелчә генә калтырый иде. Әле генә күргән төштән ул берничек тә айный алмады. Каян килеп керә диген шундый тузга язмаган чүп-чар. Убырлы Мөштәфширә төшкә керсә, юньлегә түгел — моны бөтен авыл шулай ди. Тукта, тукта, ул бит акчаны алды. Әгәр чыннан да... Альфред кабаланып мендәр астына кулын тыкты һәм эсселе-суыклы булып китте. Әнисе авылдан биреп җибәргән конверт юк иде. Аның эче «жу-у!» итте. Алганнар! Ул тизләнеп мендәрнең икенче ягын әйләндерде, матрац асларын актарды. Әллә монда куймадымы? Кабаланып караваттан төште, уң аягы кефир өстеннән шуып китеп, чак кына чалкан китмәде. Ул, табанын идәнгә ышкып корыта-корыта, зур сары портфеле янына килде, аның эчендәге һәр әйберне селкеп чыкты — конверт юк иде. Урын-җирләрен туздырып атты — акча табылмады. Менә ни өчен төшкә кергән икән ул Убырлы тәре! Болай булгач, мәшәкатьләнеп Казанга килүнең мәгънәсе дә калмады. Шулчак аның күзе шифоньер өстендәге физика китабына төште. Болай гына, аптыраганнан гына ачып караса, конверт шунда иде. Аның чыгып барган җаны кире керде. Болай булгач, өмет бар диген...

...барга тегә кешене!

Ул кабаланып юынгычка барды, кранны боруга, аның тишеге «пырых!» итеп пошкырып җибәрде, Альфредның болай да бер нечкә тамырда асылынып торган йөрәге өзелеп төшеп киткәндәй булды. Күп пошкыра торгач, краннан һиндстан чәе төсле су чыкты, бер чыкты, ике чыкты, аннары ашханәләрдәге чәйгә охшап ага башлады. Альфред бармак очлары белән күзенә шул суны тигереп-тигереп алды да өстенә киенде. Конвертны джинсы чалбарының арткы кесәсенә салып биген тартты, аның өстеннән әнисе таккан каптырманы эләктерде.

Ул физика китабын тотты да, урамга йөгереп чыкты. Такси-мазар күренмәде, трамвайга утырып, Куйбышев мәйданына кадәр төште, аннары автобуска күчте. Барасы юл ерак, теге кеше Дербышки поселогында ук яши иде. Альфред физика китабын ачты да укый башлады: «Интерференция нәтиҗәсе (нәтиҗә тирбәнешләрнең көчәюе яки кимүе) яктылыкның элпәгә төшү почмагына, элпәнең калынлыгына һәм дулкын озынлыгына бәйле. Әгәр сынган 2 дулкыны кайтарылган 1 дулкынынннан бөтен сандагы дулкын озынлыгына соңга калса, яктылыкның көчәюе күзәтелә. Икенче дулкын беренчесеннән ярты дулкын озынлыгына яки ярымдулкыннарның так санына соңга калган очракта исә, яктылык кими». Ни соң бу? Моннан да күңелсез фән бар микән? Әгәр шушы физика дигән нәрсә уйлап чыгарылмаса, җир йөзендә тормыш нинди күңелле булыр иде. Кара инде: «Элпәнең тышкы һәм эчке өслекләреннән кайтарылган дулкыннар бер үк яктылык бәйләменең өлешләре булганга күрә ,когерент булалар. Нурландыручы һәр атом дулкыннары цугын элпә башта икегә аера, аннары бу өлешләр бергә туры китереләләр һәм интерференцияләнәләр». Алар моны үттеләр микәнни соң? Ул тирән сулап китабын ябып куйды. Бүген инде күпме генә укысаң да, үз көчең белән ерып чыга торган нәрсә түгел бу. Бөтен өмет теге кешедә. Бүген я бетәсең, я каласың. Я Казан, я... о, ул хакта уйларга да куркыныч! Автобуста кеше күзгә күренеп арта барды, Альфред урынын бер әбигә бирде. Кайсыдыр тукталышта бик күп кеше керде, басып торуы да кыенлашты. Шул чак Альфред түгәрәк йөзле, түгәрәк беләкле, озын чәчле бер егетнең үзенә елышуын тойды. Егетнең кулы иң элек арка тирәсенә тиеп-тиеп үтте, аннары туп-туры теге кесә турына төшеп капшанды, ботка күчте, тагын теге конверт салынган кесәгә менде. Альфредның бөтен тәне куркудан җиңелчә калтырый башлады. Әнисе джинсысының арткы кесәсенә каптырма таккач, Альфред, кеше көлдермә, дип аны орышкан иде. Менә хәзер әнисенең мең мәртәбә хаклы булганлыгын аңлады ул. Теге егет үзенең кайнар гәүдәсе белән тәмам сыланды, тирләгән беләкләрен аның беләгенә терәде, хушбуй исе сеңгән чәчләренең Альфредның муенына тулуын, кайнар сулышын аның колагына өрүен дә сизмәде.

— Әйдә, төшәбезме? — диде карак ике кулын аның ике боты тирәсендә йөртеп.

Ул борылырга да куркып аңа күзенең чите белән карап алды. Егет елмаеп ике мәртәбә каш сикертте. «Беттем!» дип уйлады Альфред. Аларның ялгыз йөрмәгәнен ул ях...

...иде. Бераз баргач, такси тотты. Җиңел тынычланып, тиешле йортка барып җитте. Менә теге кешенең фатиры. Ах, әйдә булса! Ул җәрә төймәгә ике мәртәбә басты, эчтә «теллин, теллин» дигән матур тавыш ишетелде. Шул матур тавыш артыннан матур елмаеп бер абый чыксын да: «Килеп җиттеңмени, Альфред апаем!» дип кочаклап алсын иде. Әмма беркем дә чыкмады. Альфред сәдәфкә берьюлы өч мәртәбә басты. Ишек артында эт өргән тавыш яңгырады. Аның эченә җылы керде. Яңа уяналар бугай, шәһәр кешесе озак йоклый бит ул. Ләкин кабат эт тә өрмәде, ишек тә ачылмады. Өченче мәртәбәсендә Альфред бик озак «теллин-теллин» иттереп торды, аңа кушылып эт өрде дә өрде. Ниһаять, аның күңелендә өметле шатлык уятып йозак шалт-шылт итте һәм янәшәдәге ишек ачылып китте. Тартылган чылбыр артында бик нык җыерылган эчке күлмәкле бер карт хатын басып тора иде.

— Ну чиго двонишь, чиго двонишь?! — Хатынның киптерергә элеп куелган мүкне хәтерләтүче озын чәчләре арасыннан күренеп торучы сыңар күзе сварка утыдай ялтырап-ялтырап алды. — Аптуринт шту-ли?! Рәже ни бидишь его дума ниту?! Ә?! Вәйт бежобразие, и выхотнуй пакуя ни дают суббаки! Ни сосед, а ысболочь!

Хатынның тутырылган турсыктай күкрәкләре турындагы чылбыр бушады да ишек шартлап ябылды.

Альфред бу йорттан чыкса да чыкты, чыкмаса да чыкты, автобуска утырса да утырды, утырмаса да утырды. Инде нишләргә? Имтиханны ничек булса да тапшырырга кирәк. Бәлкем теге кеше хәсрәтен күреп куйгандыр? Ул бит Альфредның исем-фамилиясен белә. Тот капчыгыңны, конверттан башка куйды ди. Ни булса да үзеңә кала хәзер. Үлеп җитеп, күз яшьләре коеп, ялынып-ялварып булса да тапшырырга. Иң соңгы кеше булып, укытучылар тәмам арып-алҗып беткәч керергә. Башка юл юк. Бәлкем берәрсе шпаргалка бирер...

Ул иң элек институтның бер җиренә барып, учлап-учлап су эчте. Су җылы, тәмсез, күңелне болгата иде. Аннары имтихан ала торган аудиториягә күтәрелде. Я хода! Хәлләр бер дә әйбәт түгел икән монда. Бөтенесенең чыраена, күзләренә курку сөреме сарган. Бер өлеше фил сөяге төсле зур ишек каршына өелгән, икенчеләре коридор буйлап чәчелгән. Кайберләре, көзге чебешләрне хәтерләтеп, стена буйларына, тәрәзә төпләренә сыенып бөрешкәннәр. Менә саргылт ишек ачылып китте дә аннан кызарып-пешкән бер кыз чәчрәп чыкты һәм елый-елый читкә йөгерде. Кемдер өметсез тавыш белән:

— Бу да бирә алмагач! — дип акырды.

Ишектә йөзе кәфен төсле ап-ак бераү күренде. Бу — Альфред белән бер бүлмәдә урнашкан егет иде. Аны корт күчедәй сырып алдылар, мең төрле сорау яуды:

— Ничек, ничек?
— Бирә алдыңмы?
— Нинди сорау туры килде?
— Әйт инде тизрәк!
— Ничәле куйды, ничәле?!

Егет муенына кулы белән аркылы сызып җибәрде дә:

— Рәттән суялар! — диде.

Бөтенесе «ах» итте, шау-шу купты...

(Ахыры бар).

Яшь талантлар

# ГАРМУН КЕЧКЕНӘ БУЛСА ДА...

«Халкыбызның оста гармунчылары Фәйзи Биккинин, Гали Җәмлиханов, Фәйзи Садыйков, Оркыя Ибраһимова, Мостафа Сәлахетдинов, Рәшит Мостафин кебек талантлар исемлегенә гармунчы Рөстәм Вәлиев исемен дә кертергә була. Сәләтле шушы егет иҗаты турында киңрәк итеп сөйләсәгез иде...»

Әлмәт шәһәрендә яшәүче Г. Әхмәтвәлиевадан шундый хат килде. Әлеге үтенечне канәгатьләндерү өчен тагын бер уңай сәбәп килеп чыкты. Горький шәһәрендә уздырылган Бөтенроссия конкурсында Татар дәүләт филармониясе артисты Рөстәм Вәлиев, милли уен коралларында чыгыш ясап, дипломга һәм конкурсның дипломанты исеменә лаек булды.

Жигули тауларына сыеныл утырган Самара (хәзерге Куйбышев) бик күп талантларны хәтерли. Монда руслар белән бергә, татарлар, мордвалар, чувашлар да олы сәнгатькә юл алганнар. Әмма азчылык милләтләрнең талантлары чын мәгънәсендә соңгы елларда — үзгәртеп корулар башлангач киң ачылып китте. Казан тамашачылары яхшы хәтерли булыр: моннан берничә ел элек Куйбышев өлкәсеннән килгән «Ялкынлы яшьлек» (Металлурглар культура сарае каршында) ансамбле үзенең чыгышы белән халыкны шаккатырган иде.

Баянчы Рөстәм Вәлиев тә профессиональ сәнгатькә менә шушы танылган коллективтан килде. Дөресрәге, башта урта һәм музыка мәктәбен, аннан соң Куйбышевтагы музыка училищесын тәмамлады. Аннан филармониябезнең Илһам Шакиров җитәкчелегендәге концерт бригадасында баян уйнады. Шулчак Илһам абыйсы аның берничә төр уен коралында — курайда, кубызда, концерт гармуннарында, хәтта немецларның авыз гармунында да уйнавын күреп ала.

— Энем, сиңа шушы юнәлештә осталыгыңны чарларга кирәк, — дигән киңәш бирә ул аңа. — Андый сәнгать осталары да кирәк!

Танылган җырчыбызның киңәшен тотып, Рөстәм атаклы гармунчы Гали абый Җәмлиханов янына китә. Аның белән аралашу, халкыбыз көйләрен башкаруның төрле алымнарына төшенү аңа кабатланмас иҗади канат бирә. Шул вакытта ул Казан консерваториясенең баян классын да тәмамларга өлгерә, осталыгы да камилләшә.

Ул республикабыз, ил буйлап гастрольләрдә йөргәндә милли уен кораллары ясаучыларны эзли һәм гаҗәеп осталарга юлыга. Кайчандыр Казан музыка уен кораллары фабрикасында эшләгән оста Салих Шәйдуллин, Куйбышев өлкәсенең Ярмәк авылыннан Гали Гәрәев, үзешчән композитор Ифрат Хисамов яшь талантка төрледән-төрле уен кораллары ясап бирүдә ярдәм итәләр, аның иҗат офыкларын киңәйтүдә турыдан-туры булышалар.

— Ә шулай да иҗат чишмәң кайчан, кайда ургып китте? — дип сорадык Рөстәмнән. Аның җавабы әзер иде кебек. Ул бер дә икеләнмичә:

— Әлбәттә, сабый чакта, гаиләбездә. Әти янында. Шофер ул безнең. ЗИЛ машинасында. Әниебез дә җырларга ярата. Менә шулар янында һәвәсләнеп киттем инде. Җырладым да, аннан гармунда уйный башладым. Гомумән, безнең гаиләдән үзе бер ансамбль төзеп булыр иде. Минем Ринат исемле энем ашханәдә пешекче булып эшли. Буш вакытлары булган саен культура сараена ашыга. Бии ул. Үзләренең ансамбльләре белән Япониядә, Кореяда, Болгариядә, Румыниядә гастрольләрдә булып кайттылар. — дип сокланып сөйли Рөстәм Вәлиев. Мин ышанам: әле ул да шушы эреле-ваклы гармуннары, курай-кубызлары белән дөньяны шаккатырыр.

**С. ХӘЙРЕТДИНОВ.**

**РӘСЕМДӘ: яшь талант Р. Вәлиев концерт вакытында.**

Хат эзеннән

# БАЛАЛАР ӨЛЕШЕНӘ КАГЫЛМЫЙК

Үзара тарткалашу бик озакка китте. Югыйсә, ул кадәр баш ватарлык, очына чыкмаслык нәрсәләр тирәсендә бармый бәхәс. Туймәт авылы кешеләре белән район җитәкчеләре арасында березлексез барган низагны һәркем үзенчә хәл итәргә тырыша. Югары оешмалар исеменә берәзлексез шикаятьләр ава тора. Аңа җавап бирергә өлгермиләр, икенчесе килеп төшә. Шулай итеп бу бәхәс ике ел дәвам итә.

Эш нәрсәдә соң? Әйткәнебезчә, әллә нәрсәдә түгел: авыл кешеләре участок больницасы ачтыруны сорыйлар. Кая гына мөрәҗәгать итмәгәннәр инде алар?! Район Советы башкарма комитетына, КПСС райкомына, «Социалистик Татарстан»,

се — балалар бакчасы мөдире Рәсимә ханымны яклап, кызы Рәзинә болай дип яза: «Минем әнием балалар бакчасына үзе ашкынып килмәде. Мәктәптәге озайтылган эш группасын калдырып, халык соравы буенча урнашты. Югыйсә, укучылар да бик яраталар иде үзен. Әниемнең бакча ачтыру өчен имза җыеп йөрүе дөреслеккә туры килми. Киресенчә, больница кирәк дип, Ә. Әшрәпов үзе авыл капкаларын шакып йөрде».

Рәзинәнең әлеге хаты тикшерү өчен кабат КПСС райкомына җибәрелде. Редакциягә райком секретаре Н. Островскийдан яңа шушындый җавап килде: «Туймәттә булганда түбәндәгеләр ачыкланды: Ә. Әшрәпов...

**Фазыл Фәссәхов:**

— Хөкүмәтнең больницаларны арттырырга дигән сүзе бар бит.

**Шәфыйк Ильясов:**

— Больница ачылса, штаты булыр иде әле. Кассада 150 мең сум акчабыз бар. Әгәр больница өчен өстәмә биналар кирәксә, һәммәбез дә өмәгә чыгарга, тезелешне бушлай башкарырга әзер.

**Хәернас Фәссахов:**

— Балалар бакчасын салганда, авылга КПСС райкомының элеккеге беренче секретаре Рушан Гарипович Сабировның килүе исте калган. Ул нигез урынын күргәч, бинаны ике катлы итеп салырга киңәш биргән иде. Монда участок больницасы...

тәртибе белән таныштыра:

— Участок больницасында врач-терапевт тоту өчен, авылда 2500 олы кеше яшәү шарт. Ә халык саны 4 меңгә җитсә, врач-стоматолог бирелә. 25 мең кешегә 1 хирург җибәрелә.

— Әгәр район үзәк больницасында урын җитмәсә нишләргә?

— Бу очракта хат авторы ялгыша. Әйтик, Чирмешән больницасындагы һәр урын ел дәвамында 356 көн файдаланылырга тиеш. Ә чынлыкта быелтыр бу күрсәткеч 343 көнә булды, ягъни койкалар буш торган.

— Раиса Яковлевна, участок больницаларында эшләр ничек тора?

— План буенча Түбән Каменкада — 83, Котышта 23 урын-көн җитмәде. Димәк, врачлар, шәфкать туташлары ял итеп акча алганнар. Мондый шартларда яңа участок больницасы ачу турында нинди сүз булырга мөмкин?

Туймәт медицина пунктында эшләүче тәҗрибәле белгечләр — фельдшер Н. Рәҗәпова белән акушерка К. Хәсәнова да авылдашларының участок больницасы ачтырырга йөрүләрен аңлап бетермиләр. Чөнки ни бары...

Игътибар! Игътибар! Игътибар! Игътибар!

# АТЫМ — ПАР КАНАТЫМ

## Әйдәгез, ярышка

**1990 елда һәм унөченче бишьеллыкта атчылык продукциясе җитештерүне арттыру өчен колхоз-совхозлар һәм районнар арасындагы республика ярышы шартлары.**

Колхоз-совхозлар һәм районнар арасындагы бу ярыш азык-төлек проблемасын хәл итү, халыкның иткә һәм ит продуктларына ихтыяҗын тулырак канәгатьләндерү, атны тарту көче һәм спорт өчен киңрәк файдалану максатында уздырыла.

Ярышта узган ел белән чагыштырганда атларның баш санын кимендә 10 процентка арттырган, атчылыкта әйбәт нәтиҗәлелеккә ирешкән, атларны асрау өчен тиешле шартлар булдырып, аларны җитәрлек кадәр азык белән тәэмин иткән, бер яшьлек чагында кырыкмышның авырлыгын 310 килограммга җиткергән, эштә ат белән бәйле бәхетсезлек очракларына юл куймаган, ит җитештерү һәм хәзерләү планын үтәүдә зур үсешкә ирешкән колхоз-совхозлар һәм районнар җиңүче дип табылачак.

Җиңүчеләрне бүләкләү өчен ТАССР Агропромышленность комитеты, агропромышленность комплексы эшчәннәре профсоюзы өлкә комитеты һәм «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе түбәндәге бүләкләрне билгеләделәр:

**районнар арасында:**

— атларның баш саны авыл хуҗалыгы җирләренең йөз гектарына күчереп исәпләнгәндә уртача республика күрсәткеченнән ким булмаган, йөз башка күчереп исәпләгәндә бияләрдән эш аты максатында 80 колын алып үстергән ӨЧ районга — берәр «КамАЗ» автомашинасы;

**колхоз-совхозлар арасында:**

— 80 баш һәм аннан да күбрәк аты булган, шуның кимендә 35 процентын бияләр алып торган, йөз башка күчереп исәпләгәндә бия атлардан 85 колын алып үстергән **БИШ** колхоз-совхозга — берәр йөк автомобиле;

— кимендә 70 баш аты булган, шуның 35 процентын бияләр алып торган, йөз башка күчереп исәпләнгәндә бия атлардан 80 һәм аннан да күбрәк колын алып үстергән **БИШ** колхоз-совхозга — берәр ИЖ-2715 «Москвич» автомашинасы;

**ат караучылар арасында**

— атларны караудагы норманы тәгәл үтәгәндә, бияләр барлык атларның баш санында кимендә 35 процент алып торганда, йөз баш биягә кимендә 90 колын алып үстергәндә, район беренчелеге ярышлары (Сабантуйны да кертеп) призеры тәрбияләгәндә ат караучылар бригадасына — **750 шәр сумлык ӨЧ премия;**

— атларны караудагы норманы тәгәл үтәгәндә, барлык атларның баш санында бияләр кимендә 35 процент булганда, йөз башка күчереп исәплә гәндә бия атлардан 85 колын алып үстергәндә ат караучылар бригадасына — **600 әр сумлык БИШ премия;**

— атларны караудагы норманы тәгәл үтәгәндә, барлык атларның баш санында бияләр кимендә 35 процент булганда, йөз башка күчереп исәпләгәндә бия атлардан кимендә 80 колын алып үстергәндә ат караучылар бригадасына — **500 әр сумлык БИШ премия.**

Җиңүчеләргә «Социалистик Татарстан» газетасы һәм агропромышленность комплексы эшчәннәре профсоюзы өлкә комитетының истәлек бүләкләре, Мактау грамоталары да тапшырылачак. Ярышка йомгак ел саен алдагы елның 15 январенда ясалачак.

**Республикабызда ат асрауның торышына ТАССР Агропромышленность комитетының баш зоотехнигы — «Атым — пар канатым» конкурсы арбитры Камил Сәйфетдинов аңлатмасы:**

— Дөресен генә әйткәндә, хәзергә атларга игътибар юк дәрәҗәсендә. Аларның баш саны елдан-ел кими. Ике ат елы арасындагы хәлгә күз ташласаң, моңа тагын бер тапкыр ышанырга туры килә. Унике ел элеккеге ат елында колхоз-совхозларда 83 мең баш ат булса, шушы елның 1 январена ул 70 меңгә генә калды. Әгәр игътибарны арттырмасак, бу кимү әле тагын да дәвам итәргә мөмкин.

Атларның баш саны кимүгә авылда техника революциясе нәтиҗәсе итеп кенә карарга кирәк түгел. Бу — колхоз-совхоз җитәкчеләренең крестьян психологиясен, борынгы традицияләрне аңламавыннан да килә. «Ат асрамагыз», — дип, югары оешмалардан беркайчан күрсәтмә бирелгәне юк. Шуның белән бергә, килеп туган хәлнең объектив сәбәпләрен дә әйтергә кирәк. Мәсәлән, моңарчы агропромышленность берләшмәләрендә ат асрау өчен җаваплы берникди белгеч юк иде. Агропром системасында үзгәрешләр булгач — ТАССР Агропромышленность комитеты төзелгәч кенә — андый штатлар булдырылды.

Статистик отчетларда да моңарчы атка игътибар җитмәү сизелеп тора иде. Мәсәлән, аларның баш саны бер тапкыр ел ахырында гына исәпкә алынды. Югыйсә, атлар ит өчен хәзерләүләр пунктларына күпләп озатыла бит. Шулай икән, нигә аларның үсешен башка төр терлекләрнеке кебек граммлап үлчәмәскә? Ат караучылар хезмәтенә түләүне шул нәтиҗәләргә бәйле итеп куймаска? Бу атларга карашны үзгәртергә ярдәм итәр иде. Югыйсә, хәзер бу мескен җан ияләре дөньяда әллә бар, әллә юк. Кышлату чорына терлек азыгы туплаганда да атлар исәпкә алынмый. Аларга башкалардан арткан терлек азыгы гына бирелә.

Соңгы вакытта авылларда атка сорау артканны әйтергә кирәк. Терлекчелектә эшләүче аренда звенолары тарту көче итеп гел аны сорыйлар. Житештерелгән продукциянең үзкыйммәтен арттырмас өчен иң кулай транспорт чарасы ул. Кыйммәтле бензин, запас часть, майлау материаллары да кирәк түгел бит үзенә. Борын-борыннан кешеләр ат итенең организм өчен бик файдалы булуын белгәннәр, аны туклану өчен киң кулланганнар.

Республикабызда «Ит» комплексы программасы кабул ителде. Аның максаты — алдагы бишьеллык ахырына һәр кешегә елга уртача 80 килограмм ит куллануга ирешү. Ат асрауны киң җәелдерү моңа ирешүдә зур өлеш кертер иде. Безнең республикабыздан ат ите, терлек симертүче берләшмәләр аша, Италиягә һәм Франциягә сатыла. Валютага, билгеле. Менә монда колхоз-совхозлар өчен мәсьәләнең тагын бер кызыклы ягы ачыла. Алар, ТАССР Агропромышленность комитетының тышкы элемтәләр бүлеге ярдәмендә, чит ил фирмалары белән ике якка да файдалы эшчәнлеккә керә алалар. Экономик яктан мөстәкыйльлек, үзфинанслау шартлары моңа тулы мөмкинлек бирә.

Менә шуларны исәпкә алып, ТАССР Агропромышленность комитеты колхоз-совхозларда атларның баш санын унөченче бишьеллык ахырына 120 меңгә җиткерүне максат итеп куя. «Социалистик Татарстан» газетасы белән бергәләп игълан ителә торган смотр-конкурс та моңа булышлык итәр, дип уйлыйбыз. Аның шартлары белән район агропромышленность берләшмәләре, колхоз-совхоз җитәкчеләре, һәм белгечләре ныклап танышсыннар иде. Әйдәгез, атларның баш санын арттыру, авылларыбызга матур бизәк өстәү өчен барыбыз да бергәләп тырышыйк!

Хәтер

# Якын дуска мәдхия

**Авыл кешесендә крестьян рухын кире кайтару аттан башка мөмкинме икән?**

Мөгаен, күпләр үзенең яшьлеген искә төшергәндә иң якын дусларын күз алдына китереп бастырадыр. Ә минем шундый дусларым арасында Пәчтүк тә урын алмыйча калмый. Бу нинди сәер исемдәге кеше дип аптырауга калмагыз. Карасу-кызгылт төстәге бия ат иде...

түдән кайтканда, атлар абзарына төшмичә, капка төбендә кала иде ул. Әгәр капка ачык булса, ишек алдына керә дә ой ишеге төбенә килеп ашарга, эчәргә биргәнне көтә башлый. Инде янына тиз генә чыгучы булмаса, лапас астына кереп үзе эзләнергә керешә. Тезмәдәге печәнгә үрелә, ләгәндә тавыклардан калган ризыкны ялмап куя. Менә шулай ике...

өчен артык булмый ул. Әмма без моңа сөенмәдек, чөнки авыр йөк белән Мишә ел гасының текә ярыннан төшәсе һәм менәсе, суын ерып чыгасы бар иде. Шунда кайтып җиткәч, барыбыз да туктап калдык. Инде нишләргә? Тайгак үрдән атларыбыз менә алырмы?

Минем Пәчтүк иң алдан атлый иде. Шуңа күрә Мишә ярыннан аска иң беренче булып без... икәү төшеп...

рәнгe турап бирдем, тәмләп су эчерттем. Пәчтүк ул көнне капкадан аерча теләргә теләмәс кенә чыгып китте.

Мишә ярындагы хәл атның абруен бөтенләй күтәрде бит. Әмма ул мина дә эшне арттырды. «Синең атың куәтле», — дип мине ерак юллардан кайтармыйлар. Арча белән ике араны (45 километр) кыш көннәрендә күпме генә тапкыр узарга туры килмәде икән! Ындыр табагыннан амбарга ашлык күчерү, таш ташу, яз көне чәчү агрегатларына орлык чыгару... — берсе дә калмады. Һәм без һаман Пәчтүк белән икәү. Әгәр бу атны башка берәүгә бирсәм, бәлки, мондый эшләр әләкмәс...

# Балалар өлешенә кагылмыйк

Үзара тарткалашу бик озакка китте. Югыйсә, ул кадәр баш ватарлык, [illegible] чыкмаслык нәрсәләр тирәсендә бармый бәхәс. Туймәт авылы кешеләре белән район җитәкчеләре арасында березлексез барган низагны һәркем үзенчә хәл итәргә тырыша. Югары оешмалар исеменә өзлексез шикаятьләр ява тора. Ана җавап бирергә өлгермиләр, икенчесе килеп төшә. Шулай итеп бу бәхәс ике ел дәвам итә.

Эш нәрсәдә соң? Әйткәнебезчә, әллә нәрсәдә түгел: авыл кешеләре участок больницасы ачтыруны сорыйлар. Кая гына мөрәҗәгать итмәгәннәр инде алар?! Район Советы башкарма комитетына, КПСС райкомына, «Социалистик Татарстан», «Сельская жизнь» газеталары редакцияләренә, Татарстан Министрлар Советына...

Узган ел Ә. Әшрәповның «Безгә больница кирәк» дигән язмасы газетабызның 75 нче санында басылып та чыккан иде: «Инде менә ничәнче ел безнең авылда бәхәс бара, — диелгән иде ул хатта. — авыл уртасына больница дип бер бина салып куйдылар. Колхоз председателе: «Мин аны участок больницасы ясар өчен төзетмәдем, анда колхоз идарәсе, китапханә, балалар бакчасы, радиоузел ясыйм», — дип кистереп әйтеп куйды. 1988 елны авыл халкы бергә җыелышып — пенсионерлар, сугыш ветераннары, колхозчылар бу бинада участок больницасы ясауны сорадылар. Шунда сөйләшкәннән чыгып, Сәламәтлек саклау министрлыгына хат җибәрелде. Алар рөхсәт тә биргәннәр иде. Ләкин районнан безгә һаман каршы төшәләр, ә балалар бакчасына күп дигәндә 14—15 бала йөри. Районыбыздагы шифаханәләрдә урын житми. Шулай дип төрле җиргә яза торгач, Рәсимә Хәйруллина безнең имзаларыбызны җыеп, «безгә больница кирәкми», дип документ ясап, Казанга барып раслатып кайтты. Чөнки аңа урын кирәк иде. Хәзер ул шунда бакча мөдире булды...» Шунда ук әлеге мәкаләгә аңлатма да бирелде. Партиянең Чирмешән район комитеты беренче секретаре М. Шакиров түбәндәгеләрне хәбәр итте: «Хат урынга барып тикшерелде. Фактлар расланмады. Моны автор үзе уйлап чыгарган. Беренчедән, 15 чакрымда Түбән Каменка һәм Чишмә участок больницалары бар. Икенчедән, врачлар һәм медицина җиһазлары җитмәгәнлектән, квалификацияле медицина ярдәмен район үзәк больницасында гына алып була».

Бер-берсен тулыландыручы әлеге ике хат мәсьәләгә тулысынча ачыклык кертер сыман иде. Әмма алай булып чыкмады. Кайтавал редакциягә Бөгелмә педагогия училищесында укучы Р. Хәйруллинадан яңа хат килеп төште. Ә. Әшрәпов язмасында телгә алынган әнисе — балалар бакчасы мөдире Рәсимә ханымны яклап, кызы Рәзинә болай дип яза: «Минем әнием балалар бакчасына үзе ашкынып килмәде. Мәктәптәге озайтылган эш группасын калдырып, халык соравы буенча урнашты. Югыйсә, укучылар да бик яраталар иде үзен. Әниемнең бакча ачтыру өчен имза җыеп йөрүе дөреслеккә туры килми. Киресенчә, больница кирәк дип, Ә. Әшрәпов үзе авыл капкаларын шакып йөрде».

Рәзинәнең әлеге хаты тикшерү өчен кабат КПСС райкомына җибәрелде. Редакциягә райком секретаре Н. Островскийдан янә шушындый җавап килде: «Туймәттә булганда түбәндәгеләр ачыкланды: Ә. Әшрәпов, нигезсез, кешене түбәнсетүче шикаятьләрне өзлексез яза. Ул мәсәлән, күптән түгел Р. Хәйруллинаны балалар бакчасыннан азык-төлек урлауда гаепләгән иде. Әмма прокуратура тикшерүчесе һәм район финанс бүлеге хезмәткәре тарафыннан уздырылган тикшерү барышында факт расланмады».

Мөдир дәрәҗәсен һәм намусын яклап суд юлында йөрерме-юкмы, монысы аның шәхси эше. Әмма участок больницасын ачуга кагылышлы хатларны авыл халкы хөкеменә чыгарырга бик вакыт. Чөнки районда бу мәсьәлә белән кемнәр генә шөгыльләнмәгәннәр инде?! Үзәк больницаның баш врачы Х. Абдуллин, район Советы башкарма комитеты председателе урынбасары В. Гыймранов, район план комиссиясе председателе Г. Нургатин, мәгариф бүлеге мөдире Т. Хәкимҗанов һәм башкалар өзлексез тикшерү уздырып тәмам ялыгып беткәннәр. Тик, бәхәскә нокта куелмагач, югары оешмаларга игезәк җаваплар җибәрүдән ни мәгънә. Редакциягә, әнә, соңгы вакытта Туймәттән тагын бер хат килеп төште. Больница ачу мәсьәләсен җентекләп тикшерүне, «район җитәкчеләренең алдаулырына ышанмауны сорап» Ә. Әшрәпов кабат кулына каләм алган.

— Бу Әхмәдулла сүзләре генә түгел, — диделәр авылга килгәч. — Хатны авыл халкының уртак фикере итеп кабул итегез.

Чыннан да «Азат» колхозында Ә. Әшрәпов язган сүзләргә кул куярга әзер торучылар байтак. Бигрәк тә аны пенсионерлар хуплый. Колхозчылар түбәндәгечә фикер йөртә:

**Назыйм Сәгыйров:**

— Ашказаным авырта, әмма район үзәк больницасында урын юк. Әгәр авылда участок больницасы ачылса, чиратта торырга туры килмәс иде.

**Фаил Ногманов:**

— Ике катлы бинаның әйбәтлеген күрсәгез икән! Җитмәсә, Туймәт түгыз авыл уртасына урнашкан. Участок больницасы өчен иң шәп урын.

**Фазыл Фәссахов:**

— Хөкүмәтнең больницаларны арттырырга дигән сүзе бар бит.

**Шәфыйк Ильясов:**

— Больница ачылса, штаты булыр иде әле. Кассада 150 мең сум акчабыз бар. Әгәр больница өчен өстәмә биналар кирәксә, һәммәбез дә өмәгә чыгарга, төзелешне бушлай башкарырга әзер.

**Хәернас Фәссахов:**

— Балалар бакчасын салганда, авылга КПСС райкомының элеккеге беренче секретаре Рушан Гарипович Сабировның килүе истә калган. Ул нигез урынын күргәч, бинаны ике катлы итеп салырга киңәш биргән иде. Монда участок больницасы ачылачагын да әйтте.

Колхозның партбюро секретаре Х. Вәгыйзовның эш бүлмәсенә җыелган колхозчылар арасыннан кемдер бүгенге КПСС райкомы беренче секретаре исеменә үпкәсен белдерде:

— Шакиров каршы төшә безгә, — әгәр ул ризалыгын бирсә, участок больницасы әллә кайчан ачылган булыр иде инде.

Шулаймы икән? Әлеге сорауга ачыклык кертергә теләп, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгына мөрәҗәгать итәргә туры килде. Андагылар исә архивтан Чирмешәннән җибәрелгән (8 июль, 1988 ел) «Туймәт авылында участок больницасы ачу турында»гы хатны эзләп таптылар. Бу — район Советы башкарма комитетының 173 нче карары. Анда болай диелә: «Туймәт авылындагы балалар бакчасы бинасында 25 урынга участок больницасы ачарга. ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгыннан яңа участок больницасын врачлар һәм медицина персоналы белән тәэмин итүдә практик ярдәм күрсәтүне сорарга».

Карарга ул чактагы район Советы башкарма комитеты председателе, ягъни хәзерге КПСС райкомы беренче секретаре М. Шакиров кул куйган. Әмма министрлыкта моңа каршы чыкканнар. «СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының 1978 елның 26 сентябрендә кабул ителгән 900 нче фәрманына нигезләнеп, 585 кеше яши торган Туймәт авылында участок больницасы ачарга рөхсәт бирә алмыйбыз», — дигән җавап җибәргәннәр. Димәк, колхозчыларның район җитәкчеләренә карата әйтелгән дәгъвалары урынсыз.

— Авыл саен участок больницасы ачаргамы? — дип гаҗәпләнә министр урынбасары Р. Җамалиев. — Моның нинди файдасы булыр соң? Беренчедән, халык саны җитмәгәнлектән, врачларның тулы штатын раслап булмый. Икенчедән, дәвалау-диагностика техникасы җитешми. Ә мондый больницага кереп ятудан ни мәгънә?

План-экономика бүлеге экономисты Р. Путилина штат расписаниесен билгеләү авылда 2500 олы кеше яшәү шарт. Ә халык саны 4 меңгә җитсә, врач-стоматолог бирелә. 25 мең кешегә 1 хирург җибәрелә.

— Әгәр район үзәк больницасында урын җитмәсә нишләргә?

— Бу очракта хат авторы ялгыша. Әйтик, Чирмешән больницасындагы һәр урын ел дәвамында 356 көн файдаланылырга тиеш. Ә чынлыкта былтыр бу күрсәткеч 343 көнә булды, ягъни койкалар буш торган.

— Раиса Яковлевна, ә участок больницаларында эшләр ничек тора?

— План буенча Түбән Каменкада — 83, Котышта 23 урын-көн җитмәде. Димәк, врачлар, шәфкать туташлары ял итеп акча алганнар. Мондый шартларда яңа участок больницасы ачу турында нинди сүз булырга мөмкин?

Туймәт медицина пунктында эшләүче тәҗрибәле белгечләр — фельдшер Н. Рәҗәпова белән акушерка К. Хәсәнова да авылдашларының участок больницасы ачтырырга йөрүләрен аңлап бетермиләр. Чөнки ни бары берәр врач эшләгән участок больницасында тиешле ярдәм күрсәтеп булмый. Кичектергесез чакта авыруны барыбер район үзәгенә илтергә яисә аннан белгечләр чакырырга туры килә.

Авылдагы ике катлы бинаны, балаларга салынган икән, балаларныкы итәргә кирәк. Дөрес, әлегә аның кайбер бүлмәләрендә сабыйлар тавышы ишетелми. Буш урыннар байтак. Әмма соңгы елларда Туймәттә бала туу артуын да онытырга ярамый. 1988 елда — 16, 1989 елда — 11 өйдә бәби туйлары узган. Өстәвенә өйләнмәгән егетләр саны да 44 кә җиткән. Әгәр якын арада авылга шулкадәр килен төшсә, балалар бакчасында нарасыйлар өчен урынның җитмәве дә ихтимал.

Инде якын тирәдәге участок больницаларын күздән кичерик. Дөресен әйтик, Чишмә авылы Туймәткә әллә ни ерак булмаса да, монда элгүләре ай-һай читен. Юлсызлык үзәккә үтә. Түбән Каменкага да язгы-көзге пычракта юл өзелә. Менә монысы инде җитди мәсьәлә. Участок больницаларының ярым җимерек хәлдә булулары да күңелдә борчу тудыра. Түбән Каменкадагысының матчалары сыгылып төшкән, бинада җылы тормый. Әгәр бу шифаханәне тиз арада берничә колхоз шефлыкка алса, шартлар яхшырыр иде.

Еллар дәвамында куертып килә торган участок больницасы кыйссасының төп эчтәлеге менә шуннан гыйбарәт. Уйлап карасаң, монда аңлашылмаслык бер нәрсә дә юк. Әмма Туймәт кешеләре үзләренең урынсыз таләп куйганлыкларын һаман да аңларга теләмиләр. Бүген безгә участоклар санын арттырудан битәр, булганнарын белемле кадрлар, яхшы җиһазлар белән тәэмин итү, аларның материаль-техник базасын ныгыту, авыруларга төпле киңәш бирерлек, чирне алдан кисәтерлек, үзәкләштерелгән больницалар булдыру турында кайгыртырга кирәк. Инде килеп, балалар өлешенә кермәсәк иде, алардан күпсенмәсәк иде...

**Х. БӘДРЕТДИНОВ,**
үз хәбәрче.

Чирмешән районы.

---

— колхоз-совхоз җитәкчеләренең крестьян психологиясен, борынгы традицияләрне аңламавыннан да килә. «Ат асрамагыз», — дип, югарыгы оешмалардан беркайчан күрсәтмә бирелгәне юк. Шуның белән бергә, килеп туган хәлнең объектив сәбәпләрен дә әйтергә кирәк. Мәсәлән, моңарчы агропромышленность берләшмәләрендә ат асрау өчен җаваплы

нәтиҗәләргә бәйле итеп куймаска? Бу атларга карашны үзгәртергә ярдәм итәр иде. Югыйсә, хәзер бу мескен җаннары дөньяда әллә бар, әллә юк. Кышлату чорына терлек азыгы туплаганда да атлар исәпкә алынмый. Аларга башкалардан арткан терлек азыгы гына бирелә.

Соңгы вакытта авылларда атка сорау артканны әйтергә

— алдагы бишьеллык азагына һәр кешегә елга уртача 80 килограмм ит куллануга ирешү. Ат асрауны киң җәелдерү моңа ирешүдә зур өлеш кертер иде. Безнең республикабыздан ат ите, терлек симертүче берләшмәләр аша, Италиягә һәм Франциягә сатыла. Валютага, билгеле. Менә монда колхоз-совхозлар өчен мәсьәләнең тагын бер кызыклы ягы ачы-

[illegible] ителә торган [illegible] та моңа булышлык итәр, дип уйлыйбыз. Аның шартлары белән район агропромышленность берләшмәләре, колхоз-совхоз җитәкчеләре һәм белгечләре якыннан танышсыннар иде. Әйдәгез, атларның баш санын арттыру, авылларыбызга матур бизәк өстәү өчен барыбыз да бергәләп тырышыйк!

---

Хәтер

# Якын дуска мәдхия

**Авыл кешесендә крестьян рухын кире кайтару аттан башка мөмкинме икән?**

Мөгаен, күпләр үзенең яшьлеген искә төшергәндә иң якын дусларын күз алдына китереп бастырадыр. Ә минем шундый дусларым арасында Пәчтүк тә урын алмыйча калмый. Бу нинди сәер исемдәге кеше дип аптырауга калмагыз. Карасу-кызгылт төстәге бия ат иде ул. Инде аның исеменә килсәк, эш болай тора. Колхоз оешканда Фәсхетдин дигән крестьян да аңа үз аты белән керә. Хуҗасы исеменнән чыгып (билгеле, шактый бозып), аны Пәчтүк дип йөртә башлыйлар. Мин җигеп йөргәне теге атның өченче буыны иде бугай.

Колхозда эшләгәндә Пәчтүкне өч ел җигеп йөрдем. Кышкы бураннарда, көзге салкын яңгырларда күп юлларны аның белән бергә узарга туры килде. Кем әйтмешли, ачысын да, төчесен дә бергә татыдык. Я, шундый дустыңны ничек онытырсың! Ничек аңа мәдхия укымассың!

...Ат караучы Әхмәдулла абый аны беренче тапкыр утардан алып чыкканда минем кәеф шактый кырылган иде. Пәчтүк дигәнебез шыр сөяк белән тиредән генә тора диярлек. Тояклары ярылып-кителеп беткән. Камытлыгы һәм ыңгырчаклыгы әллә ничә урында бозылган. Ул тирәдә чебен мыжгып тора. Мескенкәйгә карарга кызганыч. Башын салындырып, күзеннән чын мәгънәсендә яшьләрен агызып басып тора бу. Ичмасам, сбруеның да рәте юк. Камыт, ыңгырчак киезе таш булып каткан, каеш-бөятләре өзелеп беткән...

— Бик шәп, куәтле ат бу. Бераз рәткә кертергә, аннары карап йөртергә генә кирәк. Син бер дә борчылма, — дип тынычландырды мине Әхмәдулла абый.

Пәчтүк белән дуслык, танышлык менә шул көннән башланды. Һәм ул өч елга сузылды. Ишек алдына беренче кайткан көнне үк күп итеп он, әнинең каз-үрдәкләргә дип пешергән бәрәңгесен болгатып, җылы су эчердем мин моңа. Тимер щетка белән камыт-ыңгырчак киезләрен яхшылап чистарттым. Тәненең бозылган урыннарын каролин мае белән майладым. Арбасының күптәннән деге күргәне юк икән; анысына да иренмәдем. Пәчтүк мескенкәй үзенә мондый карашны күргәне булмаган, ахыры. Беренче көннәрдән үк җакланып китте бу. Башын күтәреп атлый башлады, яралары да төзәлде. Ат безнең өйгә тиз ияләште. Җәйге чорда төнге кө-

түдән кайтканда, атлар абзарына төшмичә, капка төбендә кала иде ул. Әгәр капка ачык булса, ишек алдына керә дә өй ишеге төбенә килеп ашарга, эчәргә биргәнне көтә башлый. Инде янына тиз генә чыгучы булмаса, лапас астына кереп үзе эзләнергә керешә. Тезмәдәге печәнгә үрелә, ләгәндә тавыклардан калган ризыкны ялмап куя. Менә шулай ике урыннан ашау эләккәч, кирәкле-кирәкмәскә сыртына чыбык, камчы төшмәгәч, тернәкләнде бит аткай. Елкылдап тора башлады бу. Яллары күтәрелеп китте.

— Атны тәки рәтләдең бит, әй! — дип моңа, барыннан да элек, ат караучы Әхмәдулла абый куанып бетә алмады.

Пәчтүк рәтләнгәч, аңа (билгеле, минем белән бергә) эшнең авырын, юлның ерагын билгели башладылар. Беренче язда ук пар ат белән авыл кешеләренең өй яны бакчаларын сукаларга туры килде. Монда таләп бер генә: тирән, пөхтә итеп сукаларга кирәк. Кайберәүләр тәрәнгә утырып та йөриләр әле. Синең атың тарта аламы — анысында берәүнең дә эше юк. Мин андыйларга: «Атларны яхшылап ашатсагыз гына...» — дип үз шартымны куйдым. Моның нәтиҗәсе сиздермичә калмады: атларым күзгә күренеп тазарды, ике тәрәнле сукаүы тарту аларга берни дә тормады.

Озакламый атымның инде чын мәгънәсендә куәт җыйнавын, савыгып җитүен сынарга сәбәп тә табылды... Ул көнне без озын арбалар җигеп унлап ат белән Олы Нырсы урманына юан-юан имәннәр алып кайтырга киттек. Болар сыерлар торагына идән такталары ярдырырга кирәк иде. Урманнан кайтыр юлга чыккач, коеп яңгыр явып кына кәефне кырды. Җәй көне яңгыр игеннәр

өчен артык булмый ул. Әмма без моңа сөенмәдек, чөнки авыр йөк белән Мишә елгасының текә ярыннан төшәсе һәм менәсе, суын ерып чыгасы бар иде. Шунда кайтып җиткәч, барыбыз да туктап калдык. Инде нишләргә? Тайгак үрдән атларыбыз менә алырмы?

Минем Пәчтүк иң алдан атлый иде. Шуңа күрә Мишә ярыннан аска иң беренче булып без икәү төшеп киттек, башкалар яр өстендә торып калды. Биш метр озынлыгындагы колач җитмәстәй имән салынган арбаны түбәнгә таба төшерү дә авыр. Я, бахбай, югарыга менгәндә сынатмассыңмы икән син? Судан чыккач, мин атны бераз ял иттердем һәм: «Әйдә, Пәчтүк!» — дип дилбегә белән акрын гына чиертеп куйдым. Мескен ат нишләргә кирәклеген аңлагансыман, бөтен җаны-тәне белән югарыга омтылды. Бер, ике, өч... дигәндә без яр өстендә идек.

Безнең текә ярдан ансат кына менгәнне күргәч, башкалар да теге яктан аска төшә башладылар. Менә алар Мишә суын чыктылар, текә ярга җиттеләр һәм... менә алмыйча шунда туктап калдылар. Барлык егетләр җыелышып булышып та карадык мескен атларга, ник берсе генә менә алсын! Байтак азапланганч, бездән олырак яшьтәге Габдрахман абый әйтә куймасынмы:

— Егетләр, Пәчтүкне җикмичә булмый.

Мине корт чактымыни! Бөтенесен ташлап, үз атым янына йөгердем. Берәүне дә якын китермәскә, атны туарырга ирек бирмәскә исәплим. Егетләр мине чорнап алдылар да үгетли башладылар. Бик озак сүз көрәштергәннән соң гына Пәчтүк янына җибәрдем боларны. Менә атымны бер арбага җигеп куйдылар да «әйдә» дип дилбегәсен тарттылар. Пәчтүк, бөтен ышаныч үзендә икәнне сизгәндәй, күз ачып йомганчы бүрәнәне яр өстенә менгерде. Икенче, өченче, дүртенче... унынчысын тартканда да сынатмады. Әмма өстеннән шаулап пар күтәрелә, эче кысылып калган, борыннары зур булып ачылган иде мескенемнең.

— Егетләр, гомер буе колхозда эшләп, мондый куәтле атны күргәнем юк иде әле, — диде Габдрахман абый, Пәчтүкне мактап.

Ул мактады, ә мин мескенемне кызганып нишләргә белмәдем. Бүрәнәләрне бушатып өйгә кайткач, аны әле атлар абзарына төшереп җибәрергә ашыкмадым. Әнидән яшереп кенә хәзинәдәге бары белән сыйладым үзен: бер бөтен ипи ашаттым, бәрәңге турап бирдем, [illegible] су эчерттем. Пәчтүк ул [illegible] теләмәс кенә чыгып китте.

Мишә ярындагы хәл атның абруен бөтенләй күтәрде бит. Әмма ул миңа да эшне арттырды. «Синең атың куәтле», — дип мине ерак юллардан кайтармыйлар. Арча белән ике араны (45 километр) кыш көннәрендә күпме генә тапкыр узарга туры килмәде икән! Ындыр табагыннан амбарга ашлык күчерү, таш ташу, яз көне чәчү агрегатларына орлык чыгару... — берсе дә калмады. Һәм без һаман Пәчтүк белән икәү. Әгәр бу атны башка берәүгә бирсәң, бәлки, мондый эшләр эләкмәс тә иде. Ләкин минем яраткан Пәчтүгемнән аерыласым килмәде. Язын, колхозда терлек азыгы нык кысылган чорда да, мескенкәйне ач итмәскә тырыштым. Үзебезнең тезмәдән туйдырдым моны.

Менә шундый язгы көннәрнең берсендә терлекләргә басудан салам ташырга куйдылар. Төнлә 15—20 градуска кадәр салкынайта, көндез аяк астында су ялтырап күренә торган чак бу. Басу түрендәге салам эскертләре янына керү бала булды бит. Атлар белән һич уза торган түгел: өсте бозланып каткан калын карга баталар да аякларын күтәрә алмыйча тик торалар болар. Уйлаша торгач, хезмәттәшем Фәрит белән җаен таптык бит! Пәчтүк белән аның Кукан дигән атын утарга кертеп яптык та... тәртә арасына үзебез җигелдек. Кояш әле чыгарга өлгергәнче, аяк аслары йомшарганчы, басу түреннән фермага икешәр рейс ясыйбыз. Кыр авыл ягына бераз авыш булганга, йөкне тарту һич авыр түгел. Каты кар өстеннән элдертәбез генә! Ул көннәрдә безнең атлар абзарда ял итте. Әгәр теле булса, Пәчтүгем моның өчен рәхмәтен әйтмичә калмас иде, дип уйлыйм. Ат караучы Әхмәдулла абый әйткән сүзләр икесе өчен дә булды бугай.

... Казанга укырга киткәч тә сагынып йөрдем мин атымны. Каникулга кайтканда атлар абзарыннан үзен эзләп менә идем. Мескенкәйнең тагын элеккеге хәленә кайтканлыгын күреп, йөрәгем сыкранганын һич онытасым юк. Дөньяда миһербансызлар азмыни: телсез хайванны кыйнау, кыерсыту аңа берни тормый. Пәчтүк үзе дә мине әле озак вакытлар онытмады. Күргә янымa килеп, борыны белән кесәмнән ипи эзли, кулларымны иснәи иде. Ә бер кайтуымда аны абзарда таба алмадым. «Ит өчен дип, хәзерләүләр пунктына алып киттеләр», — диде Әхмәдулла абый. Ул көнне атлар абзарыннан кайтканда йөрәгем тулы сагыш иде...

**Н. БУЛАТОВ.**

Саба районы,
Алан авылы.

Инде күптәннән бирле күрешмәгән танышларымны, дусларымны берьюлы очраттым. Гаҗәп хәл, туган-үскән якларда һәм районнарда шаулап-гөрләп узган Сабантуйларында да мондый очракның булганын хәтерләмим. Өзми дә, куймый да торган лэйсән яңгыр сибәли. Үтәли җил киемнәрне йолыккалый. Ник берсе кайтып китәргә ашыксын! Бирелә олуг тантана — Нәүруз бәйрәме.

Бергә үскән авылдаш, дус Рафаэль Гайсин — Казандагы зур гына заводның директоры урынбасары.

— Яңгырда лычма булып йөрергә өеңнән ни өстерәп чыгарды? — дим.

— Кием кибәр, — диде ул. — Ә монда күргәннәр

тыныш торган иде, әллә кайдан ялгыз курай авазы дисварга таралды. Күпме халык һәм ялгыз курай. Шушы курай моңы — халкыбыз моңы, аның үткәне түгелме соң инде?! Дербышки поселогындагы Сәетгалиев исемендәге Культура сараеның халык уен кораллары ансамбленә йөрүче Нил Исламов «Олы юлның тузаны»н уйный. Халык тын калды. Бу монда милләтебез язмышы да, үткән юлыбыз да, язмышыбыз да, олы юлның тузанында

Ә мәйданда Нәүрузбикә белән Кыш бабай «якалаша». Яз үз урынын дәгъвалый, кыш сер бирми. Әйтелгән такмаклар әнә шул хакта. Ни генә булмасын, яз үзенекен итә. Башта шәкертләр уйный, көлә, җырлый, китә аннары Нәүруз бәйрәме!

Нәни Альберт Кадыйров мондый тамашаны үз гомерендә беренче генә мәртәбә күрә әле. Казандагы 106 нчы татар мәктәбендә укый икән. Дербышки поселогыннан киләр килгән. Әлбәттә инде,

Бу — төрки халыкларының кышны озатуы, язны каршылавы. Галимнәр фикеренчә, төрки халыкларда безнең эрага кадәр мең еллар элек үк Нәүруз бәйрәм ителгән. Сер түгел, утрак тормышта яшәгән һәм күчмә халыклар язны көтеп алган, яңа елга яңа өметләр баглаган. Борын-борын заманнарда ук кешеләр бер-берсенә изге теләкләр юллаган. Тарих фәннәре кандидаты Габделбәр Фәйзрахмановның быелгы бәйрәмдә сөйләгән-

# МЕҢ ЯШӘ, НӘҮРУЗ!

Репортаж

нәреннән күренгәнчә, бу көнне лэйсән яңгыр яуса, кешеләр бик сөенгән, елның яхшы киләсенә юраган. Быел бәйрәмдә лэйсән яуды. Аның суын борынгылар (олы яшьтәгеләр бүген дә хәтерли) җыеп, мунча якканнар, юынганнар, лэйсән боткасы пешергәннәр. Аеруча кызлар битләрен юып калырга ашыккан. Имеш, болай итсәләр, әкияттәгечә гүзәл кызга әвереләләр, сөйгән ярларына кияүгә чыгалар.

Финляндиядән килгән татар кызы Айнур Низаметдин:

— Әниләр, әбиләр сөйләүләреннән генә чамалый идем Нәүрузны. Үз күзләрем белән күргәч, исләрем, акылларым китте. Милләтемнең без белмәгән әллә нинди хәзинәләре, гореф-гадәтләре бар икән ич! Шуларны саклый белгәне өчен генә дә халкыма мең шөкер! Һичшиксез, үзебезгә кайткач, әлеге тамаша турында уртага салып сөйләшәчәкбез, Нәүрузга Казаннан ерак-ерак җирләрдә дә икенче гомер бирәчәкбез...

Тамашада һәммә төрки халык вәкиле бар иде. Казан — вузлар шәһәре бит. Анда мөселман халыкларының күпме вәкиле белем ала. Килгәннәр, Моңнары да, фикерләре дә, гореф-гадәтләре дә, теләкләре дә уртак ич.

70 яшьлек Халисә Минһаҗева гомере буена гармунда уйнаган. Түзмәгән, 40 ел элек сатып алган тальян гармунын күтәреп, бәйрәмгә килгән.

— Картаям, гармуным гына шул килеш, — ди әби. — Моңы да картаймый...

Моңы яшь булган халыкның киләчәге бар! Халисә әби үзе уйнаган, үзе җырлаган «Сүнмәс дәрт»енең дә мәңгелек икәнен күрдек, шуна инандык. Моң чишмәң саекмасын, Халисә әби!

Нәүруз — изге бәйрәм дә

хәтердә калыр. Нәни чакларда әниләр, әбиләр сөйләгән буенча гына чамалыйм бу бәйрәмне. Ни икән ул? Шуны беләсе килде.

Рафаэль кебекләр Казанның Яшьләр үзәге каршындагы мәйданда ул көнне бик күп иде. Китте бию, китте җыр, такмак әйтешү, сөйләк сөйләү!

Карыйм, дустым пальтосы итәгендәге тигәнәкне күреп алды.

— Кара син моны, — диде ул җанлы әйбергә әйткәндәгедәй. — Авылдан килеш иде, каядыр нәргән. Үзебезнең тигәнәк! Йолкып атарга да җәл.

Дусның нечкә күңелле кеше икәнлеген шунда абайлап алдым. Тик, үзебезнең тигәнәк, дип киемендә йөртә алмый ич инде ул аны. Йолкып алды. Тик күпме генә азапланмасын, бер селтәнү белән генә морадына ирешә алмады. Тигәнәкнең тырнакларын озаклап чүпләргә туры килде. Уйлап куйдым: чү, бу бит әлеге бәйрәмнең символы түгелме соң?! Нәүрузга охшаш күпме милли бәйрәмнәребезне төбе-тамыры белән йолкып атарга, оныттырырга маташтылар. Ә ул, халкыбыз язмышы сыман, сикәлтәле, канлы юллар үтсә дә, алай тиз генә бирешергә теләми. Бу бәйрәм — халык хәтере. Хәтерене югалттыңмы, димәк, хыялыңны да югалтасың. Ә хыял — киләчәк ул.

Дустыма бу хакта әйтеп тормадым. Үзе фикер йөртсен.

күпме тапталган, изелгән бер бөртек тузан — бөек татар халкы күз алдына килеп басты.

Юк, милләтебезне дә, бәйрәмнәребезне дә, гореф-гадәтләребезне дә юкка чыгара алмадылар. Шуның дәлиле — бүгенге тамаша.

Янымда Исмәгыйль Баянов һәм аның хатыны Мәсхиҗамал апа. Өлкән яшьтәгеләр. Актанышта туып-үскән бу кешеләр кай яклары беләндер күңелемне биләп алды. Апа — оста гармунчы, 6 яшеннән үк кулына гармун алган, хәзер дә бу шөгылен ташламый икән. Исмәгыйль ага — халкыбызны тузанга әйләндереп, таптап, изеп үтәргә ниятләгән фашист юлына аркылы төшкән миллионнарның берсе. Гармунын куеп торып, кулына мылтык тотарга туры килгән, Кенигсбергны алган, дошманның үзен тузан иткән. Гомере буе мәйданда бил алышкан, сугыштан инвалид булып кайтса да, күпме Сабантуен шаккатырган. Пенсиядә булса да, әле дә төп шикелле таза.

— Ә бит, — ди ул. — әле кайчан гына Нәүрузда бил алыша торган идек. Сугыштан соңгы еллар. Яз житү белән Аккош күленә җыйнала идек. Ул бәйрәмнең матурлыклары! Сөендерә: оныттылды, бетте, дисәк, юк икән бит!

Һәр икесе Актаныш якларында һәр яз килү белән ераклаша барган балачакларын, Нәүруз бәйрәменең ничек уздырылуларын сөйлиләр. Ул чорда әйтелгән так-

әнисе белән. Килгәндә юл буе башындагы милли түбәтәен салмаган. Бәйрәмгә бара ич! Башта әнисе белән матур итеп, парлап биеделәр, ә аннары ул, йөрәкләргә үтеп керердәй итеп, Тукаебызның мәңге сүнмәс, сүрелмәс, тутыкмас «Туган тел»ен җырлап күрсәтте. Шәрык халкының берьюлы шулай бәйрәм иткәнен, берберсен котлаганнарын беренче генә мәртәбә күрә әле. Бер генә исерек, бер генә милиционер күренми. Менә нинди икән бит ул аның өчен яңа да, серле дә Нәүруз. Бу хәтле милләт кешесе үзебезчә, татар телендә генә ни өчен аңлаша, рәхәтләнеп сөйләшә алганлыгын ул бераз үсә төшкәч аңлар әле. Ышанам, озак вакыт үтмәс, Нәүрузның ни икәнлеген дә белеп алыр ул. Әлбәттә, нәни Альберт бу язманы укып чыгар. Шуна күрә әлеге бәйрәм тарихы хакында ана, аның чордашларына, яшьләргә бераз гына сөйләп, аңлатып китик әле.

Тормыш, яшьлек бәйрәме ул. Яңа көн дигәнне аңлата.

әле ул. Казандагы Мәрҗани, Әҗем мәчетләре мөтәвәллиятләре әгъзаларының да түр башында утыруы нур өстенә нур буларак кабул ителде. Мәчеттә дин сабаклары укытучы Рәшидә әби Исхакова чыгышын һәркем бирелеп тыңлады. Кешеләргә бары тик игелек итәргә, изгелек кылырга, яхшы булырга өндәүче бу дин әһеле бәйрәмнең Ак әбисе буларак кабул ителде. Шуңа да аның чыгышы, үзе чыгарган шигырьләрен укуы алкышларга күмелде. Кем әйтер аны заманнан артта калган, надан карчык дип?! Гомере буена микрофон алдында чыгыш ясаган диярсең! Һәр сүзеннән, һәр гыйбарәсеннән нур сирпелеп тора.

Башка төбәкләрдә яшәгән мөселман халыклары әлеге бәйрәмне ничек үткәрә? Мине шул сорау да кызыксындырмый калмады. Казахстаннан килгән Амангилде Кабдулов белән Канатбәк Тастаевның, шул сорауны ишеткәч тә, йөзләре яктырып китте.

— Без, кешеләр — табигать балалары, — ди Амангилде. — Шуңа күрә Нәүрузны һәр авылда, һәр калада табигатьтә үткәрәбез. Хәзерлек — күптән алдан. Халык көне буе күңел ача, төче-мөче, чәй, кымыз белән сыйлана. Ул һәртөрле уеннарны санап китсәң! «Ак сөяк», «Алты багана» ише тамашалар ел буе истән чыкмый.

— Яшьләр читтә калмыймы соң?

— Нәүруз — яшьлек бәйрәме бит инде ул. Аксакалларыбыз бу яктан тыныч — бәйрәмнәребез елдан-ел яңа нәкыш ала бара. Татарстанда уздырыла торган Нәүруз бәйрәменә киләсе елларда әнә шундый яңа төсмерләр өстәргә булышырбыз әле...

Әйе, тагын да бәстәсы иде мондый тамашаларны. Ә бит унтугызынчы гасырда ук тупланган, аннары басылып чыккан «Нәүруз» дастаныбыз бар. Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри тара-

фыннан тупланган такмакларыбыз байтак. Фольклорчылар язып алган төрле вариантлар («Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары»), «Борынгы татар әдәбияты»ндагы әлеге бәйрәмгә кагылышлы әсәрләребез дә бар. Тулырак өйрәник шуларны, заманыбызга яраклаштырыйк, халык күңеленә юл ачыйк! Әлегә бу бәйрәм Казанда гына үткәрелә (беренчесе былтыр булды). Авылларыбыз читтә калып килә әле.

Биш сәгатькә сузылган, чыгыш ясаучылары 200 дән артык булган әлеге бәйрәмгә ни өчен әле елъязмачыларыбыз исәпләнгән телевидение, кинохроника студиясе, радио әһелләре киләсе итмәгән? Киләсе елда әлеге бәйрәмне һәр авылда да күрәсе иде. Бу — минем генә түгел, халыкның үз теләге.

ВЛКСМның Казан шәһәр комитеты, шәһәр Советы башкарма комитетының культура бүлеге, хуҗалык исәбендәге «Болгар» берләшмәсе, Яшьләр торак комплексы, Татар иҗтимагый үзәгенең яшьләр секциясе, «Ядкарь» театр-студиясе, ветеринария институты коллективлары Нәүруз бәйрәме онытылмаслык булып үтсен өчен күп тырышлык куйган. Башлап йөрүчеләр киләчәктә тагын да ишәйсен өчен бүген уйлашыйк.

...Олы юлның тузанында
Калды минем эзләрем...

Нәни танышым Альберт! Оныкларың өчен син нинди эз калдырырсың икән? Бәйрәм беткәч, төнге Казан урамнарыннан өйгә кайтып барган чакта шулай уйлап куйдым.

**Ренат ГАФФАР.**

РӘСЕМДӘ: Нәүруз бәйрәменнән күренешләр.

А. Биктимеров фотолары.

# БЕЛЕШМӘЛӘР

## ТЕАТР

**М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры.** 25 мартта 11 сәгатьтә — «ДОН ПАСКУАЛЕ», 19 сәгатьтә — «ЙОКЫГА ТАЛГАН ГҮЗӘЛ», 26 мартта 11 сәгатьтә — «СИХЕРЛӘНГӘН МАЛАЙ», 19 сәгатьтә — «КАР КЫЗЫ».

**Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры.** 25 мартта 12 сәгатьтә — «ТАТАР ХАТЫНЫ НИЛӘР КҮРМИ», 18 сәгатьтә — «ӘЛДЕРМЕШТӘН ӘЛМӘНДӘР», кече залда 25 мартта 15 сәгатьтә — «ШҮРӘЛЕ».

**В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры.** 25 мартта 12 сәгатьтә — «МАНДАТ», 18 сәгатьтә — «КИЛДЕ ИР ХАТЫН ЯНЫНА», 26 мартта 19 сәгатьтә — «КИЛДЕ ИР ХАТЫН ЯНЫНА».

**К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры.** 25 мартта 12 сәгатьтә — «ӘНИЕМНЕҢ АК КҮЛМӘГЕ», 18 сәгатьтә — «ГАРМУН УЙНЫЙ БЕЛӘСЕҢМЕ?», 26 мартта 19 сәгатьтә — «МАЛ САТАМ — КӘЛӘШ ЭЗЛИМ».

**Ленин комсомолы исемендәге Казан яшь тамашачылар театры.** 25 мартта 10 һәм 13 сәгатьтә — «АЛ ЧӘЧӘК», 19 сәгатьтә — «ИИСУС ӘНИСЕ», 26 мартта 10 һәм 13 сәгатьтә — «АКЫЛСЫЗ ИВАН ТУРЫНДА», 19 сәгатьтә — «БИЛОКСИ-БЛЮЗ».

## КИНО

**«Татарстан».** 25 мартта 9, 11, 12, 15, 17, 19 һәм 21 сәгатьтә — «ЯШЬ ЛОВЕЛАС», 26 мартта 9, 12, 15, 18 һәм 21 сәгатьтә — «БЕЙБАРС».

**«Родина».** 25 мартта 9, 11-20, 13-40, 16, 18-20 һәм 20 сәгать 40 минутта — «КИНГ-САЙЗ», 26 мартта 8-40, 10-30, 12-20, 14-10, 16, 17-50, 19-40 һәм 21 сәгать 30 минутта — «КАРА ТАРТМАЧЫКНЫҢ ЮГАЛУЫ».

**«Дружба».** 25 һәм 26 мартта 9 сәгать 30 минутта — «КӨЛКЕ ҺӘМ КАЙГЫ АК ДИҢГЕЗ БУЕНДА», 25 мартта 10, 12, 14, 16, 18, 20 һәм 21 сәгать 30 минутта һәм 26 мартта 10, 12, 14, 16, 18 һәм 20 сәгатьтә — «ЛИФТТАН СУЛГА», 25 һәм 26 мартта 11, 13, 15, 17, 19 һәм 21 сәгатьтә — «ҖИНАЯТЬНЕ ТИКШЕРҮЧЕ КВАРТЕТ».

**«Спутник».** 25 мартта 9 сәгатьтә — «БОЗ ОНЫК», 10-20, 14-40 һәм 19 сәгать 10 минутта — «ТУТСИ», 12-25, 16-55 һәм 20 сәгать 50 минутта — «КАМУРАСКА», 26 мартта 9 сәгать 40 минутта — «БОЗ ОНЫК», 11, 13-15, 16, 18-15 һәм 20 сәгать 20 минутта — «УЛ».

**«Победа».** 25 һәм 26 мартта 9, 11, 13, 15, 17, 19 һәм 21 сәгатьтә — «ЭТЛӘР».

**«Идел».** 25 мартта 9 сәгатьтә — «МАРИЯ, МИРАБЕЛА ТРАНЗИСТОРИЯДӘ», 10-50, 12-40, 14-30, 16-50, 18-40 һәм 20 сәгатьтә — «ҖИНАЯТЬНЕ ТИКШЕРҮЧЕ КВАРТЕТ», 26 мартта 9, 12, 17 һәм 20 сәгатьтә — «ОЗАККА СУЗЫЛГАН ҖӘЗА», 15 сәгатьтә — «ЦИРККА ГАШЫЙК КЫЗ».

**«Звезда».** 25 һәм 26 мартта 9, 10-40, 12-30, 16-10, 18 һәм 20 сәгать 10 минутта — «ЛИФТТАН СУЛГА», 14 сәгать 20 минутта — «ЗАПАСТАГЫ УЕНЧЫ».

**«Восток».** 25 мартта 14 сәгать 30 минутта — «РЕКС-ТЫЛСЫМЧЫ», 16, 18 һәм 20 сәгатьтә — «ШИКЛӘНМИЧӘ СӨЙЛӘ», 26 мартта 16, 18 һәм 20 сәгатьтә — «САБЫР КАСӘСЕ».

**«Мир».** 25 мартта 10 сәгатьтә — «НАВИГАТОР ОЧУЫ», 12, 14, 16, 18 һәм 20 сәгать 20 минутта — «СИХЕРЛӘНГӘН ДОЛЛАР», 26 мартта 10 сәгатьтә — «НАВИГАТОР ОЧУЫ», 12, 13-50, 16, 17-50, 19-40 һәм 21 сәгать 30 минутта — «ҖИНАЯТЬНЕ ТИКШЕРҮЧЕ КВАРТЕТ».

**Г. Тукай исемендәге кинотеатр.** 25 мартта 9-30, 10-50, 12-10 һәм 13 сәгать 30 минутта — мультфильм, 14-50 һәм 18 сәгать 40 минутта — «БЕРВАКЫТ АМЕРИКАДА» (3 нче серия), 26 мартта 9-30 һәм 11 сәгать 10 минутта — **мультфильм**, 12-50, 14-30, 16-10, 18-20 һәм 20 сәгать 20 минутта — «СИХЕРЛӘНГӘН ДОЛЛАР».

**«Огонек».** 25 һәм 26 мартта 11 сәгатьтә — **мультфильм**, 25 мартта 14, 16, 17-50 һәм 20 сәгатьтә — «МӘХӘББӘТЕМ, МИНЕМ МӘХӘББӘТЕМ», 26 мартта 14, 16, 17-50 һәм 20 сәгатьтә — «КӘРРОЛЛ - СТРИТТАГЫ ЙОРТ».

**Химиклар мәдәният сарае.** 25 мартта 11 сәгатьтә — **мультфильм**, 16, 18 һәм 20 сәгатьтә — «АК СӨЯК».

РАДИО

АТНАЛЫК ПРОГРАММА

### ДҮШӘМБЕ, 26 МАРТ

6.30 «Иртәнге дулкында».
6.55 Белдерүләр.
7.15 Информацион - музыкаль программа.
7.50 Белдерүләр.
8.25 «Татулыкка ни җитә» (чуваш телендә).
15.15 «Язгы каникул көннәрендә» (Мәскәү язмасында).
• • •
18.00 СССР һәм чит ил хәбәрләре.
18.05 «Социаль гаделлек һәм без».
18.20 СССР халыклары музыкасы.
18.30 Республика хәбәрләре.
18.40 «Кеше һәм закон» (М.)
19.45 Республика хәбәрләре.
19.55 Үзешчән сәнгатьтә катнашучылар концерты.
20.45 Халыкара көндәлек (М.)

### СИШӘМБЕ, 27 МАРТ

6.30 «Иртәнге дулкында».
...
7.15 Республика газеталарына күзәтү.
7.30 Иртәнге концерт.
7.50 Белдерүләр.
14.40 «Пионер ялкыны» (Мәскәү язмасында).
• • •
18.00 СССР һәм чит ил хәбәрләре.
18.05 Республика хәбәрләре.
18.15 «Контакт». Информацион-публицистик программа.
19.00 Соңгы хәбәрләр (М.)
20.00 Республика хәбәрләре.
20.10 «Музыкаль сәхифәләр». Радиоальманах.
20.45 Халыкара көндәлек (М.)

### ҖОМГА, 30 МАРТ

6.30 «Иртәнге дулкында».
6.55 Белдерүләр.
7.15 Республика газеталарына күзәтү.
7.25 Иртәнге концерт.
7.50 Белдерүләр.
8.25 «Сезнең өчен һәм сезнең хакта».
8.40 Яңа музыкаль язмалар.
15.15 «Пионер ялкыны» (Мәскәү язмасында).
• • •
18.00 СССР һәм чит ил хәбәрләре.
18.05 Республика хәбәрләре.
18.15 «Яшьлек радиодулкында».

...ы өтегендәге тигәнәкне күреп алды.

— Кара син моны, — диде ул жанлы әбиергә әйткәндәгедәй. — Авылдан килеш иде, каядыр нәрган. Үзебезнең тигәнәк! Йолкып атарга да жәл.

Дусның нечкә күңелле кеше икәнлеген шунда абайлап алдым. Тик, үзебезнең тигәнәк, дип киемендә йөртә алмый ич инде ул аны. Йолкып алды. Тик күпме генә казаланмасын, бер селтәнү белән генә морадына ирешә алмады. Тигәнәкнең тырнакларын озаклап чүпләргә туры килде. Уйлап куйдым: чү, бу бит әлеге бәйрәмнең символы түгелме соң?! Нәүрузга охшаш күпме милли бәйрәмнәребезне төбе-тамыры белән йолкып атарга, оныттырырга маташтылар. Ә ул, халкыбыз язмышы сыман, сикәлтәле, канлы юллар үтсә дә, алай тиз генә бирешергә теләми. Бу бәйрәм — халык хәтере. Хәтереңне югалттыңмы, димәк, хыялыңны да югалтасың. Ә хыял — киләчәк ул.

Дустыма бу хакта әйтеп тормадым. Үзе фикер йөртсен.

Биюләр бер мәлгә генә ләр. Актанышта [illegible] бу кешеләр кай якларны белгәндер күңелемне биләп алды. Апа — оста гармунчы, 6 яшеннән үк кулына гармун алган, хәзер дә бу шөгылен ташламын икән. Исмәгыйль ага — халкыбызны тузанга әйләндереп, таптап, изеп үтәргә ниятләгән фашист юлына аркылы төшкән миллионнарның берсе. Гармунын куеп торып, кулына мылтык тотарга туры килгән, Кенигсбергны алган, дошманның үзен тузан иткән. Гомере буе мәйданда бил алышкан, сугыштан инвалид булып кайтса да, күпме Сабантуен шаккатырган. Пенсиядә булса да, әле дә төп шикелле таза.

— Ә бит, — ди ул. — әле кайчан гына Нәүрузда бил алыша торган идек. Сугыштан соңгы еллар. Яз житү белән Аккош күленә җыйнала идек. Ул бәйрәмнең матурлыклары! Сөендерә: оныттылды, бетте, дисәк, юк икән бит!

Һәр икесе Актаныш якларында һәр яз килү белән ераклаша барган балачакларын, Нәүруз бәйрәменең нечек уздырылуларын сөйлиләр. Ул чорда әйтелгән такмакларын да сөйләп бирәләр.

...әле. Бер генә исерек, бер генә милиционер күренми. Менә нинди икән бит ул аның өчен яңа да, серле дә Нәүруз. Бу хәтле милләт кешесе үзебезчә, татар теленнә генә ни өчен аңлаша, рәхәтләнеп сөйләшә алганлыгын ул бераз үсә төшкәч аңлар әле. Ышанам, озак вакыт үтмәс, Нәүрузның ни икәнлеген дә белеп алыр ул. Әлбәттә, нәни Альберт бу язманы укып чыгар. Шуңа күрә әлеге бәйрәм тарихы хакында аңа, аның чордашларына, яшьләргә бераз гына сөйләп, аңлатып китик әле.

Тормыш, яшьлек бәйрәме ул. Яңа көн дигәнне аңлата. Килгәннәр. Моңнары да, фикерләре дә, гореф-гадәтләре дә, теләкләре дә уртак ич.

70 яшьлек Халисә Минһаҗева гомере буена гармунда уйнаган. Түземәгән, 40 ел элек сатып алган тальян гармунын күтәреп, бәйрәмгә килгән.

— Картаям, гармуным гына шул килеш, — ди әби. — Моңы да картаймый...

Моңы яшь булган халыкның киләчәге бар! Халисә әби үзе уйнаган, үзе җырлаган «Сүнмәс дәрт»нең дә мәңгелек икәнен күрдек, шуңа ышандык. Моң чишмәң саекмасын, Халисә әби!

Нәүруз — изге бәйрәм дә ...» ише тамашалар ел буе истән чыкмый.

— Яшьләр читтә калмыймы соң?

— Нәүруз — яшьлек бәйрәме бит инде ул. Аксакалларыбыз бу яктан тыныч — бәйрәмнәребез елдан-ел яңа нәкыш ала бара. Татарстанда уздырыла торган Нәүруз бәйрәменә киләсе елларда әнә шундый яңа төсмерләр өстәргә булышырбыз әле...

Әйе, тагын да баетасы иде мондый тамашаларны. Ә бит унтугызынчы гасырда ук туп... аннары басылып чыккан «Нәүруз» дастаныбыз бар. Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри тарафручеләр киләчәктә тагын да ишәйсен өчен бүген уйлашыйк.

...Олы юлның тузанында
Калды минем эзләрем...

Нәни танышым Альберт! Оныкларың өчен син нинди эз калдырырсың икән? Бәйрәм беткәч, төнге Казан урамнарыннан өйгә кайтып барган чакта шулай уйлап куйдым.

Ренат ГАФФАР.

РӘСЕМДӘ: Нәүруз бәйрәменнән күренешләр.

А. Биктимеров фотолары.

# ТАРИХТАН КИЛГӘН БӘЙРӘМ

Гарәп хәрефләре белән «Рәхим ит, Нәүруз», «Нәүруз мөбарәкбад» дип язылган яшел әләмнәр Кызыл яр авылы урамнарын серлелеккә күмә. Авылның мәдәният йорты янындагы иркен мәйданында иртәдән үк халык кайнып. Кырыйлап сәүдә рәтләре тезелеп киткән. Өстәлләрдә — нигъмәт. Бер якта казан асканнар. Икенче урында исә ак самоварлар пар бөрки. Кешеләр бер-берсен бәйрәм белән котлыйлар, бәхет, байлык телиләр.

Нинди бәйрәм соң ул март ахырында? Бу — безнең тарихи бәйрәмебез, бабаларыбыз мирасы — Нәүруз. Баулы районында шушы бәйрәмне яңадан тормышка кайтарырга карар кылганнар. Һәм ул беренче тапкыр районның Кызыл Яр авылында үткәрелә.

Милли киемнәр киенгән, беләкләренә, иңнәренә янчыклар аскан балалар йорттан йортка кереп яз килүе турында хәбәр бирәләр, хуҗаларны котлыйлар.

Мал-туарыгыз артсын,
Игеннәрегез уңсын, —

дип такмаклыйлар, матур теләкләр телиләр, җырлар җырлыйлар. Балаларның яхшы теләкләренә каршы хуҗалар сый белән җавап кайтаралар. Шаһит булган һәркем тойгандыр: бу мизгелләр үзләренең самимилеге белән күңелләргә изгелек иңдерәләр, рухны сафландыра төшкәндәй булалар. Балаларны сөендерү сүзсез бер рәхәтлек бирә икән. Хәер, монда һәркем бер-берсен сөендерергә ашыкты. КПССның Баулы район комитеты секретаре А. М. Рахманкулов бирегә җыелган халыкны тарихи бәйрәм белән, матур гадәтләребезнең тормышка яңадан кайта башлавы белән чын күңелдән котлады. Ул шулай ук бу бәйрәмне торгызуда зур ярдәм күрсәткәннәре өчен ТАССР Мәдәният министрлыгына, аның методик үзәгенә зур рәхмәт белдерде.

...Күчтәнәчләр, бүләкләр төяп балалар кайталар. Алар туплаган байлыкларын гомуми өстәлгә салып, берберсен кыстап сыйлашалар. Казан аскан учак тирәсен дә халык сырып алган: карга боткасыннан авыз итәләр. Шунда:

— Табигать патшасының фәрманы бар! — дип сөрән салалар.

Барлык халык, тыңларга әзерләнеп, тын кала. Табигать патшасы фәрманын ирештерә:

— Сезнең бабаларыгыз Нәүрузны зурлап каршы алганнар, — ди ул, халыкка мөрәҗәгать итеп. Кешеләрне дуслыкка, татулыкка өнди, табигатьне күз карасы кебек сакларга чакыра, гореф-гадәтләребезне оныткагда кешелек сыйфатларыбызны югалтачагыбызны искәртә. Аның шушы сүзләрен тыңлаганда тәннәр чымырдап китә.

— Нәүрузбикәне хәерле сәгатьтә каршылагыз, — ди табигать патшасы.

Халык дәррәү Нәүрузбикәне чакыра:

— Нәү-руз-бикәү!!

Менә кыңгыраулы пар атларда мәйданга гаҗәп матур итеп киенгән, күз явын алырлык чибәр кыз — Нәүрузбикә килеп керә.

— Мине искә төшергәнсегез һәм сагынып көтеп алганыгыз өчен зур рәхмәт, — ди ул. Шуннан китә җыр, бию, уен-көлке...

Халык үзенең тарихи бәйрәмен таныды, бигрәк тә шул бәйрәмнең кайтуына, бүгенге көнебезнең тарихы белән тоташуына куанудан дәртләнеп күңел ачты.

Шөкер, рухи агачыбызның тамыры бөтенләй өзелмәгән икән әле. Инде менә кайгырту тойгач, җәрәхәтләре төзәлеп, кәүсәгә яшәү көче бирә башлады. Хәерле сәгатьтә! Моннан соң бу бәйрәмебез тормышыбызда аерылгысыз урын алсын.

Д. АСЫЛОВ.
Үз хәбәрчебез.
Баулы районы.

## Үз исемнәребез

Шәһәрләрнең, урамнарның үз исемнәрен кайтарыйк дип матбугатта күп язылды. Шөкер, шактый шәһәрләр, урамнар үз исемнәрен алдылар да инде.

Безнең үзебезнең исемнәребез дә милләтебезгә, телебезгә хас халәттә түгел бит. Нурислам Хөсәен дип татарча әйткәндә дә кемлегем аңлашыла, югыйсә. Нигә исем-фамилиябезне шулай татарча әйтү-язуга күчмәскә?! Моның өчен зур чыгымнар да, Мәскәү рөхсәте дә кирәкмидер, шәт.

Н. ХӨСӘЕН.
Бөгелмә.

# Борылыш елы булсын

Үзгәртеп кору чоры башлангач, безнең татар халкына да үзенең тарихы белән танышырга азрак кына булса да мөмкинлек тудырыла башлады. Татар халкы уйлана һәм уяна, үзенең тарихы белән кызыксына башлады. Ләкин тарихи китаплар бик аз санда чыга, аларның тиражлары халыкны бер дә канәгатьләндерми. Билгеле булганча, узган ел Газиз Гобәйдуллинның «Татар халкы тарихы сәхифәләре» исемле китабы чыкты. Бу — куанычлы күренеш. Китапның тиражы 10000 данә. Татар халкы үз тарихын бик аз белә, белүче кешеләр бик аз. Газиз Гобәйдуллинның бу китабы, һичшиксез, күп тираж белән чыгарылыр дип ышанасы килә. Тарих укытучыларына бу китап бигрәк тә файдалы булыр иде. Җиде миллионлы татар халкына 10000 данә тираж белән китап чыгару — 700 кешегә бер генә данә туры килә дигән сүз.

Мәгълүм булганча, Октябрь революциясенә кадәр татарча китап басу саны буенча татарлар руслардан һәм латышлардан кала өченче урында булса, тиражы буенча беренче урында иде. Хәзер татарча китап басу иң соңгы урыннарда. Шушы гаделсезлекләргә йөрәк әрни.

Узган ел Җәмил Зәйнуллинның «Гарәп язуы нигезендә татарча әлифба»сы басылды. 300000 данә. Тиражы чагыштырмача күбрәк. Казанда — татар халкының рухи тормышының үзәгендә дә югарыда язылган китапларны кибетләрдә көндез ут яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың. Алар шул ук көнне сатылып беткәннәр. Казанда да ул китапларны таба алмагач, кайда инде безнең Татарстаннан читтә яшәүче биш миллионлы милләттәшләребезне канәгатьләндерү. Алар бит Татарстанны үзләренең мәркәзе дип саныйлар, ярдәм көтәләр. Хәзерге вакытта гарәп язуы белән татар халкы бик кызыксына, өйрәнә. 300 мең данә басылса да, бер генә кибеттә дә юк ул китап. Татарстан китап нәшрияты яңадан бу әлифбаны да бастырса, халкыбыз бик канәгать булыр иде.

Димәк, безнең татар халкы китапка сусаган. Татарстан китап нәшрияты татар телендәге китапларны күбрәк бастырсын иде.

Безнең изге теләгебез: 1990 ел — татар китаплары басуда үзгәртеп кору чорының борылыш елы булсын иде.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛИН.
Казан.

## Хоккей

20—21 мартта булып үткән турда командалар түбәндәгечә уйнадылар: Урицкий исемендәге спорт клубы — «Авангард» — 6:5, 4:1, «Торпедо» (У-К) — «Динамо» — 1:3, 8:3, Армия спорт клубы (Л) — «Автомобилист» — 3:2, 2:5, «Кристалл» (Э) — «Кристалл» (С) — 6:5, 4:2.

Турнир таблицасы

| Командалар | У | Ж | Н | О | Ш | О |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «Торпедо» (У-К) | 26 | 17 | 2 | 7 | 117—79 | 36 |
| «Кристалл» (Э) | 26 | 14 | 4 | 8 | 99—75 | 32 |
| Армия спорт клубы | 24 | 14 | 4 | 6 | 87—66 | 32 |
| Урицкий ис. СК | 24 | 12 | 5 | 7 | 77—64 | 29 |
| «Автомобилист» | 26 | 10 | 5 | 11 | 91—90 | 25 |
| «Трактор» | 22 | 10 | 4 | 8 | 67—69 | 24 |
| «Динамо» | 26 | 9 | 4 | 13 | 68—83 | 22 |
| «Кристалл» (С) | 26 | 6 | 8 | 12 | 83—100 | 20 |
| «Салават Юлаев» | 22 | 7 | 5 | 10 | 47—67 | 19 |
| «Авангард» | 26 | 4 | 1 | 21 | 64—107 | 9 |

27—28 март көннәрендә Казан хоккейчылары Харьковта жирле «Динамо»чылар белән очрашалар.

## Бокс

Якташыбыз Фоат Гатин (57 килограммлы үлчәү категориясендә) ГДРның Галле шәһәрендә бара торган традицион халыкара бокс турнирында совет спортчыларыннан беренче булып ярымфиналга үтте. Ул очколар буенча Куба вәкиле Мануэль Мартинесны бирелдерде.

Турнирда шулай ук Болгария, Корея Халык Демократик Республикасы, Мехико, Мозамбик, Монголия, Сүрия, ГФР, Чехословакия һәм башка ил спортчылары да көч сынаша.

## АТНАЛЫК ПРОГРАММА

### ДҮШӘМБЕ, 26 МАРТ

6.30 «Иртәнге дулкында».
6.55 Белдерүләр.
7.15 Информацион - музыкаль программа.
7.50 Белдерүләр.
8.25 «Татулыкка ни җитә» (чуваш телендә).
15.15 «Язгы каникул көннәрендә» (Мәскәү язмасында).
...
18.00 СССР һәм чит ил хәбәрләре.
18.05 «Социаль гаделлек һәм без».
18.20 СССР халыклары музыкасы.
18.30 Республика хәбәрләре.
18.40 «Кеше һәм закон» (М.)
19.45 Республика хәбәрләре.
19.55 Үзешчән сәнгатьтә катнашучылар концерты.
20.45 Халыкара көндәлек (М.)

### СИШӘМБЕ, 27 МАРТ

6.30 «Иртәнге дулкында».
6.55 Белдерүләр.
7.15 Республика газеталарына күзәтү.
7.30 Иртәнге концерт.
7.50 Белдерүләр.
8.25 «Сезнең хатларыгыз буенча».
8.40 «Коммунист Татарии» журналы битләреннән.
15.40 «Пионер ялкыны» (Мәскәү язмасында).
...
18.00 СССР һәм чит ил хәбәрләре.
18.05 Г. Гафиятуллина җырлый.
18.30 Республика хәбәрләре.
18.40 Бөтенсоюз радиосы тапшырулары.
19.45 Республика хәбәрләре.
19.55 Татар композиторларының камера музыкасы.
20.38 Халыкара көндәлек (М.)
20.53 «Татар музыкасының яңа язмалары» (1990 елның 17 марттагы тапшыруын кабатлау).
22.00 Соңгы хәбәрләр (М.)

### ЧӘРШӘМБЕ, 28 МАРТ

6.30 «Иртәнге дулкында».
6.55 Белдерүләр.
7.15 Республика газеталарына күзәтү.
7.30 Иртәнге концерт.
7.50 Белдерүләр.
8.25 «Үзгәртеп кору һәм хуҗалык исәбе».
15.30 «Пионер ялкыны» (Мәскәү язмасында).
...
18.00 СССР һәм чит ил хәбәрләре.
18.05 Балалар өчен. «Музыка дөньясына сәяхәт».
18.30 Республика хәбәрләре.
18.40 Бөтенсоюз радиосы тапшырулары.
20.00 Республика хәбәрләре.
20.10 Радиотыңлаучыларның сораулары буенча концерт.
21.00 Халыкара көндәлек (М.)

### ПӘНҖЕШӘМБЕ, 29 МАРТ

6.30 «Иртәнге дулкында».
6.55 Белдерүләр.
7.30 Иртәнге концерт.
7.50 Белдерүләр.
14.40 «Пионер ялкыны» (Мәскәү язмасында).
...
18.00 СССР һәм чит ил хәбәрләре.
18.05 Республика хәбәрләре.
18.15 «Контакт». Информацион-публицистик программа.
19.00 Соңгы хәбәрләр (М.)
20.00 Республика хәбәрләре.
20.10 «Музыкаль сәхифәләр». Радиоальманах.
20.45 Халыкара көндәлек (М.)

### ҖОМГА, 30 МАРТ

6.30 «Иртәнге дулкында».
6.55 Белдерүләр.
7.15 Республика газеталарына күзәтү.
7.25 Иртәнге концерт.
7.50 Белдерүләр.
8.25 «Сезнең өчен һәм сезнең хакта».
8.40 Яңа музыкаль язмалар.
15.15 «Пионер ялкыны» (Мәскәү язмасында).
...
18.00 СССР һәм чит ил хәбәрләре.
18.05 Республика хәбәрләре.
18.15 «Яшьлек радиодулкынында».
19.00 Бөтенсоюз радиосы тапшырулары.
19.45 Республика хәбәрләре.
19.55 Лирик көйләр.
20.30 «Халыкара хәл. Сораулар һәм җаваплар» (М.)

### ШИМБӘ, 31 МАРТ

7.15 Республика газеталарына күзәтү.
7.30 Иртәнге концерт.
7.50 Белдерүләр.
8.25 «Тәгәри китте йомгагым...» Әдәби-музыкаль программа.
9.15 «Туганнарча аңлашу».
9.45 «Мәсьәләгә бер караш».
10.15 «Идел дулкыннары». Радиоальманах.
11.00 «Сәламәтлек» (М.)
11.30 Бөек Җиңүнең 45 еллыгына. «Батырлык сәхифәләре».
12.00 «Союз» радиостанциясе (М.)
13.00 «Таныш моңнар».
14.00 «Элемтәдә — Останкино радиостудиясе» (М.)
15.15 «Яшьлек радиодулкынында».
15.45 Халыкара темаларга әңгәмә.

### ЯКШӘМБЕ, 1 АПРЕЛЬ

7.15 Республика газеталарына күзәтү.
7.30 Иртәнге концерт.
7.50 Белдерүләр.
8.25 Балалар һәм ата-аналар өчен. Табигать турында хикәяләр.
11.00 Укучылар өчен. «Фантастлар радиоклубы».
11.30 «Танышу». Яшьләр өчен тапшыру.
12.00 «Союз» радиостанциясе (М.)
12.30 «Тел күрке — сүз».
13.00 Ял концерты.
13.55 Бөек Җиңүнең 45 еллыгына. Б. Горбатов. «Бер төн». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакленең монтажы.

Редактор урынбасары Р. А. СӘГЪДИЕВ.

Газета индексы 54123. Тираж 202900

ПФ 00254. Заказ 371.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясендә басылды.